ГЕТЕ

ФАУСТ



ТАТГОСИЗДАТ
1948

МӘКТӘП СЕРИЯСЕ

ИОГАНН-ВОЛЬФГАНГ ГЁТЕ

ФАУСТ

БЕРЕНЧЕ КИСӘК

МӘХМҮД МАКСУД тәрҗемәсе
ХАТИП ГОСМАН сүз башы

Кавига иптәшлек [illegible]
[illegible] 14. 6. 48

ТАТГОСИЗДАТ
ЯШЬЛӘР-БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ СЕКТОРЫ
КАЗАН 1948

ҖАВАПЛЫ РЕДАКТОРЫ
Ш. МАННУР

ГЁТЕ

ГЁТЕ ҺӘМ АНЫҢ „ФАУСТ“ ӘСӘРЕ

Бөек немец шагыйре Иоганн-Вольфганг Гёте „Фауст“ әсәрен 1774 елда яза башлый һәм, 57 елдан соң, 1831 елда язып бетерә. Аның бөтен гомере буе диярлек язган бу әсәре дөнья әдәбиятының иң бөек әсәрләре рәтенә керә.

Гётенең әдәбият мәйданына чыккан чорында Германия, Көнбатыш Европаның бүтән илләре белән чагыштырганда, гаять артта калган ил иде. Әгәр күршедәге Франциядә бу вакытта бөек тарихи хәрәкәтләр башланган һәм феодализмның черегән, сәрсегән калдыкларын себереп ташлаучы революция давылы шаулаган булса, Германиядә исә урта гасырларның кара реакциясе хөкем сөрә иде әле. Бу ил 300 дән артык вак-вак феодаль биләмәләргә (князьлекләргә, герцоглыкларга, графлыкларга, баронлыкларга һ. б.) бүлгәләнеп беткән иде. Бу биләмәләрнең башында вак князьләр, герцоглар тора. Бу реакцион феодаллар Германиянең бөтен байлыгын суыралар. Нәтиҗәдә промышленность үсми, һөнәрчелек түбән төшә, сәүдә бармый, ил хәерчеләнә, һичнинди хокукы булмаган халык массалары интегәләр, газап чигәләр. Германиянең реакцион тынчу һавасы иҗтимагый тормышны яхшы якка үзгәртерлек көчләргә үсәргә юл куймый, аларны томалый. Җитлекмәгән, зәгыйфь һәм кыюсыз буржуазия исә шушы хәлгә күнә. Үзенең куркаклыгы, вак җанлылыгы белән аерылып торган бу буржуазия җирәндергеч мещан, обывательләр моралена кереп бата. Аның өчен филистерлык, ягъни мещаннарча тарлык, чикләнгәнлек характерлы булып әверелә.

Бу чордагы Германияне характерлап Ф. Энгельс: „Бу—черүче һәм таркалучы бер масса иде“[1]—ди. Немец җәмгыяте гүяки юлы буылып, тукталып калучы һәм, тик торуы аркасында, сөрсегән суны хәтерләтә иде. Әмма бу кара реакцияне себереп ташларлык көч ул вакытта немец халкында юк иде.

„Яхшы заманнарга булган бердәнбер өметне,—дип дәвам итә Ф. Энгельс,—әдәбиятта күрделәр. Бу хурлыклы политик һәм социаль эпоха шул ук бер вакытта немец әдәбиятынын бөек эпохасы булды. 1750 еллар тирәсендә Германиянең барлык бөек акыллары: шагыйрьләрдән Гёте һәм Шиллер, философлардан Кант һәм Фихте тудылар, егерме ел чамасы соңрак Германиянең соңгы бөек метафизигы Гегель туды. Бу эпоханың һәрбер гүзәл әсәре шул вакыттагы немец җәмгыятенә каршы протест, ялкынлы ачу рухы белән сугарылган“[2].

Һәм чыннан да, әдәбият мәйданына француз революциясенең азатлык идеяләре белән рухланган яшь һәм прогрессив немец язучылары килеп чыктылар. Алар давыллы ачу хисе дөрләп торган әсәрләрендә черегән һәм сөрсегән немец җәмгыятенә, вак җанлы немец буржуазиясенең чикләнгәнлегенә, аның җирәндергеч

[1] Маркс—Энгельс „Сәнгать турында“ 1938 М. 297 бит.
[2] Шунда ук.

мещан моралена каршы протест авазын күтәрделәр. Немец әдәбиятындагы бу яңа хәрәкәт „Давыл һәм һөҗүм“—„Sturm und Drang“ хәрәкәте дигән исемне алды. Бу хәрәкәтнең күренекле җитәкчеләреннән берсе яшь Гёте булды.

„Давылчылар“ның феодаль реакциягә каршы күтәргән протестлары күп кенә яклары белән стихияле һәм кирәгеннән артык сүз белән мавыгучы протест иде, тик шунда да бу илне изүчеләргә каршы тирәннән күтәрелгән чын ачу, нәфрәт хисе белән тулган протест булды. Яшь Гётенең бу чордагы әсәрләрендә кол ителгән халыкның җанлы авазы яңгырады.

Гётенең яшьлек елларында язган әсәрләренең үзәгендә шәхес һәм аның азатлыгы мәсьәләсе тора. Гёте феодаль реакциянең шәхесне изүенә, таптавына каршы чыга, шәхеснең азатлыкка, бәхеткә, һәрьяклап үсүгә булган хокукын яклый. Без аның „Гец фон Берлихинген“, „Прометей“, „Яшь Вертернең газаплары“ кебек әсәрләрендә азатлыкка омтылучы геройларны күрәбез. Ул „Яшь Вертернең газаплары“ романында сизгер җанлы, кайнар хисле һәм тирән дулкынлана белүче яшь егет Вертерне сурәтли. Вертернең чын күңеленнән кайнап чыккан нечкә һәм саф хисләрен сурәтләүдә Гёте гаять зур биеклеккә күтәрелә, кешенең рухи тормышын даһиларча зирәклек белән ачып сала, кешенең кадерен белгеләүдә үзенең бөек гуманист икәнен күрсәтеп бирә. Яшь Вертер аны чолгап алган мещаннар, обывательләр тормышында, реакция хөкем сөргән шартларда үз көчләренә урын таба алмый, җәмгыять белән конфликтка керә һәм һәлак була.

„Давыл һәм һөҗүм“ хәрәкәте вәкилләре яшьлек елларында иҗат иткән ялкынлы әсәрләрендә стихияле-демократик идеалларны гәүдәләндерделәр. Алар көрәштә түбәндә индивидуаль бунтка өмет багладылар. Әмма бөтен немец җәмгыятен үтәдән үтәгә сугарып чыккан феодаль реакцияне, мәгълүм ки, индивидуаль бунт белән җиңәргә мөмкин түгел иде. Тиздән аларга бу юл белән уңышка ирешүдән өмет өзәргә, феодаль реакциянең бөтен рәхимсезлеген үз җилкәләрендә татырга туры килде һәм, ниһаять, алар көрәштән ваз кичәргә мәҗбүр булдылар. Моңар, бер яктан, „Давыл һәм һөҗүм“ хәрәкәтенең демократик тамырлары үтә зәгыйфь булу да сәбәп иде. Бу „давыллы даһилар“ның бунтарьланып ашкынган хисләре тиз суынды.

Гёте дә, Веймар принце Карл-Август чакыруы буенча, 1775 елда Веймар герцоглыгына күчте һәм гомергә шунда торып калды. Яшь герцог аңар министрлык эшен йөкләде, үзенең киңәшчесе итте. Хакимлек итүче дворяннар лагере әле күптән түгел генә бунт күтәреп йөргән шагыйрьне рухани яктан үзенә буйсындырырга теләп, аны кабахәт чынбарлык белән килешү позициясенә этәрә барды, бу чынбарлыкның политик тәртипләре белән филистерларча риза булу юлына тартты. Реакционерлар үз максатларының кайберләренә ирешә алдылар: Гёте үз әсәрләренең шактый өлешендә Германиянең патриархаль тормыш формаларын филистерларча мактап җырлады. Әмма, Гётенең хәле каршылыклы һәм ул үзе дә каршылыклы иде; бер яктан, ул тирә-юньнең кабахәтлегеннән җирәнүче даһи шагыйрь, икенче яктан, Веймарның яшерен киңәшчесе сыйфатында, чынбарлык белән килешергә мәҗбүр ителә торган кеше. Аның үзендә менә шушы ике як даими көрәшәләр, аның рухи тормышына, карашларына каршылык кертәләр иде. Ф. Энгельс сүзләре белән әйткәндә, ул: „Әле чиксез бөек, әле вакчыл, әле буйсынмас, көлүче, дөньяга

нәфрәт күзе белән караучы даһи, әле сак, һәммә нәрсәдән канәгать булган филистер"[1], аның күңеле икегә аерылган иде. Шагыйрьне кысырыклаучы реакция йогынтысыннан ул сакланырга да тырышты. Ул, тирә-юне белән килешүдән баш тартып, аңа катнашмыйча яшәргә теләде, шушы максат белән үз шәхси дөньясына кереп бикләнергә омтылды: гүзәллекне сөюгә бирелде, үзенең матур хисләреннән сөенеч, табигатьтән ләззәт алып яшәргә теләде. Бу аңа тирә-юнендәге реакцион-филистерчы тормыштан үзен аерым тотарга ярдәм итте, ул „үз әйләнәсен түгәрәк сызык белән сызып алды, бу сызыкны дуслык, сәнгать һәм фәннән башка бернәрсә дә үтеп керә алмаска тиеш"—диде.

Гёте мондый сызык, мондый чик эчендә торып кала алмады, аңарда чиксез көчләр кайный, аның бөек иҗади акылы тынып кала алмый иде. Ул үз тирә-юнендәге чынбарлыкны нечкәләп күзәтә, үзенең үткен карашыннан үткәрә, ул аны гаять тирән аңлый һәм аңлаганын шул заман өчен искиткеч реалистик тулылык һәм көч белән шигъри әсәрләргә әверелдереп бирә. Аның әсәрләрендәге геройлар гүяки тормышның үзендә яшәүче кешеләр кебек җанлы, тере булып барлыкка киләләр, аларда тормышка булган чиксез мәхәббәт, бәхеткә омтылыш ялкыны дөрли. Әмма боларны даһиларча тирән философия һәм искиткеч шигъри гүзәллек белән гәүдәләндерүдә Гётенең бер әсәре дә аның „Фауст"ы дәрәҗәсенә күтәрелә алмый. Алай гына да түгел: бөтен бер эпоханы дулкынландырган мәсьәләләрне, аның омтылышларын философик тирәнлек белән гомумиләштерүче һәм даһиларча шигъри осталык белән сурәтләп бирүче „Фауст" шикелле бөек бүтән бер әсәр бу чорда Германиядә барлыкка килә алмый. Гёте бу әсәрендә яктырткан мәсьәләләрне, бөтен кешелек өчен зур әһәмияте булган югары дәрәҗәгә күтәрә. Гёте үз даһилыгының барлык чиксез зур көчен шушы әсәренә сала.

Гётенең „Фауст"ы—философик әсәр. Кеше тормышының мәгънәсе нәрсәдә? Кеше нинди максат белән яшәргә тиеш? Феодализмнан яңа, буржуаз җәмгыятькә күчүнең хәлиткеч чорында кешелек алдына менә шушындый сораулар аеруча үткен төстә килеп басалар. Гёте „Фауст" әсәрендә менә шушы сорауларга җавап бирә. Аның җавабы гуманистик җавап булып яңгырый. Гётенең яшьлек елларындагы гуманизмы аеруча Вертер образында гәүдәләнә. Бу гуманизм—пассив гуманизм. „Фауст"тагы гуманизм исә чагыштыргысыз югары тора: бу—хәрәкәт итүче, актив, иҗади гуманизм, бөтен халык бәхете өчен иҗади эшкә рухландыручы гуманизм. Гёте гуманизмындагы бу соңгы сыйфатлар, һичшиксез,—француз революциясенең йогынтысы астында барлыкка килгәннәр.

Феодализм өчен йомыклык, тормыш формаларының катып калганлыгы хас. Шуңар күрә феодализм чынбарлыгы тынчу, ул һәрбер җанлы хәрәкәтне буа, томалый, аның фикер ияләре—„фән" вәкилләре өчен схоластика, ягъни тормышның үлгән, җансыз формаларына ябышып яту, шушы формаларның җимерелү ихтималыннан курку хас. Феодализмның шушы катып калган, черегән, сасыган чынбарлыгына, немец мещанлыгына һәм обывательлегенә Гёте „Фауст" әсәрендә искиткеч шигъри көч белән сурәтләнгән мәңге туктаусыз үсеш, мәңге алга хәрәкәт итү һәм иҗат идеясен даһиларча каршы куя.

---

[1] Маркс—Энгельс „Сәнгать турында" 1938. М. 303 бит.

Әсәрнең үзәгендә доктор Фауст образы тора.

Безнең каршыбызга Фауст башта ук яңадан-яңа максатларга омтылучы, туктаусыз эзләнүче, үткен карашлы, искиткеч зирәк бер кеше булып килеп баса. Ул тынып калуны белми. Аның заманындагы немец филистерлары өчен хас булган тынычлыкка бирелү һәм үз-үзеннән канәгать булу Фаустка бөтенләй ят нәрсә. Ул тормышны түбән формалардан югары формаларга күтәрелә баручы өзлексез, бер генә секундка да тукталып тормаучы хәрәкәт, үсеш дип күз алдына китерә. Әсәрдә чынбарлыкны гәүдәләндерүче рух:

Туу һәм үлем үзе—
Мәңгелекнең диңгезе,
Алмашына тукыма—
Тормыш утында!

ди. Фаустча яшәү—бу туктаусыз алга омтылу, алга хәрәкәт итү, бу—секундта ирешелгән белән канәгатьләнеп калмау, чөнки анда—икенче секундта—югарырак максат көтә. Ул өзлексез яңадан-яңа җиңешләргә омтыла. Аның һәрбер яулап алган җиңеше тагын да югарырак торган җиңешне яулап алу өчен нигез, таяныч кына булып кала бара. Фауст белән Мефистофель арасында төзелгән килешүнең шартын аңлар өчен, Фаустның шушы, югарыда әйтелгән сыйфатларын анларга кирәк. Алар ике арада шундый шарт куялар. Мефистофель Фаустны ирешелгәннәрдән канәгатьләндерерлек дәрәҗәгә җиткерә алса, әгәр шундый секунд килеп җитсә, Фауст, „Тукта, секунд! Син чиксез гүзәл",—дияр, һәм Мефистофель шул чагында Фаустның җанын үзенә алыр.

Тынычланып, башны куйсам мин түшәккә,
Шунда мине бетте, дип бел!—

ди Фауст. Ирешелгән белән чикләнү, үз-үзеңнән канәгатьләнеп калу, күңелеңнең тынычлыкка, ваемсызлыкка бирелүе, аныңча, тормыштан төшеп калу, үлү, гомумән һәлак булу дигән сүз.

Фаустны кешелеккә булган чын мәхәббәт хисе рухландыра. Кешелек өлешенә чыккан барлык хәсрәт һәм шатлыкны ул үзе кичерергә тели, кешелек белән өзелмәслек булып бергә кушылырга омтыла. Мефистофель белән төзегән килешү Фаустка шәхси рәхәтлеккә ирешү юлында хыялына килгән барлык нәрсәләрне булдыру мөмкинлеген бирә. Ләкин Фаустны тар шәхси рәхәтлек кызыксындырмый.

Белем кысымыннан азат күкрәгемдә
Һәрбер төрле зар-әрнүгә урын булсын,
Кешелекнең бөтен кичергәннәре дә —
Һәммәсе дә минем канда ташып торсын.
Белсен рухым иң биекне, иң түбәнне,
Алар биргән шатлыкларны, әрнүләрне,
Минем асылым шулар белән берексен дә,
Иң ахырда алар юкка чыксын бергә!

Фауст менә шулай ди. Ул эзләнә. Аның эзләнүе кешелек бәхете өчен. Эзләнү юлында вакыт-вакыт уңышсызлыкларга очраулар да аны куркытмый. Ул, ялкынланып, бөек көрәшкә, иҗади эшкә омтыла. Ул өзлексез „көрәш тели, ул давылга каршы сугышырга да хәзер, әгәр корабы һәлакәткә очраса, аның анда да исе китмәс".

Гёте үзенең героен бик күп сынаулар аркылы, аны кызыктырып, үзләренә бәйләрлек вакыйгалар аркылы үткәрә. Әмма студентлар-

ның әйттерү-типтерүләре дә, аның Маргаритага булган һәм соңыннан фаҗигале рәвештә беткән мәхәббәте дә, гүзәллеге белән хәйранга калдырырлык Елена да — боларның берсе дә, Фаустка тулы канәгатьләнү бирә алмый, ул чиксез югары идеалларга, хезмәткә, иҗади эшкә омтылуында дәвам итә. Әсәрнең ахырында (икенче кисәк) Фауст бөек төзү эшенә керешә. Ул диңгез суларын куар өчен буа төзи, диңгез астыннан тартып алынган җир кисәгендә азат халыклы хөр дәүләт төзәргә уйлый. Төзелеш күренеше гуманист Фауст карашында, бөтен халыкның иҗади хезмәт мәйданы булып, киң ачылып китә. „Мин күп миллионлы кешеләргә, тулы куркынычсызлыкта булмаса да, азат хезмәт белән яшәр өчен, җир мәйданы ачып бирәм", — ди ул һәм әсәрнең ахырында, кеше тормышының бөек мәгънәсе бөтен кешелек бәхете өчен иҗади хезмәт белән яшәүдән, көн саен туктгусыз көрәшүдән тора, дигән фикергә килә. „Азатлыкка һәм тормышка боларны һәр көн саен көрәшеп алучының гына хакы бар", — ди ул. „Менә мин,— ди әсәрнең ахырында Фауст,— шундый катлаулы тормыш кичерергә, азат халык белән азат җирдә яшәргә теләр идем. Шул чагында мин бер секундка: „Тукта! Син чиксез гүзәл",— дияргә хаклы булыр идем".

Шулай итеп, Фауст бөтен кешелек бәхете өчен булган иҗади хезмәттә канәгатьләнү таба, ә иҗади хезмәт, диалектика законы буенча, тукталып калуны, тынуны белми, ул һаман алга, һаман югарыга омтылудан тора.

Әсәрдәге Мефистофель образының роле беренче карашка тискәре төсле күренергә мөмкин. Ул җимерү, инкарь итү рухы. Әмма ул нәрсәне җимерә? Кешенең ваемсызлыгын, тормышка иллюзияле карашын җимерә. Ул кешенең карашларына уяулык, реалистик үткенлек бирел тора, кешегә сүрәнләнергә, тукталып калырга ихтыяр куймыйча, аны туктаусыз яңадан-яңа эшләргә этәреп бара. Күктәге прологта алла да аның ролен нәкъ әнә шулай билгели:

Кешене эш тиз вакытта ялыктырыр,
Ул бик тыныч ял итүдән рәхәт таба,
Шуңар күрә мин бер юлдаш бирдем аңа,
Җендәй эшләп, үртәп, эшкә өндәп торыр.

Мефистофель чынбарлыкның һәрбер күренешенә кискен тәнкыйть күзе белән карый, аны инкарь итә, җимерә һәм чынбарлыкның үсүче тенденцияләренә шушы эше белән киләчәккә иркен юл ачып бара. Шулай итеп, бу явыз көчнең роле, ахыр чиктә, үсеш өчен кирәкле, зарури роль булып чыга. Бу турыда ул үзе дә бик тапкыр итеп әйтеп бирә:

Мин шул көчнең бер өлеше, кайсы яман
Эшләр тели, тик яхшылык эшли һаман, —

ди. Әсәрнең ахырында Фауст, буа төзү эшенә керешкәч, Мефистофельне төзү эшләрен карап алып баручы итеп билгели. Бу да — ягъни җимерүче көчнең төзүче булып әверелүе дә — Мефистофельнең роленә шагыйрь тарафыннан ясалган бик нечкә ишарә, әлбәттә.

Әсәрдә Гёте бөтен халык катнашы белән барган иҗади эшкә тискәре образ — иске карашлы „галим" Вагнерны каршы куя. Вагнер — схоластик, җанлы тормыштан аерылган „фән" вәкиле, мондый типлар Гёте заманындагы Германиядә немец университетларында еш очрый торган булганнар.

Болар феодализмның фән өлкәсендәге иң җирәндергеч калдыклары. Гёте Вагнерның чикләнгәнлегеннән, җанлы тормыштан еракта — тузанлы кабинетта борынгы китапларны ятлап, сөрсеп ятуыннан ачы итеп көлә. Вагнерның педантлыгына Гёте гаять тирән мәгънәсе булган:

Теория ул, дустым, һаман соры була,
Тормыш дигән алтын агач яшел һаман, —

кебек сүзләрне каршы куя. Монда, әлбәттә, шагыйрь гомумән теорияне инкарь итми, бәлки тормыштан аерылган, иҗади рухы булмаган схоластик теорияне инкарь итә. Гёте теорияне мәңге тере, мәңге яшәреп, гөлләнеп торган җанлы тормышның үзеннән үстереп чыгарырга чакыра.

„Фауст“ әсәрендә „алла“, „фәрештә“, „убыр карчыгы“, „Мефистофель“ кебек нәрсәләрне Гёте, әлбәттә, чынбарлыкның теге яки бу ягын гәүдәләндерүче билге (символ) итеп кенә куллана. Гёте үзе җеннәргә, шайтаннарга ышанган дип уйларга ярамый. Үз вакытында татар халкының бөек шагыйре Тукай да, „Шүрәле“, „Су анасы“ кебек әсәрләрен язгач,

Җен-фәлән дип сөйләшүләр искеләрдән калган ул,
Сөйләве яхшы, күңелле, шагыйрәнә ялган ул, —

дип күрсәтү ясаган. Гёте дә үз әсәрендә чынбарлыкның гади уй-исәп белән иңләп алырга читен булган теге яки бу катлаулы күренешләрен, художестволы төстә гомумиләштереп, конкрет сурәт рәвешендә керткән. Билгеле, бу образларның нигезендә реаль чынбарлык күренешләре ята.

„Фауст“ — бөтен бер эпоханың даһиларча осталык белән эшләнгән картинасы. Гёте үз әсәрендә психологик яктан искиткеч зирәклек һәм нечкәлек белән эшләнгән типик вакыйгаларны сурәтли, бөтен кешелек өчен әһәмияте булган гомумиләштерүләргә кадәр күтәрелә. Аның образлары тирән мәгънәле, шигърият көченә бай, җанлы итеп эшләнгәннәр. Алар мәңге яши торган үлемсез образлар.

Шагыйрь үзенең чынбарлык турындагы фикерләрен тирән мәгънәле афоризмнарга оештырып бирә. Мондый афоризмнар әсәрнең беренче битеннән алып, соңгы битенә кадәр зур юмартлык белән сибелгәннәр. Әсәр кыйммәтле җәүһәрләр белән бизәлгән төсле, афоризмнар, үткен сүзләр белән бизәлеп, әйтерсең, җемелдәп, җанлы нурлар уйнатып, балкып тора. Бу афоризмнарда киң халык массаларының тормыш тәҗрибәсе тупланган. Шуңар күрә дә аларның күбесе мәкаль төсле булып яңгырый. Мәсәлән:

Йөрәкләрне кушарга соң нинди юл бар,
Чын йөрәктән бармаса сүз?

яки:

Тугры фикер, дөрес акыл —
Бизәксез дә көчле балкыр,

кебекләр.

„Фауст“ — бөтен прогрессив кешелекнең гүзәл казанышы. Шуңар күрә ул безнең өчен дә кадерле әсәр. Ул әле татар теленә беренче башлап тәрҗемә ителде. Бу эшне культура өлкәсендәге күренекле җиңеш дип карарга кирәк.

Хатип Госман

БАГЫШЛАУ

Сез киләсез тагын, шәүләләр, чайкалып;[1]
Бер күренгән идегез моңлы күзләремә.
Булырмы бу юлы сезне тотып калып,
Ул хыялны йөрәк эзләрме әле дә?
Кысылышыгыз, мине шулай чолгап алып!
Сезне биргән караңгылык, томан — бергә;
Яшь чактагы төсле дулый бу күкрәгем,
Сулышыннан сез бөркегән әфсүннәрнең.

Сез китерәсез хатирәсен шат чакларның,
Бик күп ямьле күләгәләр баса алга,
Ярым тынган легенда күк хәзер тагын
Беренче саф сөю, дуслык тереләә бар да.
Яңара зур әрнү, кабатлап үз зарын:
Бутап, алдап, тормыш агыла һаман да.
Күптән үлгән яхшы дуслар үтә алдан,
Матур көндә бәхет аларны алдаган.

Ишетмәсләр инде яңа җырларымны,
Беренчеләй җырлый идем мин кемнәргә;
Чәчте язмыш төрле якка дусларымны,
Бирмәс аваз, аһ, элекке күк берәү дә!
Таныш түгел толпа тыңлый моңнарымны,
Авыр миңа, алар мактап сөйләгәндә,
Җырларымнан ләззәт алган кешеләрнең
Төрле якка язмыш сипкән тереләрен.

Бик күптәнге теләкләрем терелә тагын,
Омтылам тын, җитди рухлар дөньясына.
Билгесез бер көйгә яңгырый җырларым,
Сыкраналар ошап эол[2] *арфасына.*
Дулкынланам, нечкәрә һәм йомшый җаным,
Кайнар яшькә чылана күз алмасы да.
Мин нәрсәгә хуҗа булсам, ерак алар,
Үткәннәрнең барысы гүя тормышта бар.

ТЕАТРДА ПРОЛОГ

Директор, театр шагыйре, мәзәкче.

Директор

Сез икегез бүлештегез
Михнәт, зарны күпме еллар,
Я, әйтегез, ничек барып чыгар
Германиядә бу эшебез?
Публикага теләр идем мин ярарга,
Ул яши һәм бүтәннәргә дә юл бирә.
Сәхнәбездә хәзерләнеп бетте бар да,
Һәркем безгә бәйрәм күрер өчен килә.
Һәммәсе дә кашын күтәреп утыра,
Таң калырга иң баштан ук хәзер тора.
Беләм, ничек халык күңелен табалар,
Ләкин бүген гадәттән тыш мин борчылам.
Дөрес, шуннан шәпне күрсәтмиләр аңар,
Ләкин бит ул кот очарлык күп укыган.
Кайдан алыйк, — барысы яңа, кызык булсын,
Мәгънәсе дә һәр кешегә ошап торсын?
Мин яратып карыйм халык агылганын
Бер өзлексез безнең кибет тирәсенә,
Кабатланган көчле дулкын булып аның
Тар ишектән узуын, кысылып бер-берсенә,
Көпә-көндез, сәгать инде дүртләрдә үк
Тарткалашып аның кассага үткәнен,
Икмәк кибете алдындагы ач кеше күк,
Билет өчен муенын өзәргә җиткәнен.
Бу могъҗизаны булдыра шагыйрь генә;
Дустым, зинһар, эшлә шуны син бүген дә.

Шагыйрь

О, сөйләмә шул чуар толпа турында,
Аны күргән чакта авыр була җанга;
Кертмә мине аның шашкын дулкынына,
Ирексездән өстери ул упкыннарга.
Юк, алып кит зәңгәр күкнең тын нурына,
Шунда гына шагыйрь саф, чын шатлык таба.
Анда дуслар һәм мәхәббәт, аллаларның
Әмре белән, шатландыра кеше җанын.

Ах! нәрсәләр туа шунда күкрәгеңдә,
Юаш кына сөйли шунда иренеңниләр, —
Мәгънәсез дә, кайчагында мәгънәле дә, —
Алып китә барысын дулап искән җилләр.
Еллар үткәч, ачык булып ул күренә, —
Матурлыгы инде тулып җиткән, диләр.
Ялтыравык һәрвакытта тиз югала,
Ә чын нәрсә килер буыннарга кала.

Мәзәкче

Килер буын турында син сөйләмә дә!
Аның белән мавыгып йөрсәм мин әгәр дә,
Бүген менә кем көлдерер?
Мәзәк тели халык, моңар хакы да бар.
Бүген гомер итә торган көләч җаннар
Бар мәгънәдән буш түгелдер.
Публикага әгәр берәү ошый белсә,
Борчый алмас һич тә аның капризлары,
Бигрәк яхшы, — халык әгәр күбрәк килсә,
Тагы да көчле ашкындыру ансат аны.
Кыю булып, күрсәтегез осталыкны;
Хоры белән фантазия урын алсын,
Акыл һәм аң, тойгылар һәм дәрт ялкыны,
Бераз гына тилелек тә онтылмасын.

Директор

Иң кирәге — вакыйгалар мулдан булсын!
Тамашачы рәхәтләнеп карап торсын,
Сүтсәгез сез күбрәк маҗара йомгагын,
Таңга калып халык бик киң ачса күзне,
Үстерерсез шунда театрның данын,
Халык сөеп мактар сезне.

Массаны тик масса аша тартып була,
Һәркем үзенә берәр нәрсә сайлап алыр.
Күп китерсәң, күп кешегә бүлеп була,
Һәркем бездән бик канәгать китеп барыр.
Бирегез бүлеп мең өлешкә бер бөтенне, —
Шундый рагу[3] — шатландырыр ул һәркемне.
Ансат аны уйлап табу һәм бирү дә,
Ни файда бар бөтен булсын дип йөрүдә,
Барыбер халык өзеп бетерәчәк түгелме?

Шагыйрь

Сез сизмисез, мондый һөнәрчелек — начар!
Чын сәнгатьче кешеләргә килешми ул!
Тәти әфәнделәр кәгазь пычратсалар,
Ахры, сездә иң яхшысы санала шул.

Директор

Мондый шелтә борчый алмый мине бер дә:
Эшне дөрес эшлим дигән ир кешегә
Сайлау кирәк коралларның яхшыларын.
Сез кисәсез агачларның иң йомшагын.
Карагыз бер, язганыгыз кемнәргә бит!
Эч пошканнан килә анысы, көләргә дип,
Монысы килә аштан соң тук карын белән,
Иң начары — шунысы үзәккә үтә бик:
Бик күбесе төрле журнал укып килгән[4].
Маскарадка барган төсле чаба алар,
Кызык күрү уе барысын китерә безгә;
Хатын-кызлар кием белән мактаналар
Һәм уенга катнашалар түләүсез дә.
Төш күрмәгез шигъриятнең күкләрендә!
Шатмы соң сез, халык шыгрым тулса залга?
Бер карагыз, килми безгә кемнәр генә:
Я бик салкын, я бик тупас алар бар да.
Берсе уйлый, киткәч моннан, карта уйнарга,
Берсе шашкын төн үткәрер фахишәдә.
Тиле дә сез, хезмәт итсен дип шуларга,
Сихри сазны тынычсызлау ул нәрсәгә?
Сезгә сүзем: күбрәк языгыз, күбрәк һаман,
Шулай булса, ялгышмассыз барыр юлда,
Саташсын бар халык шунда,
Башкача һич рәхмәт ишетмәссез аннан.
Нәрсә булды? Илһаммы бу, әрнүме бу?

Шагыйрь

Бүтән бер кол эзләп тап син, бар, кит моннан.
Шагыйрь үзенең иң югары хокукыннан —
Кешелектән — табигатьнең бүләгеннән
Синең өчен мәхрүм калсын мәллә?
Ничек соң ул ялкын сала йөрәкләргә.
Стихияләрне җиңә нәрсә белән?
Сихри аваз белән җиңә—саф йөрәктә
Туып, дөнья гизеп, кайта ул күкрәккә.
Мәңгелекнең җебен табигать, өзмәстән,
Исе китми орчыкка тик чорнаганда,
Бөтен мәхлук, гармонияне һич белмәстән,
Барысы бергә ямьсез тавыш чыгарганда, —
Кем тезә ул авазларны тигез китереп,
Җанландырып, — алар ритмик агылалар, —
Әерымнарны куша изге бөтен итеп, —
Илаһи бер аккорд алып җырлый алар, —
Кем давылны бирә дәртле тойгыларда,
Әлсу нурын кичнең — тирән фикерләрдә?
Сөйгән яры йөри торган сукмакларга
Кем матур гөл сибә язгы шат көннәрдә?
Гади яшел яфраклардан кемнәр үрә
Шөһрәт таҗын данга лаек кешеләргә?
Кем Олимпда аллаларны берләштерә?
Әдәм көче, — ул көч яши шагыйрьләрдә.

Мәзәкче

Димәк, эштә кулланыгыз сез ул көчне,
Шигъри әсәр тусын тизрәк, — туган төсле,
Көтмәгәндә, гыйшык дигән бер маҗара.
Башта кинәт якынаялар, һәм үзара
Аңлашалар, матур гына тойгы туа,
Якынлык гел арта барган төсле була,
Бәхет үсә, көнчелек тә арта һаман,
Сыкрый йөрәк, — менә сиңа әзер роман.
Бирегез шулай безгә сәхнә әсәрләрен!
Чумрып алып тормышыннан адәмнәрнең!
Һәркем яши, тик тормышны белми бар да,
Нәрсә бирсәң, шунысы кызыклы аларга.
Күренешләре чуар булсын һәм караңгы,
Ялганы күп, бер чаткыдай чынлык тагы, —
Шулай бик шәп бер эчемлек кайнап җитәр,
Һәм, яратып, һәркем аннан авыз итәр.

Гөлчәчәге яшь буынның җыелып килер
Пьесада яңа бер дөнья табарга,
Сезнең әсәр меланхолик азык бирер
Хыял сөя торган иркә саф җаннарга.
Дулкынланыр шунда һәрберсе аларның,
Күрер үзенең йөрәгендә нәрсә барын.
Еларга да, көләргә дә әзер алар,
Сокланалар яктылык һәм канатларга;
Кем өлгергән[5], — ярдәм итеп булмас аңар;
Ә кем үсә — рәхмәт әйтер ул һаман да.

Шагыйрь

Бир, алайса, кире яшь чагымны,
Үзем дә мин үскән көннәрне,
Кайчан саф чишмә күк җырларымны
Өзми тудыра идем мин әле;
Бар дөньяны томан каплый иде,
Сер яшеренгән иде бөредә,
Мең чәчәкне назлап саклый иде
Матур болын миңа бирергә!
Малсыз да мин бик зур бер бай идем;
Чынны сөйдем, алдансам да көлдем.
Кире бир зур ашкынулар дәртен,
Әрнү тулы тирән бәхетне,
Чиксез көчен сөю һәм нәфрәтнең,
Кире бир син миңа яшьлекне!

Мәзәкче

Кадерле дус, яшьлек сиңа кирәк була,
Сугышларда өскә дошман ябырылганда,
Зур дәрт белән кайчак синең муеныңа
Җазибәле матур кызлар сарылганда,
Чиксез авыр максатларның якты даны,
Кызыктырып, еракларга өндәгәндә,
Шашынып, дулап озак биегәннән ары,
Эчеп, туйлап, озын төннәр тәнәгәндә.
Әмма, дустым, таныш лираның кылларын
Бер тибрәтү, дәртләнеп һәм чын күңелдән,
Үз алдыңа үзең куйган максатларың
Өчен яну садә алданулар белән, —
Монысы инде сезнең эш, карт әфәнделәр,
Моңа карап кадер кимемәскә тиеш,
Картлык, имеш, безне бала ясый, диләр,
Ялган, аңар без киләбез бала килеш.

Директор

Сүз көрәше шуның белән бетсен,
Күрсә идем сезнең эшне дә!
Макташуга киткән вакыт үтсен
Файдалырак берәр эш белән.
Илһам дип син юатасың кемне?
Көтеп торсаң, илһам килмәс ул;
Шагыйрьлеккә бер кат бирелдеңме,
Шигырьләргә үзең хуҗа бул!
Беләсез ич, безгә нәрсә кирәк:
Эчемлекләр булсыннар көчлерәк,
Хәзерлә тиз! Калса эш бүгеннән,
Эшләнми ул иртән — мин беләм.
Буш үтмәскә тиеш һичбер көн дә,
Эләктер син мөмкин булганны
Ялыннан бик кыю һәм тиз генә,
Ычкындырып җибәрмичә бер дә,
Алып бар син алга гел аны.
Сез беләсез немец сәхнәсендә
Һәркем эшли кулдан килгәнне,
Кызганмыйбыз, бездә җитмәгәнме —
Машина һәм җиһаз, һәммәсе дә!
Күп бирегез кояш нурларын,
Мул сибелсен күктә йолдызлар!
Ут, су, хайван, кошлар, текә яр —
Һәммәсе бар бездә шуларның.
Дөрес, безнең сәхнә тар гына,
Сыйдырыгыз ләкин барын да.
Анда сезнең сәфәр тоташа[6]
Күктән җәһәннәмгә җир аша.

КҮКТӘ ПРОЛОГ

Тәңре, күк гаскәрләре. Аннары Мефистофель.

Өч фәрештә алга чыга.

Рафаиль

Кардәш сфералар[7] белән һаман
Кояш җырлый үзенең җырларын,
Күк күкрәтеп уза үзе, алдан
Сызылып куйган барыр юлларын,
Нуры аның безгә бирә көчне,
Тирән серен белми беркем дә,
Беренче кат балкыганы төсле —
Каинатең[8] гүзәл бүген дә.

Җәбраиль

Тизлегенә акыл җитә алмас —
Әйләнгәләп оча җир шары,
Оҗмах нурын биргән көнгә алмаш
Булып килә кара төн тагы.
Диңгез дулкыннары, меңгә ярылып,
Кыяларга килеп кагылалар,
Диңгезне дә, кыяны да алып,
Сфералар мәңге агылалар.

Микаиль

Зур давыллар ярсып ыргылалар
Диңгезләрдән җиргә, тагын да
Диңгезләргә кире; тукый алар
Серле күренешләрнең барын да.
Үлем яшене кинәт кабынып ала,
Белдерә ул күкләр күкрәвен,
Без котлыйбыз ләкин, һаман, алла,
Тагын килерен якты көннәрнең.

Өчесе бергә

Нурың синең безгә бирә көчне,
Сереӊ тирән, — белми беркем дә,
Беренче кат балкыганы төсле
Каинатең гүзәл бүген дә.

Мефистофель

О, син, тәңре, безгә якын килдең тагын
Һәм теләдең яңа хәбәрләр белергә,
Син һичкайчан миңа начар карамадың;—
Шуңар мин дә хадимнәрең белән бергә.
Кичер, тәңре, матур сүзләр сөйли белмим,
Шуның өчен мине нәләтләсәләр дә;
Мин пафоска бирелсәм, син көләрсең, дим,
Онытмаган булсаң көлүне әгәр дә!
Кояшны һәм дөньяларны сөйләү нигә,
Мин күрәм тик, кеше ничек җәфа чигә,
Дөньядагы нәни алла — тәүге көндә
Нинди булса, шундый мәзәк ул бүген дә.
Бераз яхшы яшәр иде, әгәр аңа
Син бирмәгән булсаң күкләр нурын, алла.
Акыл дип ул атый аны,
Әмма үзе хайваннарның да хайваны.
Охшаган ул, рөхсәт итсәң син әгәр дә,
Минемчә, бер озын сыйрак чикерткәгә,—
Мәңге сикерә, очкан була,
Һәм җырлый ул бер үк җырны һаман шунда;
Ятсын иде үләндә тик тыныч кына,
Һәр пычракка нигә үзенең борынын тыга?

Тәңре

Әйтеп бетердеңме соң барын да?
Син киләсең һаман зарланырга.
Җир йөзендә яхшы нәрсә юкмы әллә?

Мефистофель

Юк шул, тәңрем, бары да начар, дөрестән дә.
Мескен кеше шундый михнәт чигә җирдә,
Хәтта аны газапларга бөзмыйм мин дә.

Тәңре

Син Фаустны беләсеңме?

Мефистофель

Докторнымы?

Тәңре

Минем бәндәм!

Мефистофель

Хезмәтендә ошамый ул башкаларга,
Җир азыгын азык дими ул дивана.
Ашкына бик еракларга аның җаны,
Яртылаш ул аңлый үзенең тилелеген,
Эстәгәне — күкнең матур йолдызлары
Һәм иң бөек ләззәтләре җир йөзенең.
Ләкинниләр бар якында, еракларда, —
Берсе тынлык бирми давыл сөйгән җанга.

Тәңре

Аңсыз хезмәт итә миңа ул әлегә,
Ләкин аны яктылыкка китерәчәкмен
Бакчачы да, агач утыртканда белә,
Алда аның чәчәк, җимеш бирәчәген.

Мефистофель

Бәхәсләшик! Сездән китәр ул бик теләп,
Миңа сездән рөхсәт булса,
Үз юлымда аны йөртергә өстерәп.

Тәңре

Җирдә ул тормыш корганда,
Тыймыйм сине бу эшеңнән,
Ялгышучан һәркем, алга омтылганда.

Мефистофель

Рәхмәт сезгә; үләләр белән
Эш итәргә сөймим, ачык әйтәм барын.
Мин яратам битнең алланып торганын.
Үләксәләр ерак булсын минем яннан,
Уйныйм, песи тычкан уйнаткандай һаман.

Тәңре

Ярый, сиңа рөхсәт бирәм,
Бу рухны син яздыр юлыннан,
Һәм алып бар үзең белән,
Әгәр шул эш килсә кулыңнан.
Хур булырсың бер син әммә, белеп шуны:
Чын кеше ул, караңгыда эзләнсә дә,
Күңеленнән сизеп тора тугры юлны.

Мефистофель

Бик шәп! Тиздән ачык булыр бар нәрсә дә.
Мин курыкмыйм бу бәхәстә оттырудан.
Теләгемә ирешкәч, — дип әйтеп куям, —
Мин тантана итәчәкмен бер, мактанып.
Туфрак ашар ул бер вакыт, бик шатланып,
Шулай туфрак ашаган күк апам — елан.

Тәңре

Шул чагында, рөхсәт бирәм, бер кил тагы,
Синдәйләргә нәфрәт иткәнем юк әле.
Бер тикшерсәм баш тартучы рухларны,
Ачуымны аз китерә хәйләкәре.
Кешене эш тиз вакытта ялыктырыр,
Ул бик тыныч ял итүдән рәхәт таба,
Шуңар күрә мин бер юлдаш бирдем аңа,
Җендәй эшләп, үртәп, эшкә өндәп торыр.
Ә сез, алла угыллары, шатланыгыз,
Мәңгелек бай гүзәллектә ямь табыгыз.
Үсә барган нәрсә яши, эшли мәңге[9],
Чорный сезне мәхәббәткә, саф нурларга.
Зәгыйфь күренеш булып тонык тирбәлгәнне
Ныгытыгыз озак дәвамлы уйларда.
(*Күк ябыла, фәрештәләр таралалар.*)

Мефистофель

(*ялгыз*)

Кайчагында картны күрсәм, ачыла күңелем,
Мин сакланам безнең ара өзелүдән.
Нинди гүзәл, шундый бөек бер тәңренең
Кешелекле сөйләшүе шайтан белән.

БЕРЕНЧЕ СЦЕНА

Төн

Гөмбәзләп ясалган биек түшәмле тар готик бүлмәдә, борчулы Фауст үзенең креслосында биек өстәл алдында утыра.

Фауст

Философия өйрәндем,
Медицинаны да белдем,
Хокук фәнен, дин фәннәрен, —
Һәйһат!—тырышып укып йөрдем[10].
Ахмак үзем тик әле дә,
Элеккедән акыл һаман артмый бер дә!
Магистр һәм доктор диеп олылыйлар,
Шәкертләрне, менә инде бер ун еллар,
Сөйрәп йөртәм борыныннан алга, артка,
Теләгәнчә, унга, сулга, өскә, аска.
Һәм күрәмен: ирешмибез һич белемгә,
Йөрәкне шул әйләндерер, ахыры, көлгә.
Акыллы да булыйм төрле ахмаклардан,
Язучыдан, магистр, поп, докторлардан;
Җәфа чикмим төрле шик һәм шөбһәләрдән,
Курка белмим җәһәннәмнән һәм җеннәрдән —
Ләкин миннән бик еракта чын шатлыклар,
Белә алмыйм: хәкыйкатькә нинди юл бар,
Белә алмыйм: нәрсә кирәк өйрәтергә —
Кешеләрне үзгәртергә, төзәтергә.
Юк шулай ук байлыгым һәм акчам минем,
Зур түгелмен, кадер-хөрмәт тә күрмимен.
Яши алмас эт тә мондый тормыш белән!
Шуңар күрә магиягә күңел бирәм.
Рухлар миңа белдерсеннәр,
Мәгълүм булсын яшерен серләр,

Моннан соң мин, шабыр тирләп,
Белмәгәнне йөрмәм сөйләп,
Мин аңлармын — бар дөньяны
Эчтән нәрсә баглаганны,
Бер табармын иҗат орлыгын,
Ташлап сүздә казыну хурлыгын.

О, тулган ай! Бүген мине
Соңгы тапкыр күрсәң иде,
Шундый авыр, зарлы хәлдә
Бүлмәдә төн кичергәндә!
Китапларга, дустым, тагын
Сибелә синең саф нурларың.
Ах! Иөрсәмче биек тауда,
Синең ямьле нурларыңда!
Рухлар белән булсамчы тау өсләрендә,
Гизсәмче киң болында моң кичләремдә,
Белем газабыннан азат булыр идем,
Чыкларыңда саулыкка дип коеныр идем!

Һәйһат! Һаман мин зинданда,
Нәләт — тынчу, таш диварга!
Чуар тәрәзәләр аша
Нурлар тонык үтә анда.
Кортлар кимереп, тузан күмгән
Китап тавы тирә-ягым,
Тетелеп барган кәгазь белән
Бар бүлмәне тутырганмын;
Киштәләрдә реторталар[11],
Һәм тәҗрибә кораллары,
Бабаларның черек малы, —
Менә синең дөньяң — шулар! Дөнья — шулар!

Ә сорыйсың: ник йөрәгең
Күкрәгеңне гел тарсына,
Аңлашылмас әрнүләрең
Киртә була ник барсына?
Кешеләргә алла биргән
Тере табигать урнына,
Тузан баскан, череп килгән
Үле сөякләр кулында.

Бар! Кач! Ерак кит син моннан!
Бу китапта күп серләр бар,

Нострадам[12] язып куйган,
Житәкче дип син шуны ал!
Йолдызларның юлы беленер,
Табигать: „син бел!“ дигәндә,
Җанга яңа көч өрелер,
Рухка рух хәбәр биргәндә.
Булмый коры акыл белән
Аңлап изге билгеләрне.
Очар рухлар, сорыйм сездән:
Ягез, җавап бирегез әле!

(*Китапны ачып, макрокосм[13] билгесен карый.*)

О! Күргәндә шуны, яңа дәрт уяна,
Ялкынланып, миндә бер кат тагын!
Яшь чактагы төсле йөрәк дөрләп яна,
Изге тойгы белән тибә тамырларым.
Бу билгене язган мәллә үзе хода,
Ул тынычлык бирә җанга,
Мескен йөрәк шатлык таба анда,
Серләр тулы омтылышта
Табигатьнең көче мине чолгап ала.
Әллә инде үзем алла? Якты нинди!
Миңа шушы гүзәл билгеләрдә, менә,
Бай табигать үзе күренә.
Аңлыйм хәзер, хәким адәм дөрес сөйли:
„Рух дөньясы бикле түгел бер дә,
Акылың бикле, үле — йөрәгең.
Тор, коенсын, шәкерт, иренеп йөрмә,
Таң нурында зарлы күкрәгең!“

(*Билгене карый.*)

Һәрнәрсә дә килә бер бөтенгә,
Бар нәрсә дә яши бер-берсендә!
Күк көчләре — аста, югарыда,
Алтын табаклар бар кулларында!
Рәхмәт канатларын кагынып алар,
Күктән, бу җир аша, юл алалар,
Бар нәрсәгә гармония салалар!
Нинди күренеш! Ләкин бу тик күренеш тагын.
Табигать! Син — чиксез, ничек мин кочармын?
Имчәкләрең кайда? Тереклек, көч бирә
Җирләргә дә, күкләргә дә алар,
Хәл алалар шулай арган җаннар,
Сез һәркемгә азык, ә мин мәхрүм нигә?

(Сабырсызланып, китап битләрен актара һәм Җир Рухы[14] билгесен күрә.)

Башкача бу билге миңа тәэсир итә!
Син якынрак ич миңа, рухы җирнең!
Сизәм, хәзер көчем арта минем,
Янам, гүя яңа шәрап башка китә.
Теләк сизәм тормыш эченә керергә,
Җирнең зарын, җирнең бәхетен белергә,
Көрәш өчен ташланырга давылларга,
Каушамаска, көймәм һәлак булса анда.
Тирә-як караңгы —
Ай яшерә нурын —
Лампа сүнә!
Сөрем! — кызыл нурлар оча
Баш очымда. — Түшәмнән
Курку иңә түбәнгә — һәм
Мине чолгый!
Сизәм, көчле рух, син шунда, якында.
Күрен тизрәк!
О, йөрәк нинди ашкына!
Яңа тойгылар,
Дәртләндереп мине, тудылар!
Сизәм, сиңа талпына ич йөрәгем!
Күрен! Күрен! Ризамын — үлсәм үләрмен!

(Китапны кулына ала һәм серле рәвештә Рухның билгесен әйтә. Кызыл ялкын кабынып китә, ялкын эчендә Рух күренә.)

Рух

Кем чакырды мине?

Фауст *(читкә борылып)*

Коточкыч йөз!

Рух

Көчең белән чакырып син китердең,
Минем сферама килеп кердең,
Я соң? —

Фауст

Куркам синнән! Югал! Бар, кит!

Рух

Бик теләдең мине син күрергә,
Ишетергә минем тавышымны,

Аңладым да көчле сагышыңны,
Килдем миңа! — Ник хурлыклы курку йөгерә,
Өстен кеше[15], йөзеңә? Кайда җан нидасы,
Күкрәгеңнең иҗат иткән үз дөньясы?
Аны саклап синең йөрәк мәгърур типте,
Безгә, рухларга, тиңлекне хыял итте.
Кайда, Фауст, син, — тавышың яңгырый иде,
Бәтен көчең белән көтә идең мине?
Бу—синме соң, сулышымнан коелып төштең,
Калтырыйсың, качты төсең,
Куркак бер кортмы алдымда?

Фауст

Ялкын заты, синнән ник куркыйм мин?
Мин — бу, мин — Фауст, мин — сиңа тиң!

Рух

Тормыш дулкынында, эш давылында,
Өскә-аска чайкалам,
Бире киләм, ары барам,
Туу һәм үлем үзе —
Мәңгелекнең диңгезе,
Алмашына тукыма —
Тормыш утында!
Туку станогын алып заманнарның[16],
Тукыйм шундый җанлы киемен аллаларның.

Фауст

Син колачлый аласың бар дөньяны да,
Эшлекле рух, мин никадәр якын сиңа.

Рух

Кайсы рухны аңласаң — син тик шуңар тиң!
Миңа түгел!

(Юк була.)

Фауст *(боегып)*

Сиңа түгел?
Ә кемгә соң?
Мин, илаһлык чагылышы,
Хәтта сиңа да тиң түгел!

(Шакыйлар.)

Фауст

Үләм инде! Беләм минем фамулус[17] ул —
Матур бәхетемне юк итәр!
Серле, тулы күренеш үтеп китәр,
Коры такылдыкның эше тик шул!

(Вагнер төнге бүрек һәм халат кигән, кулына лампа тоткан. Фауст, кәефсезләнеп, читкә борыла.)

Вагнер

Кичерегез, нидер укый идегез сез,
Грек трагедиясеннән булса кирәк.
Сөйләсәмче мин дә оста, сез беләсез:
Хәзер бездә моның кадере зур бигрәк.
Миңа бик еш ишетергә туры килә:
Вәгазьчегә дә мәзәкче акыл бирә.

Фауст

Әйе, вәгазьчең мәзәкче булса әгәр,
Очрашкалый бездә хәзер мондый хәлләр.

Вагнер

Ах! Бикләнеп шушы музейның эченә[18],
Һәм дөньяны күреп бәйрәм көнне генә,
Бик ерактан, телескоптан, карап аңа,
Башкача сүз йөртергә соң бармы чара?

Фауст

Булмаса хис, һәммәсе дә бушка гына,
Сүз ташысын ул күңелдән,
Тыңлаучыны шунда гына
Әсир итәр зур көч белән.
Утырыгыз, ябыштырып юкны-барны!
Чит табыннан рагу пешереп,
Үзегезнең көл өеменнән аңар тагы
Сүнеп барган ялкын өреп.
Таң калсыннар бала-чага һәм маймыллар,
Шуннан кәеф тапсагыз сез;
Йөрәкләрне кушарга соң нинди юл бар,
Чын йөрәктән бармаса сүз?

Вагнер

Оста сөйләү, ни әйтсәң дә, зур бәхет ул,
Аңлыйм моны, әмма үзем бик артта шул.

Фауст

Чын бәхеткә омтыл һаман,
Булма шалтыравык надан!
Тугры фикер, дөрес акыл
Бизәксез дә көчле балкыр.
Булса чын фикерең әйтергә,
Сүз артыннан кума бер дә.
Әйе, сезнең сүзләрегез матур алар,
Түбәнлекне теткәләп салалар,
Юк аларда ләкин һич тә тормыш көче,—
Җилләр көзге яфрак аша искән төсле.

Вагнер

Аһ алла, юк фәннең чиге,
Кыска ләкин безнең гомер.
Омтылса да тәнкыйтькә гел минем күңел,
Бик еш борчу ала мине.
Җиңел түгел бу дөньяда табу чара
Чишмәләргә җитәр өчен;
Мескен адәм, бетереп көчен,
Ярты юлга җитү белән үлеп кала.

Фауст

Пергаменттан эзләдеңме изге чишмә,
Шуннан эчеп, сусыныңны кандырырга?
Баса алмассың сусаганны ләкин һич тә,
Ташымаса әгәр чишмә үз җаныңда!

Вагнер

Гафу утенәм! Шатлык сизә, җаным,
Аңлый алсам рухын заманнарның,
Күрсәм, бездән элек хәким ни уйлаган,
Һәм без ничек юл үткәнбез алга табан.

Фауст

Әйе, йолдызларгачамы?
Дустым, үткән заманнарның бары
Җиде мөһер суккан китап алар.
Заманнарның рухы дигәнең дә,
Рухы бит ул хакимнәрнең генә,
Шунда чагылалар заманнар.
Анда бик еш хәсрәт кенә, чыннан!
Күрү белән аннан кеше кача,
Чүп кәрзине, сәләмәләр тулы чолан,

Шәп дигәндә, падишалар тарткалаша,
Прагматик максимасы[19] матур була,
Барысы курчак уенына ошап куя.

Вагнер

Ләкин дөнья! Кеше рухы һәм йөрәге!
Моны белү һәркемнең дә теләгендә.

Фауст

Белү! Ул соң үзе нәрсә әле?
Яшь баланың чын исемен кем атый белә?
Бик аз гына кешеләр бераз белә алды,
Тиле булды, яшермәде аңлаганны,
Тойгыларын, карашларын сөйләп барын,
Шуның өчен дарга менде, утта янды.
Гафу үтенәм, дустым, хәзер бик соң инде,
Сүзне шунда бүлү кирәктер дип беләм.

Вагнер

Мин йокысыз кичерер идем бөтен төнне,
Шулай гыйльми сөхбәт кылып сезнең белән.
Зинһар миңа иртәгә, пасха таңында,
Рөхсәт итегез бернечә сорау тагын да.
Бик яратам чынлап тырышып өйрәнергә,
Күпне беләм, телим барын да белергә.

(*Китә.*)

Фауст

Шул кешедә ничек өмет яши ала?
Ул бит һаман иске ялгап гомер итә,
Комсыз кулы аның хәзинәләр көтә,
Яңгыр корты тапса әгәр, әй, шатлана!
Шундый кеше тавышы ничек янрады ул,
Мине рухлар чолгап алган шушы төндә?
Хәер, аңар бик зур рәхмәт миннән бу юл,
Җир уллары арасында иң мескенгә.
Син килдең дә кинәт тартып алдың мине,
Өметсезлек акылымны биләгәндә,
Ах! Ул күренеш шундый гаҗәп бөек иде,
Сиздем анда мин үземне нәкъ бер кәрлә.

Мин илаһлык өлгесемен, мәңгелекнең —
Хәкыйкатьнең көзгесенә якын бардым,

Күкнең чиксез сафлыгында сулыш алдым,
Аерылдым улларыннан җирнең,
Йөгертергә табигатьнең тамырына
Азат көчне, фәрештәдән булып өстен,
Аллаларның тормышыннан тәм алырга
Иҗатта мин теләдем, — һәм егылып төштем:
Дәһшәтле сүз миңа шундый тәэсир итте.

Мин дә сиңа тиң дияргә базмыйм инде;
Тик чакырып китерергә көчем җитте,
Җитмәде көч җибәрмәскә кире сине,
Ул бәхетле минутларда
Кечкенә һәм бөек идем!
Кире кактың мине, бетте бар да,
Мин — кешемен, язмыш яшерен минем.
Кем өйрәтер? Ничек эзләнергә?
Тыңларгамы йөрәк боерганын?
Ах! Хәсрәт кебек, эшләр үзләре дә
Бикләләр тормыш юлларын.

Рух омтылган гүзәллекне — галилекне
Җир көчләре һаман читкә куып тора;
Бу дөньяның рәхәтенә тиендекме, —
Яхшы нәрсә—алдау, ялган булып тоела.
Нинди якты тойгы булса безнең җанда,
Тормыш ыгы-зыгысында кибә бар да.

Өмет белән мәңгелеккә тотып юлың,
Фантазия, канат кагынып, талпынганда,
Заман упкынында җитә бик аз урын,
Бәхетләргә бәхет кагылып ватылганда.
Сагыш, йөрәкнең түрендә оя ясап,
Тудырып тора яшерен әрнү, яшерен газап,
Тынгысыз ул, шатлык тынычлыкны җимерә,
Үзе һаман яңа битлек киеп килә,
Йорт-җир, хатын, балаң булып баса алга,
Ут, су, хәнҗәр, агу да ул,
Югалмаган нәрсәң өчен елата шул,
Бер дә юкка калтырыйсың син һаман да.

Аллаларга тиң түгел мин! Уйлама да!
Җир кортына тиңмен дисәм, шул бик җитә,
Ул тузанда яши, шунда азыклана,
Юлчы аягы аны сытып, күмеп китә.

Диварларда күпме киштә, әллә алар
Тузан түгелме барысы да?
Күпме сәләмәләр мине ураганнар
Шул көяләр дөньясында!
Шунда тиеш эзләгәнне мин табарга?
Мең китаптан укып, имеш, белим мин дә:
Җәфа чиккән кеше һәр заманда,
Бер бәхетле очрап куйган ара-тирә.
Баш сөяге, ыржайтасың ник тешеңне?
Синең ми дә бер заманны, нык адашып,
Якты көннәр эзләп, ямьсез кара төнне
Хәкыйкатькә омтылгандыр, бер саташып.
Мине мыскыл итеп көлә төрле корал:
Өчпочмаклар, өтергеләр, төрле винтләр,
Мин ишеккә килдем: ачкыч, дидем, болар;
Тешләре шәп, ачылмады ләкин бикләр!
Табигатьнең пәрдәләрен булмый ертып,
Үзе нәрсә ачса синең рухка, шуннан
Артыкны һич белә алмассың, кайчы тотып.
Иске җиһаз, кирәге юк миңа бер дә,
Тора шунда, әткәемә хезмәт иткән;
Иске төргәк, күмелеп беткән ул сөремгә,—
Бу өстәлдә лампа төти шулай күптән.
Мин тиз генә бетерер идем ул аз малны,
Андый йөктән тирләгәнче шушы җирдә!
Атаң-бабаң нинди мирас бирсә, аны
Кирәгеңә тота белү өчен билә.
Бер авыр йөк—файдасы юк малның бары,
Тик лахзаның[20] тудырганы файда бирә.

Тукта, нигә күз текәлде шул урынга?
Ул шешәдә берәр магнит бармы әллә?
Шундый якты булып китте, ай нурында
Коенган күк карурманда тын төннәрдә.

Сәлам сиңа, фиал[21], кадрең чиксез, беләм,
Алам сине кулга тирән хөрмәт белән!
Изге суың серле йокыга талдыра,
Чишмәсе син гүзәл үлем көчләренең,
Яшергәнсең кешеләрнең акыл-белемен,
Үз хуҗаңа шәфкатьлерәк бул тагын да!
Күрсәм сине, басыла әрнүләр йөрәктә,
Алсам кулга,—юашлана дәрт-теләк тә.

Рухымдагы көчле дулкын тынып калган,
Килеп чыгам ачык диңгезнең янына,
Көзге кебек су бәреләә аягыма,
Яңа көнем тарта яңа ярга табан.
Ут арбасы оча җиңел канатларда
Миңа табан. Сизәм, мин хәзермен
Эфирда өр яңа юллардан атларга
Дөньясына яңа һәм саф эшчәнлекнең.
Шушы гали тормыш! Йорты аллаларның!
Әй җир корты, соң син лаеклымы шуңа?
Әйе, ләкин кыю булып, ташлап барын,
Арканны бир җирнең якты кояшына.
Тәвәккәллә шул ишекләрдән керергә,
Кайсыларны һәркем читләп үтеп китә,
Вакыт җитте эшләр белән белдерергә —
Аллалардан кеше түбән түгел һич тә.
Калтыранма кара упкынның ярында,
Кайда көчсез фантазия сыкрый һаман;
Туктап калма үтеп чыгар юл алдында,
Хәтта бөркеп торса тамуг уты аннан.
Шул адымны шат атларлык син кыю бул,
Юклык эченә күчү хәвефен бирсә дә ул[22].

Әй саф хрусталь бокал, миңа син кил бире,
Ташла да шул тузып беткән футлярыңны!
Мин күп еллар уйламадым синең турда.
Бабамнарның туйларында нур сипкәнсең,
Кунакларны шат иткәнсең,
Күчеп йөреп зур табында кулдан кулга.
Бизәгеңнең шундый матур ялтыравы,
Эчкән чакта мактау шуны салып җырга
Һәм бушатып бирү сине, алмый тын да, —
Хәтерләдем шуның һәммәсен дә тагы.
Хәзер сине мин бирмәмен бирәүгә дә,
Сине мактап үткер сүзләр сөйләмәм дә.
Бу эчемлек нык исертә, эчсәң аны;
Ул тутыра эчне кара дулкын белән,
Хәзерләдем үзем, инде үзем эчәм;
Соңгы эчү — бик тирәнтен, чын күңелдән
Сәламләвем булсын туып килгән таңны.

(Бокалны авызына китерә. Чаң авазы һәм хор белән җырлау ишетелә.)

Фәрештәләр хоры

Гайса калыкты!
Кайгылы заманда,
Михнәттә һаман да
Яшәгән җаннарга
Шатлык балкыды.

Фауст

Нинди тирән аваз, матур, саф аһәңле,
Читкә тарта шул касәне иренемнән?
Чаңнар инде безгә хәбәр бирәләрме
Изге бәйрәм — пасха таңы килүеннән?
Җырлыйлармы хорлар юаткыч җырларны,
Гайса үлгәч фәрештәләр җырлаганны —
Ярлыканыр гөнаһ дигән вәгъдә белән.

Хатыннар хоры

Изге саф суда
Тәнен юдык та,
Без аны шунда
Салдык табутка.
Кәфенне дә без
Урадык бик мул,
Ах! Ни күрәбез:
Биредә юк ул.

Фәрештәләр хоры

Гайсабыз килде!
Аны нык сөйгәннәр,
Күп бәла күргәннәр,
Сынауны белгәннәр —
Шатлансын инде!

Фауст

Көчле, нечкә сихри моңнар,
Ник эзлисез мине җирдә?
Яңгырагыз, кайда нечкә җаннар тыңлар,
Ишетсәм дә сезне, иман юк шул миндә;
Могъҗиза тик чын иманнан гына туар.
База алмыйм шул дөньяга омтылырга,
Матур тавыш килә кайдан;
Гадәтләнгән бу җырга мин яшь заманнан,
Ул хәзер дә яшәргә дип чакырып тора.

Күкләр мәхәббәте үпте мине
Күптән инде изге бу шимбәдә,
Чаң авазы серле иде ул төндә дә,
Дога уку тирән ләззәт бирә иде.
Серле матур бер дәрт анда
Илтте мине урманнарга, болыннарга,
Кайнар яшьләр белән елаганда,
Туды миндә яңа дөнья.
Бу җыр тагын яшьлекнең шат уеннарын
Хәтерләтте, бәйрәм узды күз алдыннан,
Истәлекләр, балачакның тойгылары
Тотып калды мине шомлы бу адымнан.
Яңгырагыз, о, сез, татлы күк җырлары!
Коела күздән яшьләр, җиргә кайттым тагы!

Шәкертләр хоры

Күмелгән җиреннән
Күкләргә ашкан ул,
Галилек бирелгән,
Югары баскан ул.
Бик якын ул анда
Иҗатка — рәхәткә,
Ә без бу дөньяда —
Яшибез хәсрәттә.
Безне, аһ, бу җирдә
Калдырдың сагышта,
Әй остаз, син кил дә
Киң бәхет багышла!

Фәрештәләр хоры

Гайсабыз терелде,
Калыкты гүреннән,
Богаулар өзелде
Изге бер көч белән.
Сез, аны сөйгәннәр,
Хөрмәтләп йөргәннәр,
Дуслыкны белгәннәр,
Серләрне күргәннәр,
Шатлык бар дигәннәр, —
Яңадан килде ул,
Шушында инде ул.

ИКЕНЧЕ СЦЕНА

Шәһәр капкасы янында.

Күңел ачып йөрүче төрле кешеләр үтәләр.

Берничә яшь һөнәрче

Сез кая киттегез?

Башкалар

Аучы йортына. Ә соң үзегез?

Беренчеләр

Ә без киттек тегермәнгә табан.

Берәү

Ничек булыр күлгә барганда?

Икенче берәү

Юл бик начар анда.

Икенчеләр

Ә син кая?

Өченче берәү

Мин дә алар белән барам.

Дүртенче берәү

Бургдорфка барыйк, сүземне тыңла,
Анда иң матур кызлар, иң яхшы сыра.
Тәпәләшү дисәң — иң шәбе.

Бишенче берәү

Әй син, малай, кызык яратасың бигрәк,
Өченче кат аркаң кычыта булса кирәк,
Юк, мин анда барырга уйламыйм әле.

Хезмәтче кыз

Юк, юк, кире кайтам мин шәһәргә.

Икенчесе

Ул торадыр шунда тал янында.

Беренчесе

Бу миңа зур бәхетме әллә;
Синең яктан барыр ул тагын да,

Ул һаман тик синең белән бии,
Синең шатлык миңа берни бирми.

Икенчесе

Бүген бит ул ялгыз түгел инде,
Бөдрә чәчле берәү килер, диде.

Шәкерт

Кара, анда матур кызлар бара!
Куып җитик, туган! Йоклап калма!
Әйбәт сыра, шәп тәмәке, аннан тагын —
Көяз хезмәтче кыз минем яратканым.

Шәһәр кызы

Карасана матур егетләргә!
Бу соң хурлык түгелмени, —
Яхшы кызлар беткән микән әллә,
Алар кемгә кызыгып йөри!

Икенче шәкерт

(*беренчесенә*)

Чапма! Арттан икәү килә тагын,
Икесе дә матур киемнән,
Берсе минем күрше кызы аның,
Гашыйк булып йөрим күңелдән.
Алар шулай акрын барырлар,
Бара торгач, безне алырлар.

Икенчесе

Юк, туганкай, алай ярамый ул.
Тизрәк! Юкса, кошлар очып та китәрләр.
Шимбә көнне себерке тоткан кул
Якшәмбе көн шундый иркәләр!

Шәһәр кешесе

Яңа бургомистр ошамый бер дә!
Усаллана бара көннән көнгә.
Шәһәргә ни файда аннан?
Тормышыбыз начарлана,
Иркенчелек бетә бара
Һәм түлибез күбрәк һаман!

Телэнче

Көләч йөзле, матур киемле
Әфәнделәр, гүзәл ханымнар
Кызганмаслар миннән бер тиенне,
Ходай кушып, күзне салырлар.
Бу җырларым бушка китмәсеннәр!
Һәркем тиеш хәер бирергә.
Бар кеше дә бәйрәм иткән көннәр
Бер тук көнем булсын минем дә.

Икенче бер кеше

Иң яхшысы якшәмбе һәм бәйрәм көнне
Гәпләшүе сугышлар турында,
Төркиядә суелыш кырында
Төрле халык ничек кыра берен бере.
Тәрәзәдән карап, касә тоткан көйгә,
Күрә кеше: суда көймә үтеп китә;
Шат кайта ул кичен өйгә,
Тыныч тормыш сөргәненә шөкер итә.

Өченче бер кеше

Дөрес, күрше! Шөбһә тотмыйм моңар һич тә:
Баш өзешсен алар анда,
Бар нәрсәнең асты килсен өскә;
Тик өеңдә элеккечә булсын бар да.

Карчык
(*шәһәр кызларына*)

Әй киенгән болар! Дәртле, яшь кан!
Тилертмәссез нинди йөрәкне? —
Масаймагыз! Сезнең әйбәт заман!
Булдыра алам үзем сезнең бар теләкне!

Шәһәр кызы

Агата, кит! Ачыктан-ачыкка
Иярмик-лә убыр карчыкка!
Дөрес, миңа изге Андрей төнендә[23]
Ул мөмкинлек бирде ярымны белергә.

Икенче кыз

Мә, кара, дип ул миңа бер көзге бирде,
Батыр йөзле бер солдатны күрдем анда;

Шул чагыннан бирле аны эзлим инде,
Очрамый тик ул һич кайда.

Солдатлар

Биек диварлы
Зур ныгытмалар,
Кыю хыяллы
Тәкәббер кызлар —
Баш ия бары!

Хезмәте данлы,
Бүләге — затлы!
Бөтен солдатлар
Омтыла аңар.
Безнең барабан
Яңгырый һаман,
Шатлык булса да,
Үлем куса да.
Менә бу — тормыш!
Давыл бар анда!
Кызлар, калалар —
Бирелсен бар да.

Хезмәте данлы,
Бүләге затлы!
Бөтен солдатлар
Омтыла аңар.

(*Фауст һәм Вагнер*)

Фауст

Бозларыннан елгаларны азат итте
Җан бирүче матур язның шат каравы,
Яшел үлән каплый инде болыннарны,
Кыш бабайның хәле китте,
Ул чигенде, эзләп шыксыз зур тауларны.
Качып барган килеш шуннан ул җибәрә
Өермәсен көчсез бозлы карның
Гөрләп үскән яшел үләннәргә,
Ләкин кояш яратмый ак нәрсә барын,
Тирә-якта бөтен нәрсә дә җанлана,
Матур төскә керә, чуарлана,
Яз, дисәң, чәчәк аланда,
Чуар киенеп халык йөри анда.

Артыңа син бер әйлән дә,
Биектән күз сал шәһәргә.
Аның иске капкасыннан
Агыла халык ташкын сыман.
Һәркем кояш яктысына чыга бүген,
Бөек бәйрәм — Гайса табуттан торган көн.
Үзләре дә чыккан алар табутлардан,
Бик тәбәнәк өйнең тынчу бүлмәсеннән,
Вак һөнәрче карханәсе — тар йортлардан,
Түбәләре баскан чардаклар эченнән,
Җанны изгән тарлыгыннан урамнарның,
Чиркәүләрдә үткәрелгән изге төннән
Алар кояш яктысына килгән.
Кара, кара, халык агла тагын
Бакчаларда һәм киң кырда;
Исәбе юк матур каекларның
Борылып аккан якты суда.
Әнә халык шыгырым тулган
Соңгы көймә үтеп бара,
Ерак тауның сукмагыннан
Чуар кием күзгә чагылып кала.
Ишетәм хәзер авыл шау-шуын да,
Халыкка чын оҗмах — ул шушында,
Картлар, яшьләр бәйрәм шатлыгына талган,
Биредә мин — тагын кеше була алам.

Вагнер

Доктор, сезнең белән йөрү бергә,
Зур бәхет ул һәм файдалы;
Йөрмәс идем ләкин ялгыз мин гомердә,—
Һич яратмыйм шундый тупас уеннарны.
Быргы уйнау, кегль сугу, кычкырулар,
Колагыма һич тә тынычлык бирмиләр,
Җенләнгәндәй, белешмичә, котрынулар —
Шуларны бит күңел ачу, җырлау диләр.

Крестьяннар

(Юкә агачы төбендә бииләр һәм җырлыйлар)

Көтүче купшы киенде,
Шуннан ул биергә килде,
Жакет, билбау шәп иде.

Юкә агачы төбендә
Рәхәт тә соң биергә.
Юхе! Юхе!
Юхейса! Хейса! Хе!
Скрипка дәрт бирде.

Егет атылып килеп керде,
Шунда бер яшь кызны күрде,
Терсәге аңар тиде.
Борылды кызый бер читкә:
Чамадан бик узып китмә,
Юхе! Юхе!
Юхейса! Хейса! Хе!
Әдәпсез булма, диде.

Һәм мәйданга чыкты ул да,
Биеделәр унга, сулга,
Киемнәр очып йөрде.
Икесе дә кызардылар,
Кулдан тотышып бардылар,
Юхе! Юхе!
Юхейса! Хейса! Хе!
Терсәк терсәккә тиде.

Миңа бик туры карама,
Ялам димәсән, алдама! —
Матур кыз шулай диде.
Ялып китте егет аны,
Жыр еракта янгырады:
Юхе! Юхе!
Юхейса! Хейса! Хе!
Скрипка дәрт бирде.

Карт крестьян

Бүген безнең янга килеп,
Доктор, сез яхшы иткәнсез,
Шундый галим, олы кеше,
Безне чит күрми икәнсез.
Тотыгыз касәнең яхшысын,
Яңа эчемлек бар анда,
Бирәм матур теләк белән:
Рәхәт булып китсен җанга,
Һәм санынча тамчыларның
Көнегез күп булсын тагын.

Фауст

Сезгә рәхмәт әйтеп алам,
Шат яшәгез сез дә һаман.
(*Аның янына халык җыела*).

Карт крестьян

Чыннан да бу күңелле хәл,
Бәйрәм көнне дә килдегез,
Элек, хәсрәт көннәрендә
Сез ярдәм бирә идегез.
Мондагы бик күп кешене
Алып калды үләт елны
Сезнең әткәгез, мәрхүмкәй,
Шуңар ул бар көчен куйды.
Ул чакта сез, яшь бер егет,
Авыру янына йөрдегез,
Мәет чыккан бик күп өйдән
Сез исән чыга белдегез.
Ярдәмчегә авыр елда
Ярдәм итте үзе хода.

Барысы да

Галимгә без саулык телибез,
Ярдәм итсен тагын ул, дибез.

Фауст

Тәңрегә дан — ул өйрәтә
Ярдәмгә һәм ярдәм итә.
(*Вагнер белән бергә китеп бара*).

Вагнер

О син, бөек кеше, я әйт әле,
Ни уйладың, шундый хөрмәтне күргәндә,
Бик бәхетле шундый кешеләр, кемнәргә
Файда китерә аларның зур белемнәре!
Берсе сине күрсәтә үз баласына,
Һәммәсе дә синең яныңа сырыша.
Сизденме син җыр һәм уен бүленгәнне?
Тезеләләр сафка, син барганда,
Бүрекләрен чөя барсы да,
Тезләнмиләр чак-чак синең алда,
Әйтерсең, бер изге каршында.

Фауст

Тик берничә адым үргә менгәч тагын,
Бер таш әнә, ял итик без шунда барып,
Еш кына бар анда утырганым,
Руза хәлдә дога укыл, газапланып.
Бай өмет, нык иман белән,
Елап, авыр сулап чын йөрәктән,
Мин сорадым анда бер тәңредән
Коткаруын тизрәк шул үләттән.
Бар мактаулар мыскыл итү төсен ала,
Күрсә идең, минем эчтә утлар яна.
Мәрхүм ата да, улы да
Лаек түгел һич тә мондый данга.
Атам минем хөрмәтле бер надан иде,
Табигатьнең изге, тирән серләренә
Ул үзенчә, тик һәрхәлдә, намус белән
Омтылды, бар кечен бирде.
Ул, адептлар арасында[24]
Кара кухнядан чыкмады,[25]
Мең рецепт язып шунда,
Бутады төрле юк-барны.
Кызыл арслан[26] — батыр кияү тугач, аны
Өйләндерде җылы ваннада Лаләгә,
Һәр икесен кызу ялкында аннары
Күчерде ул бүтән бер бүлмәгә.[27]
Чуар нурлар сибеп балкыды,
Яшь бер Король кызы пыялада,
Дару иде шушы; халык кырыла торды,
Кем терелде? — дип әйтмәде берәү анда.
Тамуг зәһрен тотып шул заманда,
Бу далада һәм тауларда
Котырындык, уздырып без үләттән дә,
Меңнәргә мин үзем агу алып бардым,
Алар үлде, ә мин исән калдым,
Үтерүчегә дан укылсын өчен мәллә?

Вагнер

Ә сез кайгырасыз моңар нигә?
Һәр кешегә шунсы җитмәгәнме —
Кулланса ул үзе белгәннәрне,
Белгәнеңчә дөрес көйгә?
Хөрмәтләп син үзеңнең әткәңне,

Аннан белем алгансың яшь чакта,
Ә олайгач, алга җибәргәнсең фәнне,
Һәм омтылыр улың тагы да зур максатка.

Фауст

О, бәхетле шул кеше, кем нык ышана
Бу ялгышу диңгезендә калмавына.
Нәрсә белми кеше — шунысы кирәк аңа,
Ә белгәне һич тә кирәксезгә була.
Ләкин матур минутларны
Ямьсез уйлар белән агуламыйк әле,
Күр, бизәгән кичке кояшның нурлары
Бар өйләрне яшеллекләр эчендәге.
Батып бара кояш, бер көн үтте тагын,
Ашыга кояш, яңа тормыш көтә анда,
Җирдән күтәрергә булса канатларым,
Очар идем артыннан мин еракларга!
Күрер идем кичке мәңгелек нурларда:
Ята дөнья минем аяк очларымда,
Көмеш чишмә кушыла алтын киң суларга,
Тау башлары балкый, тынлык киң болында.
Туктатырмы аллаларча бер йөрештән
Кыргый тау һәм аның төпсез елгалары?
Менә диңгез, матур аның бухталары,
Таңга калам бу күренештән.
Һәм, ниһаять, алиһә күздән югала,
Ләкин туа яңа омтылышлар,
Мәңгелек нур эчәр өчен ашыгам алга,
Артымда — төн, алда көн бар,
Өстемдә — күк, аста дулкын шаулый.
Матур хыял! Кояш батып житте менә,
Ах! Рухның канатына җиңел генә
Бер кеше дә тән канатын куша алмый.
Була шундый минутлары һәркемнең дә —
Тойгы аны ашкындыра өскә, алга,
Зәңгәр күктә, безнең күздән яшерен генә,
Тургай дәртле җырлаганда;
Туры үскән биек наратлар өстендә
Бөркет канат кагынганда,
Күлләр. далалар өстеннән
Торналар үз илләренә агылганда.

Вагнер

Эч пошкан чак бик еш була ул минем дә,
Мондый теләк туганы юк ләкин бер дә.
Тиз туясың карап кырга, урманнарга,
Мин көнләмим кошның канатларын һич тә,
Ә бөтенләй башка шатлык бирә җанга
Китап уку, томнан томга, биттән биткә.
Кышкы төннәр ямьле, матур була,
Шул бәхетле тормыш тәнгә җылы бирә,
Һәм, ах! Серле пергаментны актарганда,
Күк үзе дә нәкъ яныңа синең инә.

Фауст

Тик бер генә синең белгән теләгең дә.
Өйрәнмә дә башкаларын — нигә алар?
Ике җан бар, аһ! минем бу күкрәгемдә,
Бер-береннән аерылырга омтылалар.
Бирелеп сөю рәхәтенә, аның берсе
Бу дөньяга тамыры белән беркетелгән,
Ашкына бит күккә аның икенчесе —
Бабаларның рухларына җир йөзеннән.
О, һавада булса рухлар, очса алар
Хакимнәрчә җир белән күк арасында,
Илтсәгез лә, төшеп алтын сферадан,
Мине яңа, кызык тормыш дөньясына.
Булсын иде сихри камзул минем,
Илтсен иде мине чит җирләргә, —
Тиңләр идем аны алтын киемнәргә,
Патшаларның хөлләсенә бирмәс идем.

Вагнер

Шул рухларны чакырмачы, зинһар әле,
Шунда, һава серемендә агыла алар,
Меңәр төрле җафалыйлар кешеләрне,
Бөтен яктан безгә куркыныч салалар.
Үткер теше рухлар төньягыннан
Агулы ук итеп батра күкрәгеңә,
Көнчыгыштан аглып коры җилләр сыман,
Туеналар алар синең үпкән белән.
Күндерелсә рухлар көньяк сахралардан,
Баш түбәңә ут өстенә ут өрәләр,
Көнбатыштан — рәхәт салкын булып алдан,
Ә соңыннан сине, кырларны күмәләр.

Тыңлый алар һәлак итү уе белән,
Күндәм алар, чөнки бик оста алдыйлар,
Алар барысы, күктән күндерелгән
Фәрештәдәй, садә сөйләп ялганлыйлар.
Ярый, киттек! Караңгылык куера бара,
Томан төшә, һава салкынлана.
Кичен генә кеше өйнең кадрен белә,
Нәрсә күрдең, гаҗәпләндең алай нигә!
Нәрсә тарта күңелеңне караңгыда?

Фауст

Күрәсеңме, бер кара эт чаба кырда?

Вагнер

Күптән күрәм, ис китәрлек нәрсәсе бар?

Фауст

Ул сиңа ни булып күренә? Ныклап күз сал!

Вагнер

Ни булсын, бер пудель[28] шунда, эзләп бара
Үз хуҗасын—аның эзләреннән.

Фауст

Игътибар ит, якын килә ул һаман да
Безгә таба борылмалы сызык белән.
Ялгышмасам, әнә ут тасмасы
Аның баскан эзләрендә сузылып кала.

Вагнер

Күз алдавы гына болар синдә барсы,
Күреп торам, тик бер кара пудель анда.

Фауст

Ә минемчә, безне чолгап сыза бара
Ул сихерле элмәкләрне, урап йөреп.

Вагнер

Күрәсең ич, куркып сикрә, боргалана,
Үз хуҗасы урнына чит кеше күреп.

Фауст

Тарайды бу түгәрәк, ул безнең янда.

Вагнер

Тик бер эт ул, өрәк түгел, әнә кара!
Өреп куя, бер ята да тагын тора,
Койрык болгый. Һәммә эт тә шундый була.

Фауст

Якынрак кил! Ияр әйдә!

Вагнер

Бу эт барсын аңлый мәллә!
Тик торсаң, ул сине көтә,
Әгәр дәшсәң, килеп җитә;
Нәрсәң төшсә—шуны китерә,
Ташла таяк — суга сикерә.

Фауст

Син бик хаклы, бар да өйрәнүдән генә,
Күрмим монда рухның хәтта мин эзен дә.

Вагнер

Өйрәтелгән булса эт әгәр дә,
Яраталар аны галимнәр дә.
Ошатсаң да хакы бар этнең —
Студентлардан өйрәнгән шәкертнең,

Шәһәр капкасыннан кереп китәләр.

ӨЧЕНЧЕ СЦЕНА

Фаустның кабинеты

Фауст пудель белән бергә килеп керә.

Фауст

Йөреп кайттым кырда, болыннарда,
Төн карасы басты аларны.
Сизеп изге, якты таңны алда
Җанда яхшы хисләр яңарды.
Йокладылар кыргый омтылышлар,
Давыллану — ярсу калмады;
Йөрәгемдә кешене сөю бар
Һәм сөю бар анда алланы.

Җитәр, пудель! йөргәләмә арлы-бирле!
Иснәнәсең бусагада алай нидән?
Мич янында тыныч кына йокла инде,
Баш астыңа мендәр бирәм.
Таулы юлдан кайтып килгән чакта
Сикергәләп, уйнап, ачтың син күңелне,
Хәзер менә миндә кунакта
Тыныч ятсаң яхшы түгелме?

Ах, яңадан минем тар хөҗрәдә
Лампа ямьле нурлар сипкәндә,
Якты булып китә күңелләрдә,
Йөрәк үзен аңлап типкәндә.
Сөйли башлый акылың яңадан,
Чәчәк ата өмет, терелә,
Тормыш ташкынына омтыла җан,
Ах! Тормышның чишмәләренә.

Өрмә, пудель! Хәзер җанны биләп алган
Изге матур җырларны
Бозмасын эт улавы.
Көлеп карау бездә гадәт булып калган
Кеше үзе аңламаган нәрсәләргә.
Яхшылык һәм гүзәллек әгәр дә
Авыр булса, кеше зарлана;
Улыймы эт, ошап аларга?
Тик, ах! инде күпме генә тырышсам да,
Ташымый һич шатлык тагын минем канда.
Кире чикте ташкын бик тиз нигә.
Сусау туды тагын нигә миндә?
Бик еш моны сынаганым бар үземдә.
Һәм менә шул кимчелекне каплау өчен
Без яхшырак дип саныйбыз күкләр көчен,
Омтылабыз вәхи сүзенә.
Ул иң гүзәл балкыган җир—
Безгә мәгълүм: Яңа Инҗил.
Телим укып аны белергә,
Күчерергә хөрмәтләп аннары
Изге оригиналны
Яратканым немец теленә.

(Китапны ачып тәрҗемә итәргә хәзерләнә.)

Монда язган: „Башта Сүз булган!“ дип,[29]
Кем булышыр, ничек моннан ары китик?

Сүзгә һич тә мондый бәһа бирә алмыйм,
Мин башкача күчереп карыйм,
Чын яктылык алсам эчке нурдан.
Язып куям: „Башта Гакыл булган“.
Тик беренче юлны яхшы уйла,
Каләмеңә ашыгырга һич юл куйма!
Бар нәрсә дә әллә акылданмы туган?
Язылырга тиеш ул: „Башта Көч булган!“
Ләкин менә мин шуны язган чагында
Сизәм, кирәк бераз үзгәрту тагын да.
Ярдәм итә рухлар! Дәресен табам шуннан,—
Кыюланып язам мин: „Башта Эш булган!“

Бүлешкәнбез икән бер бүлмәне,
Пудель, алай өрмә әле,
Ташла улауны!
Иптәшем тынгысыз булганны
Яратмыйм мин гомергә.
Калып булмас бергә,
Икебезгә тар бүлмә.
Кунак хакын бозу дисәң дә,
Ишек ачык, чык та кит, әнә!
Ләкин ни күрәм үзем!
Алдамыймы мине күзем?
Әллә чын, әллә күләгә?
Пудель зурая, киңәя,
Ул нинди тиз үсә һаман!
Этка һич тә ошамаган!
Нинди өрәк өйгә килде!
Ул бегемот төсенә керде,
Күзләре ут, ырҗайта теш.
О! Син миңа яхшы таныш.
Мондый ярым җенгә каршы
Сөләйман ачкычы яхшы.[30]

Рухлар

(ишекнең тышында)

Шайтан эләккән анда!
Береӊ дә якын барма!
Читлектәге төлке сыман,
Карт җен нинди юаш булган.
Тик белегез шунысын:
Сугылыгыз бире, ары,
Бер түбән, бер югары.

Ул тизрәк азат булсын.
Файдагыз тисен,
Ул чыгып килсен!
Онытмыйк без аның
Булышкан чакларын.

Фауст

Очрашуны башлыйм моның белән:
Дүртнең ырымын укып карап телдән.

Саламандра[31] янсын,
Ундина таралсын,
Сильфа югалсын,
Кобольд эштә калсын!

Белмичә аларны,
Элементларны,
Көчләрен
Һәм эшләрен,—
Рухларны бер дә
Чакрып та йөрмә!

Югал син ялкында,
Саламандра!
Шаулап ак дулкында,
Ундина!
Балкы метеорда,
Сильфа!
Ярдәм ит йортта,
Incubus, Incubus!
Кил, төзелсен союз!

Дүртнең берсенә
Китми исе дә.
Тыныч ята, миңа ыржая,
Үтмәде бу ырым һич аңа.
Мин сиңа табармын
Көчлерәген тагын.

Дускай, син әллә
Качтыңмы тамугдан?
Күр шушы билгене,
Калтырана аннан
Кара өерләр!

Йонын кабартып, менә ул күпренә.

Нәләтләнгән җан!
Күр, нәрсә язган?
Ул бар ителмәгән,
Сөйләп йөртелмәгән,
Барлык күкләр аша үткән,
Гөнаһсыз газап чиккән.

Эт мич артына чапты,
Кабарынды фил чаклы.
Бар булмәне тутыра,
Әйләним, ди, томанга.
Сикермә, алай котырма,
Хуҗаң сүзен тыңлап, тын ят анда.
Күр, менә мин янавымны үти беләм,
Көйдерермен сине изге ялкын белән.
Көтәсеңме тагын—
Өч кат изге утның яндырганын?
Көтәсеңме тагын—
Иң көчлесен минем ырымнарның?

Томан тарала, мич артыннан узгынчы схоласт[32] *булып киенгән Мефистофель килеп чыга.*

Мефистофель

Ник шауларга, нинди әмре бар хуҗамның?

Фауст

Менә ул кем пудель булып килгән,
Узгынчы бер схоласт! Көлке түгел, димә!

Мефистофель

Сез галимгә бик күп сәлам миннән!
Шактый гына батырдыгыз мине тиргә.

Фауст

Исмең ничек?

Мефистофель

Мондый сорау бик кечкенә
Шул ир өчен, сүзне кем бик түбән саный,
Кызыктырмый тышкы күренеш аны бер дә,
Ул асылның эчке тирәнлеген карый.

Фауст

Аслыгызны була аңлап,
Сезнең исмегезгә карап.
Исемегездән беленә барсы:
Алдакчы, Бозучы, Чебеннәр алласы.[38]
Я, соң син кем?

Мефистофель

Мин шул көчнең бер өлеше,—кайсы яман
Эшләр тели, тик яхшылык эшли һаман.

Фауст

Табышмакның мәгънәсен дә әйтсәң икән!

Мефистофель

Мин шундый рух: бар нәрсәне инкарь итәм.
Һәм хаклымын: бу дөньяда нәрсәләр бар,
Һәммәсе дә җимерелүгә лаек алар.
Һич тумавы, димәк, яхшырак бит, димен,
Бөтенесе, нәрсәне сез гөнаһ дисез,
Җимерү дисез, бу—явызлык дип йөрисез,—
Шулар стихиям минем!

Фауст

Мин бер өлеш, диден, бөтен килеш үзең?

Мефистофель

Дөрес бөтен әйткән сүзем.
Һәр кеше дә, кечкенә бер тинтәк дөнья,
Үзен тулы бер бөтен дип йөрсә шунда,
Мин—өлештән өлеш, башта тик шул булган,—
Караңгылыктан өлеш, нур аннан туган,
Тәкәббер нур, аның бөтен омтылганы—
Кысырыклау читкә хәзер төн ананы.
Булмас ләкин: ашкынса да күпме генә,
Ул җисемгә кереп сеңә.
Җисем аны балкыта һәм матур итә,
Киртә була юлларында,
Җисем белән бергә бик тиздән аның да,
Өмет итәм, һәлак булыр вакыты җитә.

Фауст

Аңлыйм хәзер, синең бик шәп эшең!
Юк итәргә зурны җитми көчен,
Шуңар күрә башлагансың кечкенәдән.

Мефистофель

Һәм күп нәрсә булдырмаганымны беләм!
Үзен Һичнәрсәгә[34] каршы куя
Шул Бернәрсә — өтек дөнья.
Барсын да эшләп карадым,
Тик рәтен табалмадым.
Дулкын, ташкын, зилзилә һәм көчле янгын —
Диңгез һәм җир тыныч хәлгә кайта тагын!
Мәлгун хайван һәм кешеләр өерендә
Эшкә ашмый минем зарар,
Минем кулдан күпме үтте алар,
Яңа, саф кан ләкин ташып тора көн дә.
Эшләр шундый начар, җенләнергә була!
Бер өзлексез һаваларда, җирдә, суда
Агылалар вак орлыклар —
Салкын, җылы, юеш һәм корыда.
Тапмас идем үземә мин бер урын да,
Ярый, миндә элеккедән калган ут бар.

Фауст

Димәк, һәммәсен дә иҗат иткән,
Мәңге тынмас изге бер көчкә
Салкын йодырык күрсәтәсең икән,
Мәгънәсезгә, усал бер төстә.
Бүтән берәр эш уйлап тап
Әй хаосның сәер улы!

Мефистофель

Ярый, уйлашырбыз ныклап
Икенче бер тапкыр моны.
Хәзер китәргә мөмкинме?

Фауст

Мәгънә тапмыйм соравыңда,
Өйрәнәсем килә сине,
Теләгәндә кил тагын да.
Әнә тәрәз, әнә ишек,
Син йөрисең морҗадан да.

Мефистофель

Дөресен әйтсәм, чыгыйм ничек:
Анда, синең бусагаңда
Бер билге бар, бикли юлны.

Фауст

Ошатмыйсың, димәк, пентаграмманы?[35]
Кызык ич бу, тәмуг улы,
Ничек кердең, чыга алмас булгач аны?
Шундый бер җен ничек алданган?

Мефистофель

Ныклап кара! Сызлып бетми калган
Бер почмагы; тора ачылып
Тышкы якка, әнә күрәмсең?

Фауст

Бик шәп очрак монсы, беләмсең!
Калдың, димәк, миндә ябылып!
Көтелмәгән бу хәл бер дә яман түгел.

Мефистофель

Кергән чакта күрми калган моны пудель.
Хәзер инде эшләр начар:
Бүлмәдән җен ничек качар?

Фауст

Тәрәзәдән әнә чык та югал!

Мефистофель

Женнәрдә һәм өрәкләрдә кагыйдә бар:
Кайдан керсәң, шул юл сиңа чыгарга да.
Керсәң — ирек, чыкканда син бер кол гына.

Фауст

Үз законы бар диген, ә, тәмугның да?
Бик яхшы бу, мөмкинме кул куярга да
Килешүгә, һәм сездә шул үтәләме?

Мефистофель

Алырсың мин вәгъдә иткән нәрсәләрне
Тулысынча; алдарлар дип уйлама да.
Ләкин хәзер вакыт бик тар,
Икенче бер сөйләшербез ныклап шуны,
Үтенәм, мине син бу юлы
Җибәрә күр тизрәк, зинһар.

Фауст

Утыр әле бераз гына,
Миңа кызык әкият сөйлә.

Мефистофель

Тотма мине! Тиз килермен, дим, тагын да,
Сорашырсың шунда һәммәсен дә.

Фауст

Әллә чакрып китердемме?
Үзең кердең бит җәтмәгә.
Тоткан кеше, тотсын җенне:
Икенче кат тиз тотармын дип әйтмә дә.

Мефистофель

Бик теләсәң, ярый, мин калырмын,
Сиңа шунда иптәш булырмын,
Тик шарты бар: вакытың алырмын,
Төрле һөнәр күрсәтә торырмын.

Фауст

Ярый, күрсәт, мин күнәмен,
Кызык булсын тик һөнәрең.

Мефистофель

Бер сәгатьтә, дустым, аклың монда,
Ялгыз үткәрелгән нәкъ бер елга
Караганда, күбрәк белер.
Иркә рухларның җырлары,
Матур күренешләрнең бары —
Алар буш бер сихер түгел.
Исне сизү тойгың ләззәт алыр,

Авызында татлы тәмнәр калыр,
Һәм ачылыр синең күңел.
Озак хәзерләп тормабыз,
Без — шушында, әйдә, җырлагыз.

Рухлар

Тонык гөмбәзләр,
Тиз югалыгыз!
Кайгы калмасын,
Назлы карасын
Зәңгәр эфир!
Кара болытлар
Таралсын, бетсен!
Иркә йолдызлар
Яктылык сипсен,
Бар җиргә үтсен!
Күкнең уллары —
Серле юлларны —
Кичеп, аглалар,
Балкып һаман да
Узганда алар,
Чын дәрт тарала.
Җилфердәп үткән
Кием итәге
Каплый җирләрне,
Каплый гөлләрне.
Гөлләр эчендә
Сөю көченә
Яшьләр бирелгән.
Гөлләр иелгән.
Алланып пешкән
Йөзем чаңнарга
Асылынып төшкән,
Сыгып аларда
Шәрап алалар,
Шәраптан ташып,
Бар җирне басып,
Ага елгалар;
Биек таулардан,
Көмеш ярлардан,
Күбекле шәрап
Төшә түбәнгә —
Иркен күлләргә
Яшел аланда.

Кошлар һаман да
Сайрап юана,
Алар юл ала
Кояшка табан
Һәм киң суларда
Әкрен чайкалган
Ямьле утрауга.
Яңгырый анда
Шатлык, дәрт җыры,
Киң — болын буе,
Иректә йөреп,
Гамьсез бииләр,
Уйнашып көлеп.
Кемнәр менәләр
Биек тауларга
Кемнәр йөзәләр
Саф дулкыннарда;
Кемнәр һавада,
Омтыла бар да
Тормышка, күккә,
Йолдызлар яна
Анда, биектә.

Мефистофель

Йоклый, бик шәп! Иркә һава балалары,
Яхшы җырлап оеттыгыз аны.
Концерт өчен сезгә мин зур бурычлымын.
Син женнәрне тотар кеше түгел әле.
Чолгап алсын аны татлы төшләр яме,
Чумсын төпсез хыял диңгезенә.
Хәзер кирәк күсе тешләре
Бусагадагы сихерне кимерергә.
Туры килмәс миңа озак ырымларга,
Берсе инде кыштырдый да минем янда.
Күселәрнең, тычканнарның
Чебен, бака, кандаланың
Алласы мин, әмер бирәм,
Бусаганы кимерергә тешең белән.
Хәзер аңа мин май ягам —
Сикреп килеп җиттең аннан!
Эшкә тотын! Шул почмагын
Азрак кына кимер тагын.
Ярый, шулай мин әйткәнчә, булды бу эш,
Йокла, Фауст, тагын тиздән күрешербез.

Фауст

(Уянып)

Алдандыммы тагын шулай?
Серле матур дөнья уалды,
Шайтанны мин төштә күрдем бугай,
Ә соң пудель кая югалды?

ДҮРТЕНЧЕ СЦЕНА

Фаустның кабинеты

Фауст

Кем ул шакый! Мөмкин! Кемнәр газаплар бу юлы?

Мефистофель

Бу мин.

Фауст

Кер, дим!

Мефистофель

Син кабатла өч кат шуны.

Фауст

Кер, дим!

Мефистофель

Мин ошаттым сине.
Уйлыйм, эшләр җайланыр дип;
Кайгыларың таралыр дип,
Дворян булып килдем бире.
Алтынлаган матур кием —
Барсы атлас, ефәк минем,
Шляпамда әтәч каврые бар,
Кылыч тактым, озын, үткерне.
Киңәш бирәм сиңа, колак сал:
Киен син дә минем шикелле,
Шунда азат, кыю йөрерсең
Һәм тормышның тәмен белерсең.

Фауст

Нинди киемдә дә тояр җаным
Җирдәге тар тормышның газабын,
Мин артык карт тик уенга омтылырга,
Һәм артык яшь һичбер теләксез булырга.
Дөнья миңа нәрсә бирә ала?
„Тыйнак бул син! Тыйнак һаман да!“
Мәңгелек җыр бит менә шул,
Һәр колакта яңгырый ул,
Гомер буе айлар, еллар
Карлыкканчы шуны җырлыйлар.
Уянам мин куркып иртә белән,
Кайнар яшьләр күземнән бөркелә,
Үтеп китәр бу көн тагын һәм мин беләм,
Бер теләкне үтәмәс ул, тик берне дә;
Төрле усал гайбәт белән кадерсезләр
Ашкынуның бар шатлыгын, ямен аның,
Тормыш шыксызлыгы белән ул ямьсезләр,
Гүзәллекне иҗат итсә минем җаным.
Һәм тиешмен, төн килгәчтен, мин яңадан
Курка-курка баш куярга мендәремә,
Тынычлык юк миңа һаман,
Кот очарлык саташам мин төшләремдә.
Күкрәгемдә урын алган алла
Эчтән мине тирән дулкыннарга салган,
Көчләремә ул үз хөкмен йөртә ала,
Юл бирә алмый тик аларга тышка табан.
Шулай, тормыш минем өчен бер йөк кенә,
Дөнья—ямьсез, котылырмын, үлеп кенә,

Мефистофель

Бик кадерле кунак түгел тик үлем дә.

Фауст

О, бәхетле шундый кеше, зур җиңүләр
Җиткәч, кемгә әҗәл канлы лавр бирә,
Һәм, давылдай узганнан соң шат биюләр,
Матур кызның кочагында аңар килә.
О, мин дә, дим, бөек рух килгән чагында
Шатлыгымнан җансыз ауган булсам җиргә!

Мефистофель

Ә шулай да теге төнне, таң алдында,
Берәү кире куйды эчемлекне нигә?

Фауст

Яратасың, күрәм, шпион булырга.

Мефистофель

Барсын белмим, беләм күп нәрсә турында.

Фауст

Таныш җырлар тартып алды мине
Куркынычлы упкын ярыннан,
Шат көннәрнең яңгырашы килде,
Алдадылар бала чагымнан
Калган хисләр, — нәләт һәммәсенә,
Алдакчы, буш, татлы хыялга,
Бәйләгән ул сукыр бер көч белән
Җанымны шул зарлы дөньяга!
Нәләт сиңа масаю зурлыгы,
Рухны син нык чолгап аласың!
Нәләт сиңа, күренеш сукырлыгы,[36]
Син зиһенгә кереп каласың!
Нәләт гасырларда яшәр данга —
Дан турында күргән төшеңә!
Нәләт, милек безне алдаганга —
Хатын, сабан һәм кол төсендә!
Нәләт сиңа, Маммон,[37] бай хәзинәң
Илтә безне кыю эшләргә,
Мәгънәсез ял, йомшак мендәр белән
Юатасың озын кичләрдә!
Нәләт төшсен йөзем бәлзәменә!
Саф сөюгә нәләт тагын да!
Нәләт сезгә, өмет, иман — бергә,
Һәм барыннан элек — сабырга!

Рухлар хоры

Хәсрәт! Хәсрәт!
Син ваттың аны,
Матур дөньяны
Көчле йодрык белән;
Китте ул йөз түбән!
Җимерде аны ярым тәңре!
Илтик әле
Җимерекләрне юклык төбенә,
Түгелә күз яшьләре,
Гүзәллек югалганга күрә,

Иң кодрәтлесе
Җир улларының,
Тагы да ямьлесен
Төз син дөньяның,
Төз аны син үз күкрәгеңдә!
Якты аң белә
Башла тормышның
Яңа адымын,
Ишетерсең тагын
Бәхет, дәрт җырын!

Мефистофель

Минем угланнар
Килеп тулганнар,
Эшкә өндиләр,
Күңелең ач, диләр.
Ялгыз, тар җирдә
Көч, акыл шиңә.
Алар чакыра
Сине яктыга.

Сагыш белән уйнавыңны ташласана,
Тилгән күк ул, чукый сине бар гомреңә;
Тиз сизәрсең, кемнәр янына барсаң да,
Башкалардай син дә тик бер кеше генә.
Хәер, моны дөрес аңла,
Начарларга якын килмә.
Бик зурлардан түгел мин дә,
Ләкин, теләсәң, һәркайда
Озатырмын бу тормышта сине һаман,
Һич тә синнән калмам,
Иптәш күрерсең,
Рәхәт йөрерсең.
Уйла, риза бул,
Мин хезмәтче сиңа, тугры кол!

Фауст

Ни бирергә тиешле мин каршысына?

Мефистофель

Әле вакыт күп ансына.

Фауст

Юк, Юк! Беләм, бик эгоист һәрбер шайтан,
Тәңре өчен көтү мөмкин түгел аннан
Файдалы эш бер тамчы да.
Шартларыңны ачык сөйлә,
Синдәй хадим хәвеф китерә өйгә.

Мефистофель

Бу дөньяда мин булырмын хезмәтеңдә,
Үтәрмен бар теләгеңне, ял да белмәм;
Очрашканнан соң яңадан без тегендә,
Син дә миңа кайтарырсың шуның белән.

Фауст

Теге дөнья борчымый ул мине бер дә,
Кирәк элек бу дөньяны җимерергә,
Аннан соң бар булыр башка дөнья.
Шушы җирдән ташып чыга шатлыкларым,
Шушы кояш күрә газапларын җанның;
Аерылыйм, дим, элек шунсыннан,
Теләсә ни булсын соңыннан.
Белергә дә теләмим мин ул дөньяда
Нәкъ шундый ук мәхәббәт һәм нәфрәт барын,
Һәм ышанмыйм бер дә, анда
Бар Югары, Түбәне дә бар дип тагын.

Мефистофель

Алай булса, тәвәккәллә шуның белән,
Сүз куешыйк: бик тиз көннән
Син күрерсең минем һөнәрләрне
Мин бирермен сиңа һичкем күрмәгәнне.

Фауст

Ни бирерсең син мескен җен?
Биек күккә ашкан рухын бер кешенең
Синдәйләр һич аңлый белмәс!
Аш бар синдә, тик ул туклык бирмәс,
Алтының бар, озак йөрмәс,
Терекөмеш төсле һич тә кулда тормас,
Уеныңнан берәүгә дә отыш булмас.
Ә кыз балаң кочагымда
Ымлап ята күзе белән бер күршегә.

Илаһи бер ашкыныйммы дан алырга?
Метеор төсле юк була дан бик тиз генә.
Өзү белән черер, әгәр бирсәң җимеш,
Агачларың һәр көн бүтән төскә керер.

Мефистофель

Болар миңа бик җиңел эш,
Мондый хәзинәне сиңа бирә алам,
Тик, дускаем, шундый вакыт бик тиз килер,
Тынычлыкта син татырсың тәмлерәк тә.

Фауст

Тынычланып, башны куйсам мин түшәккә,
Шунда мине бетте, дип бел!
Макта, алда мине, җитсә көчең,
Үземне үзем яратырлык булсын,
Хәйләлә син, ләззәт, ямь тап минем өчен,
Шулай соңгы көнем тусын!
Бәхәсләшик!

Мефистофель

Бик шәп!

Фауст

Ярый, кул сугылсын!
Мин әйтермен кайчан бер лахзага:
Үтеп китмә! Шундый матур син!—
Шунда мөмкин мине зынҗырларга,
Шунда, димәк, һәлак булдым мин!
Яңгырасын шунда әҗәл чаңы,
Хезмәтеңнең булсын беткәне,
Йөрмәс булсын сәгать шуннан ары,
Шунда булсын гомрем үткәне.

Мефистофель

Яхшы уйла! Истә торыр бар да.

Фауст

Моңар хакың бик бар синең.
Өстән үлчи бу, дип уйлама да.
Сүзне бозмам, булырмын кол, димен,
Сиңа яки, барыбер, башкаларга.

Мефистофель

Доктор, синең аш вакытыңда инде бүген
Хезмәтемне башлап китәм.
Дөнья хәлен ләкин белә алмый беркем;
Бер-ике юл язу синнән өмет итәм.

Фауст

Нинди педант! Язу телисеңме?
Кешене һәм аның сүзен белмисеңме?
Бик җиткән ич минем әйткән сүзем, аңла,
Мәңге хуҗа шул сүз минем бар көннәргә,
Ял белмичә, тормыш һаман ташый алга,
Вәгъдәм мине тотып торыр мәллә?
Шул ялгыш уй сеңгән безнең канга,
Котыла ала кем анардан?
Саф вөҗданлы кеше бәхет таба,
Ул курыкмый корбаннардан.
Тик пергамент,— имза, мөһер булса анда,—
Бер өрәк ул, һәммә кеше курка аннан.
Каләмдә үк инде сүз үлә,
Бар көч күчә балавызга, күнгә.[38]
Явыз рух, син үзең сайлап ал:
Кәгазь, мәрмәр, бакыр, пергамент бар.
Грифельме, каләм, өтергеме,—
Нәрсә белән языйм — иркеңдә.
Я, әйтеп бир, кайсын телисең.

Мефистофель

Күп сөйләргә ничек иренмисең,
Я, барысын да сөйләп бетерденме?
Яз теләсәң нәрсәгә, бик ярый бар да,
Тиеш ләкин каның белән кул куярга.

Фауст

Кызык күрсәң бик шуңарда,
Ырымлый бир, табыйм күңелеңне.

Мефистофель

Кан бөтенләй башка бер нәрсә ул.

Фауст

Тик курыкма, бу союзны һич бозмамын.
Хәзер нәрсә вәгъдә итсәм, чыннан да шул —

Бөтен көчем белән минем омтылганым.
Кәпрәйдем бик, белмим, нидән,
Чынында мин сиңа тиңмен.
Бөек рух тик көлде миннән,
Табигатьне бикле күрдем,
Фикерләүнең җебе өзелеп калды,
Бөтен фәннәр күңелне кайтарды.
Нечкә ләззәтләргә күмелсеннәр
Утлы дәртләр, сүнеп, һәммәсе дә!
Һәм, төренеп сихер пәрдәсенә,
Могъҗизалар күренсеннәр!
Без йөрербез заман шау-шуында,
Очракларның күкрәп ташуында!
Әрнүләр һәм рәхәтләр,
Уңышлар һәм михнәтләр
Теләгәнчә алмашынып торсын,
Тик, ял белми, кеше эштә булсын!

Мефистофель

Сиңа чик һәм киртә куелмаган,
Ни яратсаң, таты барысын,
Очкан җиреннән дә эләктер кайсын,
Теләкләрең үтәлерләр һаман.
Тик миңа әйт һәм үзең дә юаш булма.

Фауст

Шатлык димә, бел, сүз бармый һич ул турыда.
Мин бирелә́м иң әрнеткеч ләззәткә дә,
Сафландыргыч ачу, иркә нәфрәткә дә.
Белем кысымыннан азат күкрәгемдә
Һәрбер төрле зар-әрнүгә урын булсын,
Кешелекнең бөтен кичергәннәре дә —
Һәммәсе дә минем канда ташып торсын.
Белсен рухым иң биекне, иң түбәнне,
Алар биргән шатлыкны һәм әрнүләрне,
Минем асылым шулар белән берексен дә,
Иң ахырда алар юкка чыксын бергә!

Мефистофель

Ышан миңа: узды еллар күп меңнәрчә,—
Һаман каткан сынык чәйним,
Һичбер кеше бишегеннән кабергәчә,
Сеңдермәде ачы, иске камырны, дим.

Ышан миңа: бар дөньялар
Тик бер алла өчен яралган;
Мәңге якты, рәхәт аңар,
Ә безгә — тик караңгылык кына калган,
Сезгә — көннәр, төннәр алмашына һаман.

Фауст

Ә мин телим!

Мефистофель

Гаҗәп түгел бер дә!
Ләкин мине шундый борчу били:
Гомер кыска, сәнгать озын нинди.
Мөмкинме бер киңәш бирергә:
Берләшегез яхшы шагыйрь белән,
Уйларында күккә очсын ул,
Кемдә нинди яхшы сыйфат күргән—
Барысын бергә синдә кушсын ул,
Боланның елдамлыгын,
Арыслан батырлыгын,
Итальянның кайнар канын
Һәм намусын төньягының.
Өйрәнсен ул бөтен серләрне дә,
Бөек дәртне мәкер белән кушсын бергә,
План төзеп сезне гашыйк итсен.
Йөрәк яшьлек дәрте белән типсен,
Шундый таныш әгәр булса минем,
Микрокосм[39] исемен бирер идем.

Фауст

Мин кем соң, дим, ахырында,
Кешелекнең таҗын бер кимәгәч,
Теләгәнем булды, димәгәч?

Мефистофель

Син кем булсаң—һаман тик шул гына.
Миллион бөдрәле парик киеп ал да,
Бас син озын агач аякларга,—
Син кем булсаң—һаман тик шул гына.

Фауст

Сизәм хәзер, юкка гына туплаганмын
Бөтен белем хәзинәсен кешеләрнең.

Үземә бер сынап күзне салсам тагын,
Күрәм, эчтә яңа көчләрнең беткәнен.
Чәч бөртеге киңлеге дә үсә алмадым,
Мәңгелеккә шул кадәр дә якынаймадым.

Мефистофель

Бар нәрсәгә син карыйсың, дустым минем,
Карагандай аңар нәкъ башкалар;
Тик без бераз акыллырак эшлик, димен,
Бу тормышта күпме шатлыклар бар!
Чәнчелгере! Кулың һәм аягың,
Башың һәм артың—синеке!
Тик нәрсәдән ләззәт мин аламын,
Алар һәммәсе—минеке!
Сатып алсам алты юрга,
Үз көчләрен миңа бирә алар.
Давыл төсле чыгам юлга,
Әйтерсең лә, егерме дүрт аягым бар.
Тизрәк әйдә, уйлануны ташла,
Дөньяга чык, рәхәт яши башла!
Бел син: берәү тирән уйда булса һаман,
Нәкъ хайван ул, үлән кипкән бер яланда
Явыз рухлар аны әйләндереп алган,
Яшел болын җәелеп ята тирә-янда.

Фауст

Я, нәрсәдән башлыйк?

Мефистофель

Әйдә киттек юлга,
Шул төрмәндә һәлак булма!
Тормышыңның юк бит бер яме дә,
Азаплыйсың үзеңне дә, яшьләрне дә,
Күршең корсагына калдыр барысын,
Салам турап юкка җафаланма,
Иң яхшысын белсәң, ансын
Әйтмәссең бит балаларга.
Кемдер берәү бар ишектә.

Фауст

Күрәсем дә килми һичбер кемне.

Мефистофель

Юанып китсен ничек тә,
Мескен күптән көтә инде.
Бар кит, плащ һәм бүркеңне миңа калдыр,
Битлек матурайтыр мине

(Киенә.)

Үткер акылым бераз уйнап алыр.
Миңа кирәк барысы чирек сәгать кенә,
Ә син юлга хәзерлән бик әйбәт кенә.

Фауст китә.

Мефистофель

(Фаустның озын киемен кигән)

Нәфрәт ит син акылга һәм белемнәргә,—
Кешедәге иң югары шул көчләргә,—
Әгәр алдау рухына син ирек бирсәң,
Сихер белән көч арттырсын миңа дисәң,—
Син минеке шул чагында.
Язмыш биргән шундый кыю бер рух аңар,
Сөя бәйсез мәңге алга талпынырга,
Анда чиксез ашкыну бар,
Кирәк түгел аңар җирнең шатлыгы да.
Илтермен мин шаулы тормыш аша аны,
Илтермен сай һәм вак мәгънәсезлек аша,
Таңга калыр, комсызланыр анын җаны,
Һәм ул, мәңге туймаса да,
Эзләр һаман татлы шәрап, тәгамнарны,
Сусыннары канмас тик бөртек тә.
Хәтта сайлап алмаса да ул шайтанны,
Барыбер китәр иде төпкә.

(Шәкерт керә.)

Шәкерт

Күптән түгел мин биредә,
Һәм яныгызга килергә
Җөрьәт иттем, сезне илдә
Һәркем мактап ала телгә.

Мефистофель

Сез әдәпле, монсы күңелле бик,
Мин дә башкалардай бер кеше тик.
Ниләр укыганыгыз бар?

Шәкерт

Үзегезгә алыгыз мине, зинһар.
Зур дәрт белән укырга дип килдем,
Саулыгым шәп, акчам да бар минем.
Җибәрергә әнкәм теләмәгән иде,
Гыйлем эстәү омтылышы җиңде мине.

Мефистофель

Алайса сез килеп чыккан нәкъ җиренә.

Шәкерт

Дөресен әйтсәм, китәр идем мин кире дә:
Бу диварлар һәм бу заллар
Һич ошамый миңа алар.
Нинди тар бер ямьсез бүлмә,
Утыр шунда, агач күрмә, гөлләр күрмә,
Шушы залда, урындыкта
Күрү, ишетү һәм фикерләү чыгар юкка.

Мефистофель

Иләшүгә карый бар да.
Ана имчәген дә элек
Бик үк теләп алмый бала,—
Соңра имә, тәмен белеп.
Һәм сезгә дә хәкимлекнең күкрәгендә
Күңеллерәк була барыр көннән көнгә.

Шәкерт

Шат булырмын асылынырга муенына,
Нидән башлыйм, әйтсәгезче шул турыда.

Мефистофель

Элек шунсын белү кирәк тик,
Сезгә ошый кайсы факультет?

Шәкерт

Мин телим чын галим булырга
Һәм белергә шунын турында:

Җирдә, күктә нәрсәләр бар,
Табигать, фән нәрсә алар?

Мефистофель

Сез бик дөрес юл алгансыз,
Ләкин юк-бар белән чуалмагыз.

Шәкерт

Тырышырмын җан-тән белән.
Ләкин җәйге бәйрәм көнендә
Рөхсәт булыр миңа, дип беләм,
Бераз күңел ачып йөрергә.

Мефистофель

Вакыт кадрен белү кирәк, ул тиз үтә,
Аннан файдалану өчен тәртип җитә.
Димәк, дустым, сезгә минем киңәшем шул:
Башта кирәк Collegium Logicum,[40] ул
Рухны яхшы авызлыклый белә,
Испан итеген[41] аңар һәйбәтләп кидерә,—
Өйрәнсен ул саграк, дип, тагын да
Фикер юлларында үрмәләп барырга,
Ары-бире бәрелмәсен,
Юкка саташып йөрмәсен.
Өйрәтерләр көннәр буе сезне аннан:
„Бер, ике, өч!“ командасы кирәк һаман
Ашау-эчү кебек ачык бер эштә дә,—
Элеккечә берсен дә ансат эшләмә.
Фикер фабрикасын тиңләштерәм
Туку станогы белән,
Меңнәрчә җеп йөри анда,
Шүре аска-өскә атыла,
Җепләр күренмичә агыла,
Меңләп төен төйнәлә тик бер сукканда.
Бер философ килеп керә,
Ул барысын да исбат итә белә:
Беренчесе болай, икенчесе болай,
Шунар күрә өч һәм дүртенчесе шулай,
Беренче һәм икенчесе булмаганда,
Өченче һәм дүртенчесен уйлама да.
Бөтен шәкерт шуны һаман мактап сөйли,
Тик берсе дә чын тукучы була белми.
Терек затны язар өчен, серен белеп,
Юк итәргә тырышалар рухын элек.

Өлешләре аның кулда бар да,
Ләкин рух бәйләнеше юк аларда.
Encheiresin naturae[12]—ди химия сүзе;
Ул үзеннән көлә, шуны сизми үзе.

Шәкерт

Аңлап бетерә алмадым мин монын барысын.

Мефистофель

Тиз вакыттан аңлый башларсыз һәркайсын,
Редукцияне[13] ләкин өйрәнегез,
Һәм классификацияне шәп белегез.

Шәкерт

Башым нинди авырта башлады,—
Әйләнгәндәй анда тегермән ташлары.

Мефистофель

Шуннан соң сез бүтәнне ташларсыз,
Метафизиканы өйрәнә башларсыз.
Анда шундый тирән фикерләр бар,
Хәтта кеше миенә дә сыймый алар.
Сыямы ул әллә юкмы мигә,
Бизәкле сүз хезмәтеңә килә.
Тик башта бер ярты еллап
Тәртип өйрәнегез чынлап,
Һәр көнне биш дәрескә сез
Бер минут та кичекмәгез.
Алдан хәзерләп килегез,
Һәрбер җөмләсен белегез,
Шул чак хәлфәңнең сүзләре ачык булыр:
Китапта юк берәр нәрсә әйтмиме ул;
Бик тырышып язып барыгыз һәр сүзне,
Нәкъ изге рух имла яздыргандай үзе.

Шәкерт

Монсын бер кат әйтү җитәрдер, дип беләм!
Яхшы аңлыйм, моңарда бар бик зур файда:
Нәрсә язса кеше акка кара белән,
Аны өйгә тыныч алып кайта ала.

Мефистофель

Я, сайлагыз бер факультет.

Шәкерт

Хокук фәнен өйрәнергә теләмимдә.

Мефистофель

Моның өчен сүгә алмыйм сезне мин дә.
Ул фәннең ни икәнлеген мин аңлыйм бит.
Хокук, закон мирас булып кала,
Мәңгелек бер авыру сыман,
Буыннардан буыннарга бара,
Төрле якка җәелә бер урыннан,
Чынны ялган, акны кара ясый белә.
Хәсрәт сиңа—оныќ булганга!
Безнең белән бергә туган хокук кайда?—
Вавәйла, бу сорауны тик бирми кем дә.

Шәкерт

Тагы да ныграк бу фән төште күздән.
О, зур бәхет белем алу сездән!
Ничек булыр, бирелсәм мин дин гыйльменә?

Мефистофель

Ялгыш уйга салмас идем сезне бер дә.
Монсы аның шундый бер фән,
Кыен булыр саклануы ялгыш юлдан,
Бик күп агу анда яшеренгән,—
Чак-чак кына аерырсың дарулардан.
Иң яхшысы—тик бер остаздан укыгыз
Һәм аның сүзен тотыгыз.
Гомумән, сез тотынгыз һаман сүзгә!
Шунда ишек ачылыр сезгә
Белемнең киң мәгъбәденә.

Шәкерт

Сүз булырга тиеш ләкин мәгънәле дә.

Мефистофель

Яхшы! Ләкин кирәкми һич борчылырга,
Житми икән мәгънә, ул урынга
Берәр сүзне шунда ук табалар.
Сүзләр белән диспут уздыралар,
Сүзләр белән хәзерләнә системалар.
Һәркем тиеш сүзгә чиксез ышанырга,
Тартып алып булмый сүздән йотаны да.

Шәкерт

Гафу үтенәм, сезгә бик күп сорау бирдем,
Ләкин тагын борчыйм әле.
Әничек соң медицина фәне,—
Шул турыда сездән бер сүз ишетер идем.
Өч ел бит ул бик аз заман,
Һәм, я ходa! бик киң мәйдан.
Бармак белән күрсәтсәләр юлны,
Барган төсле тоела алга табан.

Мефистофель

(үз-үзенә)

Коры тоннан күңелем туйды,
Җен булыймчы мин яңадан.

(Кычкырып)

Медицина рухын аңлау бигрәк җиңел;
Зур, вак дөнья, укый торгач, беленер бар да
Ләкин алар һаман бара бирер—
Ничек тели алла.
Фән дип канат кагыну анысы нигә тагы,
Өйрәнәләр, кулдан нәрсә килсә, шуңар,
Тотып ала белсә кемнәр бер лахзаны,
Бу дөньяда җиңә шулар.
Буй-сын начар түгел сездә,
Кыюлык та җитәрлек бар,
Ышаныгыз үзегезгә,
Башкалар да ышанырлар.
Өйрәнегез хатын-кызларга ярарга,
Һәм мәңгелек ох-ахларын,
Мең төрен аның,
Бер ноктадан дәваларга.
Намусыгыз җитсә ярты юлга,
Алар барсы сезнең кулда.
Титул да тиз ышанырга мәҗбүр итә
Сезнең белем күп белемнән өстенлеккә,
Шуннан сезгә җиде рәхәт килер бергә,
Бүтән берәү аны еллар буе көтә.
Белегез сез пульсне дә, санап,
Ялкынлы һәм наян күзләр белән карап,
Аның нечкә билләрендә йөртегез кул,
Белер өчен, тыгыз бәйләнмәгәнме ул.

Шәкерт

Монысы шәбрәк! Кайда ни бар — күренеп тора.

Мефистофель

Теория ул, дустым, һаман соры була,
Тормыш дигән алтын агач яшел һаман.

Шәкерт

Төш күрәмен хәзер дип ант итә алам.
Рөхсәт булса, әле тагын бер килермен
Сез хәкимнән тагын сабак алыр өчен.

Мефистофель

Кулдан килгәнен бирермен.

Шәкерт

Болай гына китәргә, юк, җитми көчем.
Шул альбомны сезгә тәкъдим итәм,
Мәрхәмәттән берәр сүз язсагыз икән.

Мефистофель

Бик шатланып.

(Язып, альбомны кире бирә)

Шәкерт

(укый)

Eritis sicut Deus, scientes bonum et malum.[44]

(Хөрмәт белән яба һәм сәламләп чыгып китә.)

Мефистофель

Шул мәкальгә—елан апам сүзенә—егет колак салыр.
Һәм бик тиздән аллаларга ошавыннан мәхрүм калыр.

Фауст

(керә)

Кая киттек?

Мефистофель

Кая син телисең.
Кечкенә һәм зур дөньяларны күрерсең,
Бу курсны күңелле үтәрсең
Һәм күп кенә файда итәрсең.

Фауст

Мин бу озын сакал белән
Һич тә җиңел яши белмәм.
Сынау барып чыкмас сыман,
Киң дөньяны мин ятсынам.
Бүтәннәрдән гүя кечкенә мин,
Бу тартыну гомергә барыр, дим.

Мефистофель

Кадерле дус, барсын да тиз өйрәнерсең,
Үзеңә ышан,—матур яши дә белерсең.

Фауст

Ярый, ничек юл алабыз?
Кайда атың, хезмәтчең һәм файтон кайда?

Мефистофель

Плащымны җәеп салабыз.
Ул очыртыр безне һаваларда.
Чыккан чакта кыю юлга,
Зур төеннәр алма кулга.
Утлы һава хәзерләрмен бик аз гына,
Безне җирдән күтәрер ул ансат кына.
Җиңел булсак, тиз очырыр һава безне,
Хәзер яңа тормыш белән котлыйм сезне!

БИШЕНЧЕ СЦЕНА

Лейпцигта Ауэрбах базы[45]

Шат күңелле егетләр цехы

Фрош

Һичкем эчми, һичкем көлми дә?
Йөз сытмагыз алай биредә!
Утырмагыз ошап чи саламга,
Ялкын төсле кирәк янарга.

Брандер

Гаеп синдә, күренми ич бер дә
Тилелек тә, синең этлегең дә.

Фрош

(*аның башына шәрап коя*)

Икесе дә!

Брандер

Икеләтә эт бит үзең!

Фрош

Булсын, дидем, әйткән сүзең!

Зибель

Талашканнар чыгып китсен!
Жырлап эчик, тамак карылып бетсен!
Әй! һолла! һо!

Альтмайер

Нәләт төшкән, бетердең лә!
Колагымны ерттың, мамык бармы кемдә?

Зибель

Түшәм селкенгәндә генә
Басның көче ачык беленә.

Фрош

Булды! Ишек ачык яратмаганнарга!
А! Тара, лара, да!

Альтмайер

А! Тара, лара, да!

Фрош

Тиз җайланды тамаклар да!

(*Жырлый.*)

Изге Рим империясе,
Күптән инде җимерелсәңче!

Брандер

Әшәке җыр! Тьфү! Политика анда!
Көлке бер җыр! Тәңрегә шөкер итегез,
Рим дәүләтен кайгыртасыбыз юк, дигез.
Ичмаса, дим, шунсына шат минем күңелем,
Император яки канцлер түгелмен.

Тик шулай да безгә бер баш булсын иде,
Ягез, папа сайлыйк инде.[46]
Сайландымы кеше, сез беләсез,
Күтәреләбашлый, шөбһәсез.

Фрош

(*җырлый*)

Сандугачкай, сайра янында—
Ун мең сәлам сөйгән ярыма.

Зибель

Бер сәлам юк! Ишетергә теләмим дә.

Фрош

Сәламлә, үп! Ә син миңа каршы килмә!

(*Җырлый*)

Йозак, ачыл! Тын төндә,
Ачыл! Төн үтсен бергә!
Йозак, бикләнбикләнТаң белән.

Зибель

Җырла, әйдә, җырла, макта, төче теллән!
Рәхәтләнеп бер көлә‌рмен, вакыты килер,
Утыртты ул мине бик шәп, син дә тилер.
Сөяркәсе булып аңар Кобольд килсен,
Шаярсыннар теләгәнчә юл чатында!
Кәҗә тәкәсе: „Хәерле төннәр!" дисен,
Блоксбергтан[47] чабып кайткан чагында.
Кайнар канлы, таза тәнле егет аңар
Эләкми торса да бик ярар.
Тәрәзәсен чәлпәрәмә китерермен,
Менә шулай аңа сәламне бирермен!

Брандер

(*өстәлгә сугып*)

Житәр! Житәр! Әй, тыңлагыз!
Сезгә мәгълүм, мин бит яши беләм.
Ничә гашыйк монда җыелгансыз,
Сыйлыйм бер, риза булсагыз,
Төнгә каршы иң яхшы сый белән.
Кызык җыр бу, яңа көйгә!
Җырлагыз, я, сез дә бергә!

(*Җырлый*)

Булган, ди, базда бер күсе,
Майда йөзгән ул һаман.
Һәм, нәкъ доктор Лютер төсле,
Корсак үстергән яман.
Кухарка аңа агу куйган,
Дөнья бөтен ямен җуйган,
Эчтә гүя гыйшык уты.

Хор

(*ашкынып*)

Эчтә гүя гыйшык уты.

Брандер

Ары һәм бире йөгергән,
Һәр пычрактан су эчкән,
Бөтен нәрсәне кимергән,
Күңелсез хәлгә төшкән.
Онытылган, ди, бар рәхәте,
Җиткән, ди, соңгы сәгате.
Эчтә гүя гыйшык уты.

Хор

Эчтә гүя гыйшык уты.

Брандер

Йөгереп өйгә килеп кергән,
Көпә-көндез, куркынып,
Бик кызганыч мышный биргән,
Мич янына утырып.
Кухарка кычкырып көлгән:
Сызгырына соң бу нидән,
Эчтә бардыр гыйшык уты.

Хор

Эчтә бардыр гыйшык уты.

Зибель

Мондый кызык—егетләр эшеме!
Бик зур һөнәрме бу әллә
Агулавы бичара күсене?

Брандер

Син дус, ахыры, күселәргә?

Альтмайер

Башы пеләш, корсак май гына!
Йөрәк йомшак андый кешедә.
Ошатырга мөмкин аны да
Шул күбенгән мескен күсегә.

Фауст һәм Мефистофель керәләр.

Мефистофель

Сине, дускай, барыннан да элек
Китердем шат җиргә, белеп.
Күр син, алар җиңел гомер сөрә,
Бәйрәм итә монда алар көн дә.
Үткерлек аз, шатлык мул гына.
Бии алар, кызганмыйлар көчне,
Койрык белән шаярган бер мәче төсле.
Баш авыртса, кайгы шул гына.
Трактирчы бурычка биргәндә,
Борчылмыйлар алар бернигә дә.

Брандер

Юлдан килгән болар әле генә,
Сәер кыланышларыннан шул беленә;
Әле бер сәгать узмаган.

Фрош

Чыннан шулай! Лейпцигны мактый алам.
Кечкенә бер Париж, агарта кемне дә.

Зибель

Синеңчә, бу юлчылар кем?

Фрош

Үземә куш! Касәләрне тутырып салам,
Бар серләрен сөйләтермен,
Сөйләткәндәй сабыйларны, мин алардан.
Вак халыктан түгелдер үзләре,
Усал, эре карана күзләре.

Брандер

Әллә инде базар шарлатаннары!

Альтмайер

Мөмкин.

Фрош

Бәйләнәм аларга.

Мефистофель

Сизмәс җен барын арада,
Тотсам да мин якасыннан аны.

Фауст

Сәлам сезгә, әфәнделәр!

Зибель

Бик зур рәхмәт!

(*Мефистофельгә яннан карап, әкрен генә*)

Бер аякка аксый зәхмәт![48]

Мефистофель

Рөхсәт бармы утырырга сезнең янга?
Яхшы шәрап табып булмаган чакларда
Яхшы гәп тә шатлык бирә җанга.

Альтмайер

Сез ошыйсыз иркә кунакларга.

Фрош

Риппахтан[49] сез чыккан ахры соң гына?
Кичке ашта тиле Ганс бар идеме?

Мефистофель

Бүген килдек туры монда,
Үткән юлы күргән иде үзе мине.
Туганнары турында да ул белдерде,
Барсына да бик күп сәламнәр күндерде.

(*Фрошка карап башын ия.*)

Альтмайер

(*әкрен*)

Алдың! Күр, ул нишли?

Зибель

Акылы бар.

Фрош

Күрсәтәм мин хәзер аңар!

Мефистофель

Без бая ишеттек төсле
Бик матур хор жырлаганын,
Түшәм биек булса, жырның көчле
Яңгырашы була аның.

Фрош

Сез үзегез жырчымы әллә?

Мефистофель

Һич юк! Көч аз, теләк бик зур әмма.

Альтмайер

Бер жырлагыз!

Мефистофель

Меңне, әгәр теләсәгез.

Зибель

Өр-яңасын ләкин, сайлагыз.

Мефистофель

Испаниядән кайтып барабыз,
Яхшы шәрап, жырлар иле ул, беләсез.

(Жырлый)

Кайчандыр бер король торган,
Борчасы булган аның.

Фрош

Ишетәсезме? Борча булган! Уйланыгыз!
Борча безнең иң кадерле кунагыбыз.

Мефистофель

(жырлый)

Кайчандыр бер король торган.
Борчасы булган аның,
Борчаны ул сөя булган,
Әйтерсең, үз угланын.
Тегүчене чакырткан да,
Әйткән, ди, король аңар:
Киемнәр тек шул борчама,
Тек син бер яхшы чалбар.

Фрош

Тегүчегә алдан әйтсеннәр барын да'
Дөрес итеп кисә күрсен,
Башы бетәр, ачык белсен,
Җыерчыклар калса әгәр чалбарында.

Мефистофель

Атлас һәм ефәк киемнән
Йөргән, ди, борча һаман,
Бик күп төрле тасма элгән
Һәм тәре тагып алган.
Министр булган аннары,
Зур бер йолдыз биргәннәр,
Һәм аның бар туганнары
Дәрәҗәгә менгәннәр.
Сарайда ире, ханымы
Барсы да газапланган,
Хәтта корольнең хатыны
Тәмам аптырап калган.
Кашынырга ярамаган,
Борча тик тешли бирсен,
Ә без кашынабыз һаман,
Сытабыз тоткан берсен.

Хор

(шатлыклы ашкынып)

Ә без кашынабыз һаман,
Сытабыз тоткан берсен.

Фрош

Bravo! Bravo! Яхшы бигрәк.

Зибель

Борчаларга шулай кирәк!

Брандер

Тырнакка ал, торма карап!

Альтмайер

Яшә, ирек! Яшә, шәрап!

Мефистофель

Эчәр идем мин дә, хөрмәтләп ирекне,
Әгәр сездә яхшы шәрап булса иде.

Зибель

Икенче кат сөйләмәгез шуны инде.

Мефистофель

Килешмәс, дим, хуҗабыз алдында,
Юкса, газиз кунакларым, сезгә
Яхшы шәрап табылыр иде бездә.

Зибель

Бик шәп! Рәтлим мин барын да.

Фрош

Яхшы шәрап булса, сезгә дан диербез,
Татып карар өчен мул бирегез,
Авыз тутырып эчсәң генә,
Шәрап тәмнәре беленә.

Альтмайер

(*әкрен*)

Уйлавымча, Рейннан килгән алар.

Мефистофель

Борау бирегез![50]

Брандер

Нәрсәгә соң тагын анысы?
Әллә тышта анда мичкәгез бар?

Альтмайер

Әнә, хуҗа кәрзиндә табылыр барсы.

Мефистофель

(*кулына борау алып Фрошка*)

Я, әйтегез, телисез сез нindине?

Фрош

Ник сорыйсыз? Әллә бармы төрлеләре?

Мефистофель

Һәркемгә дә булыр үзе теләгәне.

Альтмайер

(*Фрошка*)

Әһә! Ялый башладың да син иренеңне!

Фрош

Алайса, мин рейнвейн сайлап алам,
Иң яхшысын ватанда мин табам һаман.

Мефистофель

(*өстәлнең Фрош утырган читен бораулап*)

Бөке яса син, балавыз табып ал да.

Альтмайер

Фокус кына болар бар да.

Мефистофель

(*Брандерга*)

Сезгә?

Брандер

Мина шампанский булсын,
Күбекләнеп, ташып торсын!

Мефистофель бораулый; берәү, балавыздан бөкеләр ясап, тишекләрне каплый.

Брандер

Читләрдән дә һаман качарга ярамый,
Яхшы нәрсә еракта да үсә.
Чын немец һич французны күрә алмый,
Тик шәрабын теләп эчә.

Зибель

(*Мефистофель аның янына килгәч*)

Дөресен әйтсәм, ачы шәрап яратмыйм мин,
Салыгыз миңа бер стакан иң татлыдан!

Мефистофель

(*бораулый*)

Сезгә токай агар шуннан.

Альтмайер

Юк, егетләр, карагыз, дим!
Күрәм, ул бит безне мыскыл итеп көлә.

Мефистофель

Әй! Әй! Соң куркыныч түгел кемгә
Мыскыл итү шундый кунакларны?
Тизрәк! Йоклап калмагыз тагы!
Сезгә нинди не салырга?

Альтмайер

Бар да ярый! Сорау нигә аны?

(Бөтенесенә дә тишкәннән һәм бөке тыкканнан соң)

Мефистофель

(әкәмәт гримасалар ясап)

Йөзем ботагының йөземе бар,
Кәҗә тәкәсенең мөгезе бар.
Ботак агач, аннан шәрап тама,
Агач өстәл үзе шәрап бирә ала.
Табигать ул тирән, үлчәгез,
Могҗиза бар анда, белсәгез!
Эчегез хәзер, бөкеләрен алыгыз да!

Барсы да

(бөкеләрне алалар, һәркемнең стаканына үзе сораган шәрап ага.)

Нинди матур чишмә ага барыбызга!

Мефистофель

Агызмагыз читкә тамчысын да!

Барсы да кабат эчәләр.

Барсы да

(җырлыйлар)

Әйтерсең, без—каннибаллар,[51]
Биш йөз дуңгыз рәхәте бар.

Мефистофель

Ирек алды халык, кара, кыланганын!

Фауст

Инде моннан китүне мин артык күрәм.

Мефистофель

Тукта, бөтен хайванлыклары боларның
Ачылсын бар матурлыгы белән.

Зибель

саксыз эчә; шәрап, җиргә түгелеп, ялкынга әйләнә.

Янам! Ярдәм! Тәмуг уты ул!

Мефистофель
(*ялкынны ырымлап*)

Стихия дустым, тыныч бул!
(*Егетләргә*)

Бу юлга тик тәмугдан бер тамчы гына.

Зибель

Нәрсә? Тукта, җавап бирерсең барсына!
Безне әле белмисең шул.

Фрош

Тагын бер кат безне алдалап карасын!

Альтмайер

Минемчә, ул китсен инде үз юлына.

Зибель

Әйт син безгә туры гына,
Нигә монда фокус белән чуаласың?

Мефистофель

Тик тор, мичкә!

Зибель

Ах, себерке!
Бик теләсәң — йодрык та бар.

Брандер

Ансы яңгыр төсле явар!
(*Альтмайер өстәлдән бөкене чыгара, аннан ут атылып чыга.*)

Альтмайер

Янам, янам!

Зибель

Сихер бары!
Законнан тыш бер мәлгун ул! Үтер аны!

Хәнҗәрләрен чыгарып, Мефистофельгә ташланалар.

Мефистофель

(*эре кыяфәт белән*)

Күренеш ялган, сүз ялган[52] —
Уй һәм урын алданган,
Монда булма, кит аннан!

Барсы да туктап, гаҗәпләнеп, бер-берсенә карап торалар.

Альтмайер

Мин кайда соң? Нинди гүзәллек!

Фрош

Йөзем үсә! Чынмы?

Зибель

Кулны суз — өзәрлек!

Брандер

Куаклары нинди матур үскән!
Йөземнәре нинди яхшы пешкән!

Зибельнең борыныннан тота. Башкалар да бер-берсе белән шуны ук эшлиләр һәм хәнҗәрләрен күтәрәләр.

Мефистофель

(*баягыча*)

Ялган пәрдә күздән тиз югалсын!
Җеннең ничек шаярганы истә калсын!

Фауст белән бергә юк була. Егетләр бер-берсен җибәрәләр.

Зибель

Нәрсә булды?

Альтмайер

Ничек?

Фрош

Синең борын?

Брандер

(Зибельгә)

Ә бит синең борыныңда минем кулым!

Альтмайер

Каты сукты нинди, китте бар тамырга!
Урындык бир бераз хәл алырга!

Фрош

Юк, әйтегез, нинди хәлләр?

Зибель

Кайда үзе? Күрсәм тагын,
Исән калмас иде мәгәр!

Альтмайер

Күреп калдым үзем чыкканын[53]
Шул ишектән мичкә өстендә.
Аякларга гүя таш тутырган.

(Өстәлгә таба әйләнеп)

Күрәм, шәрап инде акмас булган.

Зибель

Күзне алдау! Дөрес түгел һичберсе дә.

Фрош

Миңа калса, шәрап эчтем шикелле дә.

Брандер

Ә соң йөзем куаклары кайда?

Альтмайер

Могҗизага ышанмыйм, дип әйтеп кара!

АЛТЫНЧЫ СЦЕНА

Убыр карчыгының кухнясы

Тәбәнәк бер учакта ут өстендә зур казан тора. Аннан күтәрелгән бу эчендә төрле шәүләләр күренә. Казан янында утырган ана маймыл[54] аны болгаткалый һәм ташымасын дип карап тора. Ата маймыл һәм баламаймыллар шунда жылынып утыралар. Түшәм һәм стеналар убыр карчыгының әкәмәт җиһазлары белән бизәлгән.

Фауст һәм Мефистофель

Фауст

Сихер эшен һич яратмыйм мин күрергә,
Ә син мөмкин дисең терелергә
Шунда миңа бар әрнүдән?
Киңәш сорыйммы мин бу карчыктан?
Киметерме үзенең даруы белән
Бер утыз яшь миңа синең корткаң?
Хәсрәт миңа, белмисең шул син бүтәнне!
Өмет мине алдалады.
Көчле рух һәм киң табигать үзе әле
Бүтән һичбер бәлзәм таба алмаганмы?

Мефистофель

Дустым, акыллы син бүген тагы!
Яшәрергә бар табигый яхшы чара;
Ләкин бүтән бер китаптан эзлә аны
Һәм бик сәер бүлегеннән кара.

Фауст

Әйт, нәрсә ул!

Мефистофель

Яхшы чара, докторның да
Кирәге юк, акчаның да, сихернең дә:
Чыгып кит син хәзердән үк кырга,
Җирне казы, тырмала, чәч, эшлә көн дә.
Үзеңне һәм акылыңны тот
Бөтенләй тар чикләрнең эчендә,
Яшь талымлау нәрсә — аны белмә,
Хайван төсле яшә хайван арасында,

Үз кырыңны тиресләргә дә иренмә —
Шул иң яхшы чарасы да —
Сиксән яшькә яшәрергә иң кимендә.

Фауст

Өйрәнмәгән мин моңар, юк, булмас миннән,
Кулга көрәк тотып йөрмәм,
Юк, тар тормыш ятмый минем күңелемә.

Мефистофель

Шуңар күрә убыр карчык кирәк менә.

Фауст

Әйт, соң карчык нигә кирәк инде?
Даруны бит син кайнатсаң була аны!

Мефистофель

Вакытны бу шәп үткәрү булыр иде!
Юк, мең күпер салырмын мин,[55] яхшырагы.
Җитми монда осталык һәм белем генә,
Түземлек тә кирәк шуның белән бергә.
Тын бер рух еллар буе шөгыльләнә,
Көчне бирә вакыт кына һәр чүпрәгә.
Моңар кирәк нәрсәләр дә,
Алар бигрәк гаҗәп бары,
Җен һәммәсен өйрәтсә дә,
Ясый алмый үзе аны.

(*Хайваннарга күрсәтеп*)

Күрче — сөйкемле хайваннар!
Монда хезмәтчеләр алар.

(*Хайваннарга*)

Карчык кайда, күрмим аны.

Хайваннар

Аш ашап, тагы
Морҗа аркылы
Тышка атылды.

Мефистофель

Озак очамы ул һаман?

Хайваннар

Җылынганчы безнең табан.

Мефистофель

(*Фаустка*)

Бик матурлар бит, чыннан да?

Фауст

Шулардан да шыксыз тагын ни бар!

Мефистофель

Юк, юк, нинди кызык сөйли алар,
Яратам мин моны артык барыннан да.

(*Хайваннарга*)

Бик тырышып болгатканың нәрсә ансы? —
Сорыйм сездән—шәйтан курчакларыннан!

Хайваннар

Кайнатабыз хәерче шулпасы.[56]

Мефистофель

Публика да бүген бик күп булыр, чыннан.

Ата маймыл

(*Мефистофель янына килеп, аңар иркәләнә*)

Минем беләи бер уйна,
Байлык бир минем кулга,
Отыйм мин уенда.
Эшләрем начардан,
Мөмкин бит акчадан
Акыллы булырга.

Мефистофель

Бик зур бәхет булыр иде маймылларга,
Өйрәнсәләр лото уйнарга.

(*Шул арада бала маймыллар, зур бер туп белән уйнап, аны алга тәгәрәтәләр.*)

Ата маймыл

Менә бу—дөнья,
Түнә һәм тора,
Әйләнә һаман.

Чыңлый пыяла,
Бик тиз уала,
Эче буш калган.
Ялтырый анда,
Аннары монда.
Мин исән, балам!
Кадерле улым,
Тимәсен кулың,
Юкса, бетәрсең!
Балчыгын шуның
Миңгә түләрсең.

Мефистофель

Бу нинди иләк?

Ата маймыл

(*иләкне ала*)

Бу иләк кирәк[57]
Каракны белергә.

(*Ана маймыл янына йөгерә һәм аңар карарга иләк бирә.*)

Бер карап ал,
Каракны белеп кал,
Исемен әйтмә беркемгә!

Мефистофель

(*ут янына килеп*)

Бу чүлмәк нинди?

Ата һәм ана маймыллар

Шуны да белми!
Шыр тиле йөри,
Белми казанны!

Мефистофель

Тупас хайваннар!

Ата маймыл

Мә, себерке ал!
Утыр аннары!

(*Мефистофельне урындыкка утырырга мәҗбүр итә.*)

Фауст

(*Шул вакыт эчендә, бер еракрак китеп, бер якынрак килеп, күзге алдында басып торганнан соң*)
Нәрсә күрәм? Нинди күк гүзәле[58]
Күренә миңа серле бу көзгедә?
О, мәхәббәт канат бир дә син, тиз генә
Шул гүзәлгә мине илт әле!
Ях, калмыйм мин монда, ничек түзәр җаным,
Мөмкин булсын иде янына барырга,
Ә мин күрәм аны хыял томанында,
Иң матурын матурларның.
Мөмкиндерме шундый бер сылу булырга?
Шул кечкенә гәүдә үзенә җыйган икән
Күк серләрен һәм аларның бар нурын да,
Бу могҗиза җирдә микән?

Мефистофель

Бик табигый: нәкъ алты көн үзе хода[59]
Эшләгән һәм: „Яхшы булды!“ дигән шунда.
Дөрестән дә, рәтле генә нәрсә туган.
Туйганчы бер кара син көзгегә.
Табып бирү аны килә минем кулдан,
Бәхетле шул кеше, язмыш кемгә
Ул матурны кәләш итеп куйган.

Фауст һаман көзгегә карый, Мефистофель урындыкта киерелә һәм, себерке белән уйнап, сүзендә дәвам итә.

Тәхеттәге король төсле утырам монда,
Скипетр[60] кулда, җитми бер таҗ гына.

Хайваннар

(*үзара төрле әкәмәт хәрәкәтләр ясаудан туктап, каты кычкырып, Мефистофельгә таҗ китерәләр*)

Рәхим итеп ал,
Тир бар һәм кан бар —
Ябыштырырга.

(*Алар, саксыз күтәреп, таҗны ярулар һәм, аның ватыкларын тотып, сикеренгәләп әйләнәләр*)

Беттең, таралдың,
Күрәбез барын,
Салабыз җырга.

Фауст

(*көзге алдында*)

Ах! акылымнан язам мәллә?

Мефистофель

(*хайваннарга күрсәтеп*)

Минем баш та тәмам чуала.

Хайваннар

Бәхет көлгәндә,
Туры килгәндә,[61]
Туа уйлар да.

Фауст

(*баягыча*)

Тизрәк кирәк моннан китәргә! —
Йөрәккәем дөрләп яна!

Мефистофель

(*элекке хәлендә*)

Туры килә икърар итәргә:
Чын шагыйрь бу хайваннар да.

Маймыллар ташлап киткәч, казан ташый башлый; аннан зур ялкын күтәрелеп, морҗа аркылы чыгып китә. Убыр карчык коточкыч кычкырып, ялкын аша түбәнгә төшә.

Убыр карчыгы.

Ай! Ай! Ай! Ай!
Дуңгыз нәрсә! Нәләт төшкере!
Казан ташый, битне пешерде!
Торма шунда!

(*Фауст белән Мефистофельне күреп*)

Ни бар монда?
Кем бар монда?
Нәрсә кирәк?
Ник сез бездә?
Битегезгә
Ялкын сезгә!

(*Кашыкны казанга батырып ала да, Фаустка, Мефистофельгә һәм хайваннарга ут сибә. Хайваннар чыелдыйлар.*)

Мефистофель

(*Себерке сабы белән савыт-сабаны вата.*)

Ват икегә!
Бутка көя!
Мә, кирәксә,
Ал, эләксә,
Карт уләксә, —
Синең көйгә!

Убыр карчыгы ярсып һәм куркынып, артка чигенә.

Таныдыңмы? Карт карачкы! Коры сөяк!
Әфәндеңне һәм хуҗаңны таныдыңмы?
Бер сугуда көл итәргә күпме кирәк
Үзеңне, бар маймылыңны!
Кызыл камзулыма хөрмәт беттеме, дим?
Әтәч каурыйларын танымадың?
Капламадым ич битне мин!
Исемемне атаргамы әллә тагын?

Убыр карчыгы

Кичерелсен, хуҗам, тупас каршылавым,
Күрмим сездә ат тоягын,
Ике козгын кая киткән?[62]

Мефистофель

Ярый, бер юлга кичерәм,
Күрешкәнгә безнең синең белән
Инде шактый вакыт үткән.
Культура бит һаман алга бара,
Җенгә дә ул үзенең эзен сала.
Төньяк өрәк хәзер күзгә күренми дә,
Һәм күрмисең мөгез, койрык, тырнак миндә.
Дөрес ансы, кирәк миңа ат тоягы,
Ләкин алай йөрсәң, уңайсыз кешедән,
Бик күп яшьләр төсле, алмаштырдым аны
Мин дә фәлше аяк белән.

Убыр карчыгы

Зиһенем җуям, шашам инде!
Шайтан тагын миңа килде!

Мефистофель

Исмем белән әйтмә мине.

Убыр карчыгы

Нигә? Нәрсә була аннан?

Мефистофель

Мәсәлләргә кергән бу сүз күптән инде,
Тик кешеләр аңар карап яхшырмаган,
Явыз рухны сүгеп, явыз килеш калган.
Барон дип син ата мине, яхшырагы,
Мин кавалер, бүтән кавалерлар кебек;
Шикләнмә һич, миндә барон каны,
Мөһерне дә, кара, йөртәм белеп.

(*Әдәпсез хәрәкәт ясый.*)

Убыр карчыгы

(*чамасыз шаркылдап*)

Ха! ха! Монысы нәкъ сезнеңчә!
Сез бик шаян, элеккечә!

Мефистофель

(*Фаустка*)

Дустым, кара, син дә өйрән:
Шулай кирәк эш йөртергә убыр белән.

Убыр карчыгы

Боерык көтәм әфәнделәремнән.

Мефистофель

Касәң тутыр теге дару белән.
Булсын ләкин иң искесе,
Шунсы аның иң көчлесе.

Убыр карчыгы

Ярый, бик шәп! Бар бер гаҗәп шешәм,
Үзем дә мин кайчак шуннан эчәм.
Беткән хәзер начар исе,
Салып бирүдән эш калмас.

(*Мефистофельгә әкрен*)

Хәзерлексез эчсә аны тик бу кеше,
Сез беләсез, бер сәгать тә яши алмас.

Мефистофель

Яхшы дус ул, файда гына итәр аннан.
Мин телимен, даруның иң әгъласен тап.
Сызык сызып ырымнарыңны эшләп бак
Һәм бир тутырып бер тустаган!

Убыр карчыгы, әкәмәт хәрәкәтләр ясап, түгәрәк сызык сыза һәм түгәрәк эченә төрле сәер нәрсәләр куя, шул арада стаканнар чыңлый һәм казан гүли башлый, шулай итеп, музыка килеп чыга. Иң ахырда убыр карчыгы зур бер китап китерә, маймылларны сызык эченә кертә һәм китапны бер маймылның аркасына куя, ә бүтән маймыллар факеллар тотып торалар. Убыр карчыгы, ымлап, Фаустны чакыра.

Фауст

(*Мефистофельгә*)

Юк, әйт миңа, нәрсә болар?
Шашкан төсле кыланалар,
Иң мәгънәсез, тозсыз ялган,
Таныйм, җирәнәм мин аннан.

Мефистофель

Бар да уен гына! Утыр көлеп!
Юкка алай артык ачуланма!
Ясасын ул фокус, доктор кебек,
Һәм китерсен сиңа ныграк файда.

(*Фаустны сызыкка кертә.*)

Убыр карчыгы

(*бик зур күтәренкелек белән, китаптан карап, декламация сөйли*)

Белсәң җиңел бит,
Берне син ун ит.
Икене ташлап кит.
Өчне тезеп ал,
Шулай баеп кал.
Дүртне читкә сал,
Биш һәм алтыны,
ди, убыр карчыгы,

Җиде, сигез ит,
Ахрына килеп җит.
Тугыз — тик бер ул,
Ә ун — ноль булыр,
Өйрәтә шәп тапкырларга убыр.[63]

Фауст

Тотынды бу, ахры, саташырга.

Мефистофель

Бу тик әле аның башы гына,
Нәкъ шундый ул китап бөтенесе,
Укып әрәм китте вакытым гына.
Бер фикеренә капма-каршы берсе,
Аңлый алмас ахмак та һәм акыллы да.
Дустым, сәнгать иске һәм бик яңа,
Шулай килгән борын заманнардан:
Өчне бер дип, берне өч дип анда[64]
Чын урынына ялган ныгып калган.
Өйрәтәләр, бик акыллы кыланалар,
Кем теләсен ахмакларга бәйләнергә?
Ишетү белән һәрбер сүзгә ышаналар,
Мәгънәсен дә уйлап карау ник юк бер дә?

Убыр карчыгы

(*дәвам итә*)

Фәннең бар эше,
Аның зур көче
Яшерен бөтен дөньяга.
Ул бүләк шуңа,
Кем гамьсез була,
Һәм кем бик аз уйлана.

Фауст

Нәрсә лыгырдый ул анда?
Башым чатный шундый көчле.
Йөз мең ахмак җыелган да,
Хор белән сөйләнә төсле.

Мефистофель

Җитәр, җитәр сиңа, акыллы Сивилла,[65]
Эчемлекне тизрәк китер монда.

Тулсын касәң, кырыена җиткереп сал,
Дускаема бер зыян да булмас моннан,
Күп баскычны инде ул уздырган
Һәм аның шәп эчкәне бар.

Убыр карчыгы, бик күп церемонияләр ясап, касәгә эчемлек сала; Фауст аны авызына китергәч, җиңелчә ялкын чыга.

Мефистофель

Тиз эч! Калмасын төбендә!
Рәхәт булыр, бел, артыннан.
Син хәзер „син" дисең җенгә,
Куркасыңмы шул ялкыннан?

(*Убыр карчыгы сызыкны ача. Фауст чыга.*)

Мефистофель

Киттек! Ярамый калырга!

Убыр карчыгы

Эчкәнең зур шифа бирсен!

Мефистофель
(*убыр карчыгына*)

Йомышың төшсә әгәр, яныма
Вальпургиядә килерсең.

Убыр карчыгы

Менә бер җыр! Кайчак җырласагыз аны,
Эчкәнегез күбрәк файда итәр тагы.

Мефистофель
(*Фаустка*)

Әйдә, тиз йөр, миңа ияр дә!
Сиңа кирәк ныклап тирләргә.
Аның көче үтсен тышка, үтсен эчкә.
Эшсез рәхәт сөрү кадрен син белерсең,
Тиздән тирән ләззәт белән сизенерсең
Купидонның сикеренгәнен синең эчтә.

Фауст

Тукта, тик бер шул көзгегә карыйм тагын!
Ул сын нинди матур иде!

Мефистофель

Юк, юк! Тиздән иң гүзәлен хатыннарның
Үзең күрәчәксең инде.

(*Әкрен.*)

Бик шәп эчтең, файдасы да тиз беленер,
Һәрбер хатын нәкъ Елена булып күренер.

ҖИДЕНЧЕ СЦЕНА

Урам

Фауст, Маргарита үтеп баралар.

Фауст

Матур туташ! Биреп кулымны,
Озатырга мөмкин булырмы?

Маргарита

Матур туташ түгел шул мин,[66]
Озатмый да кайтырмын, дим.

(*Кулын ычкындыра да китеп бара.*)

Фауст

Күкләр шаһит, гүзәл бала!
Бирдер ул тик бу дөньяда.
Акыллы да, инсафлы да,
Үзе тагын чая гына.
Ирене кызыл, битләре ут,
Мәңге аны онытасым юк!
Күзен түбән төшерде дә,
Кереп калды күңелемә.
Ничек җавап бирде үзе,
Сокландыргыч һәрбер сүзе!

Мефистофель килеп керә.

Фауст

Табып бир син миңа хәзер шуны!

Мефистофель

Кемне?

Фауст

Яңа узып китте моннан.

Мефистофель

Ул кыз әле генә попта булды,
Арынды бар гөнаһыннан.
Мин күзәтеп тордым якыннан.
Гөнаһсыз ул, бер дә юкка
Барган булган шунда попка, —
Минем көчем җитми аңар.[67]

Фауст

Инде аңар ундүрт яшь бар.

Мефистофель

Азгын Ганс төсле син сөйлисең,[68]
Матур чәчәкләрнең бөтенесен
Ул үзенә тели, намус белми,
Күргән берсен өзеп йөри,
Син дә андый юлга кермә.

Фауст

Хөрмәтле магистр, бер дә
Сөйләмә син вәгазь, үзем беләм,
Әйтәм сиңа кыска гына:
Шул назлы кыз кочагыма
Керми икән бүген, тыңла,
Ярты төндә аерылабыз синең белән.

Мефистофель

Мин нишлим соң, уйлап кара,
Ундүрт көнләп вакыт ала
Сылтау эзләү үзе генә.

Фауст

Булса җиде сәгать вакытым минем,
Үзем аны аулый белер идем,
Чакырмас идем җенне дә.

Мефистофель

Француз кебек син сөйлисең.
Үтенәм синнән, һич тә ачуланма,
Бердән ләззәт табып соң ни файда?
Кызыксыз бу, син белмисең.
Элек аны үзеңә карат,

Тегеләй, болай бераз шаярт,
Күңелен тап, китапларда
Язылганча булсын бар да.

Фауст

Аппетитым болай да бар.

Мефистофель

Ярый, калсын шаярулар.
Андый сылу кыз баланы
Бик тиз алып булмый аны.
Һич мәгънә юк штурмда,
Хәйлә табу кирәк монда.

Фауст

Берәр әйбер китер аннан,
Илт янына, үзем барам,
Кулъяулыгын китер аның,
Сөеклемнең оек бавын.

Мефистофель

Син күрерсең, синең өчен
Һич кызганыч түгел көчем.
Вакытыбыз монда бушка үтмәсен лә
Илтәм сине бүген аның бүлмәсенә.

Фауст

Ул минеке булыр?

Мефистофель

Түгел!

Ул бер күрше хатынга керер.
Ә син ялгыз гына шунда
Килер шатлыгыңны уйла,
Аның һавасын син сула.

Фауст

Киттекме?

Мефистофель

Юк, әле иртә.

Фауст

Бер бүләк тап син ничек тә!

(*Китә.*)

Мефистофель

Бүләк! Бик шәп! Эшләр уңа!
Бай хәзинәләр күмелгән[69]
Әйбәт урыннарны беләм,
Барып килим хәзер шунда.

(*Китә.*)

СИГЕЗЕНЧЕ СЦЕНА

Кич

Кечкенә һәм пөхтә бер бүлмә. Маргарита чәч толымнарын үреп бәйли.

Маргарита

Ул кем? Тик шуны белергә
Мин риза бик күп бирергә.
Кыю карый үзе бигрәк,
Бер зур кеше булса кирәк.
Маңгаеннан моны укып күрәм —
Үзен тота ничек намус белән.

(*Китә.*)

Мефистофель һәм Фауст

Мефистофель

Тиз генә кер, тавышланма!

Фауст

(*бераз тик торганнан соң*)

Ә син бар кит, калыйм ялгыз!

Мефистофель

(*бүлмәгә күз йөртеп*)

Пөхтә булмый болай һәр кыз!

(*Чыгып китә.*)

Фауст

(*тирә-ягына карашып*)

Сәлам сиңа, назлы шәфакъ нуры,
Котлыйм сине шушы изге җирдә!
Йөрәккә кер, татлы гыйшык моңы,

Өмет чыгы сиңа азык бирә!
Тирә-якта тынлык хөкем сөрә,
Сизелә тәртип, дуслык-татулык!
Ярлылык та байлык булып күренә,
Тар бүлмәдә нинди матурлык!

(*Кровать янындагы күн креслога утыра.*)

Бабаларның тәхте, мине кочакка ал,
Зар, бәхеттә аларны да алган кебек!
Күпме тапкыр, ах! шатланып, шук балалар
Сарылганнар әйләнәңә, чыр-чу килеп.
Иркәләнеп бабасының кочагында
Ёлка өчен рәхмәт укыгандыр назлым,
Тулы битле, гамьсез бала ул чагында.
О, гүзәл кыз, рухын сизәм аның,
Төгәллек һәм тәртип рухы җырлый,
Кабатлый ул анаң төсле көн дә,—
Ак ашъяулык булсын өстәлеңдә,
Ә идәндә чиста ком шыштырдый.
Җитез кулы алиһәмнең,
Булдыра алыр күкләр ямен.
Ә бу!

(*Кроватьның өске җәймәсен күтәрә.*)

Татлы курку чолгый бөтен тәнне!
Китмәс идем ич мәңге дә.
Табигать, син назлагансың төшләрендә
Шул бүлмәдә фәрештәмне.
Шунда сабый җылы сулыш алган,
Иркә күкрәк күтәрелгән,
Шунда гүзәл алиһә яралган
Изге һәм саф бер көч белән.
Ә син? Монда соң син нигә килдең?
Һичкайчан да болай дулкынланмый идем!
Ни телисең? Күңелеңә авыр нигә?
Мескен Фауст! Сине таный алмыйм мин дә.
Әллә монда сихер чолгап ала?
Ләззәткә дип ашкынса да җаным
Инде сөю хыялына талдым!
Әллә очрып уйный безне һава?
Бүлмәгә ул килеп керсә иде,
Кызартырлар иде әдәпсез уйларың!
Нинди кечкенә син, олы тиле![70]
Егылыр идең аягына аның.

Мефистофель
(*керә*)

Тиз бул, кит! Ул кайтып килә.

Фауст

Киттек! Мәңге кире кайтмам.

Мефистофель

Монысы булыр менә бүләк тартмаң,
Алдым аны мин бер җирдә.
Шкафында калдыр аңар,
Күргәч, акылыннан язар.
Анда шундый шәп нәрсә бар,
Шиксез, нинди кыз да азар.
Уен — һаман уен, бала — һаман бала.

Фауст

Ярар микән алай?

Мефистофель

Ансын сорама да!
Калдырмакчы булдыңмы әллә үзең өчен?
Киңәш бирәм — комсызланма,
Вакыт кадрен яхшы аңла,
Һәм әрәмгә тотылмасын минем көчем.
Сине саный алмас идем мин саранга!
Синең өчен башны кашыйм, кулда сөял.
(*Тартманы шкафка куеп, аны яңадан бикли.*)
Киттек тизрәк!
Кыз балада кайнар йөрәк,
Сине уйлар, синең өчен көяр.
Нигә син бик чытык йөзле,
Нәкъ дәрескә баргандагы төсле,
Күз алдында басып тормый микән
Физикаң һәм метафизикаң?
Тизрәк!

Китәләр.
Кулына лампа тотып Маргарита килеп керә.

Маргарита

Нинди бөркү, авыр һава![71]

(*Тәрәзә ача.*)

Ә бит тышта эссе түгел бер дә.
Йөрәк нигәдер сызлана,

Кайтсын иде тизрәк әнкәм генә.
Бөтен тәнне курку чолгап ала,
Куркак, тиле була ул кыз бала!

(*Чишенгәндә җырлый башлый.*)

Бер король булган Фулэдә,[72]
Хатынын өзелеп сөйгән,
Аңар хатыны, үлгәндә,
Саф алтын касә биргән.

Бик кадерле касә булгач,
Король гел шуннан эчкән,
Эчкән чакта, күңеле тулгач,
Күздән яшь тамып төшкән.

Шәһәрләрен бүлеп биргән,
Король, үләр алдыннан;
Варисларым, алыгыз, дигән,
Тик касәне калдырган.

Мәҗлес җыйган зур сарайда
Тирән диңгез янында,
Рыцарьлары булган анда,
Бабаларның залында.

Король урныннан торган да,
Изге касәне тоткан
Һәм, эчкән дә, дулкыннарга
Аны ерак ыргыткан.

Король күзәткән барсын да —
Касә ничек батканын;
Артык эчмәгән тамчы да,
Күзе йомылган аның.

(*Киемнәрен элеп куяр өчен шкафны ача һәм анда бизәкле тартманы күрә.*)

Матур тартма монда кайдан килгән?
Шкаф бикле калган иде миннән.
Бик гаҗәп хәл! Анда ни бар, белсәм икән!
Берәү залог итеп бәлки китергәндер,
Әнкәм акча биреп торсын өчен аңар.
Әллә ачып карыйммы бер,
Бауга элгән ачкычы бар!

Тәңрем! Ни бу! Кара, зинһар!
Күргәнем юк бит гомердә.
Оят булмас, бай ханымнар
Кисә моны бәйрәм көндә.
Килешерме миңа муенсасы?
Кем байлыгы икән болар барысы?

(*Киенеп көзге каршына бара.*)

Булсын иде миңа алкалары!
Үзгәрдем мин хәзер бигрәк!
Яшь, матур булып ни файда?
Дөрес, бик яхшы болар да,
Ләкин бизәнү дә кирәк!
Кызганудан гына мактый безне алар.
Алтынга сырыша,
Баерга тырыша
Бар да. Ах, без ярлылар!

ТУГЫЗЫНЧЫ СЦЕНА

Ял итеп йөргәндә

Фауст, уйга талып, ары-бире йөренә. Аның янына Мефистофель килә.

Мефистофель

Мәхәббәткә нәләт төшсен! Гуаһ итәм тәмуг көчен,
Таба алмыйм сүзләрен мин тагы да яман сүгенер өчен!

Фауст

Ни бар? Кемнәр чеметәләр?
Мондый йөзне күргәнем юк гомеремдә.

Мефистофель

Бирелер идем хәзер, шиксез, мин бер җенгә,
Җен булмасам үзем әгәр!

Фауст

Берәр зарар килдеме әллә акылыңа?
Килешә сиңа тиле төсле котырынырга!

Мефистофель

Гретхенга дигән бүләк, уйлап кара,
Поп кулына эләгеп кала! —
Ана карчык, тартманы бер күрү белән,

Курка башлый күңеленнән:
Борыны яхшы сизә аның,
Укый һаман догаларын.
Һәммә нәрсәне дә ул тикшерә,
Гөнаһлымы, изгеме дип кенә.
Тартманы ул күргәч, аңлап ала:
Изгелек күп түгел анда.
„Балам, — ди ул, — алмыйк хаксыз малны,
Җанны борчыр тик ул, суырыр канны.
Аллабызга аны бирербез дә,
Күктән тәмле манный явар безгә".
Маргарита йөзен чытып куя,
„Бүләк атта нинди гаеп була? —
Дип уйлый ул, — моны бүләк иткән
Кеше нигә динсез булсын икән?"
Ана карчык попны чакырып китерә,
Ул, сорашып, бөтен хәлне белә,
Шат елмаю бизи шунда аны.
Әйтә: „Син, ди, һич тә ялгышмаган,
Нәфсең җиңсәң, әҗрен бирер аллаң,
Чиркәүнең нык аның аш казаны.[78]
Йотты бит ул зур илләрне,
Авыртканы юк һич әле.
Хаксыз малны чиркәү генә
Һәйбәтләп кенә сеңдерә".

Фауст

Мондый гадәт бар аларда,
Корольдә һәм еврейларда.

Мефистофель

Ала йөзек, алкаларны,
Әйтерсең лә, бер чүп-чарны.
Ичмаса бер рәхмәт дими,
Бер чикләвек аламыни!
Әҗре булыр, имеш, ахирәттә,
Карчык бик шат, — аңар шул кирәк тә.

Фауст

Ә Гретхен?

Мефистофель

Йөрәге бик әрни аның,
Аңламый һич ни булганын.

Бүләкне ул уйлый көн-төн,
Китергән, дип, аны соң кем?

Фауст

Бу хәл мине борчый бигрәк,
Яңа бүләк китер тизрәк!
Тагы да яхшырактан булсын.

Мефистофель

Әллә моны җиңел дип уйлыймсың?

Фауст

Мин әйткәннәр эшләнсеннәр, эзлә, тырыш,
Үзең аның күршесенә сырыш!
Шайтан бул син, бутка булма,
Бүләк китер, юк дип торма!

Мефистофель

Тырышырмын, хуҗам, чын күңелдән.

(*Фауст китә.*)

Гыйшык тоткан мондый тиле
Кояш, ай һәм йолдызларның барсын бердән
Сөйгәненә бүләк итеп бирер иде.

УНЫНЧЫ СЦЕНА

Күрше хатын йорты

Марта

(*ялгызы*)

Тәңре кичерсен иремне,
Бер дә яхшы түгел инде, —
Ил гизәргә чыкты-китте,
Җәфаланам, сабырым бетте!
Үзенә бер хыянәт тә итмәдем бит,
Чын күңелдән сөя идем, тәңре шаһит.

(*Елый.*)

Бәлки инде күптән үлгәндер дә!
Язу булсын иде үлгәненә!

(*Маргарита килеп керә.*)

Маргарита

Ах, Марта!

Марта

Гретхен, нәрсә бар?

Маргарита

Калтырый тез буыннарым.
Шкафымны ачсам, тагын
Бер матур тартма куйганнар.
Эчендәге әйбере дә
Элеккедән шәбрәк менә!

Марта

Монысын инде әниең белмәсен,
Тагын попка илтеп бирмәсен.

Маргарита

Карасана! Күрче барсын!

Марта

(*аны киендерә.*)

Син бик бәхетле тугансың!

Маргарита

Тик бизәнеп йөреп булмас,— әрни күңел,
Болай чиркәүгә дә бару мөмкин түгел.

Марта

Син еш кына миңа килерсең,
Һәм киярсең, яшереп, барын да:
Бер сәгатьләп көзге алдында йөрерсең,
Рәхәт булыр шул чагында.
Җае чыгар, бәйрәм көннәрендә
Күрсәтерсең барын бераә-берәм генә:
Башта муенсаңны, шуннан алкаларны;
Сизмәс анаң, алдый белербез лә аны.

Маргарита

Ике бүләкне дә миңа кем китергән? —
Бик яхшыдан булмас моның төбе, беләм!

(*Ишек шакыйлар.*)

Әнидер бу! Изгеләр, мәдәт бирегез!

Марта

(ишекнең пәрдәсен күтәреп карый.)

Бер әфәнде анда. — Керегез!

(Мефистофель керә.)

Мефистофель

Мин тиешмен сездән гафу үтенергә
Базган өчен туп-туры килеп керергә.

(Маргарита алдында хөрмәт беләп кире чигенә.)

Миңа Марта Швердтлейн кирәк иде!

Марта

Мин буламын, сорыйсыз сез нигә мине?

Мефистофель

(аңар әкрен генә)

Инде сезне таныйм, шунсы җиткән;
Асылзат кунак бар икән.
Гафу үтенәм, сүзегезне бүлдем,
Төштән соң бер тагын керермен.

Марта

(кычкырып)

Тыңла, бала, эшләр ничек менә!
Ул сине бер туташ диеп белә.

Маргарита

Мин бер гади кыз, я алла!
Сез бик яхшы; болар бар да
Үземнеке түгелләр шул.

Мефистофель

Ах, эш бизәктә мени ул!
Нинди буй-сын! Нур бар йөзегездә.
Бик шатланып калам сездә.

Марта

Тыңлыйм сездә нинди хәбәр барын.

Мефистофель

Бик китерер идем яхшырагын.
Тиргәмәгез, әйтмичә юк чарам:
Ирегез вафат, сезгә сәлам аннан.

Марта

Вафат? Ах! Бәгырем, сөйгәнем!
Ирем үлгән! Мин дә үләмен!

Маргарита

Ах, Марта! Бик бетмә үзең!

Мефистофель

Тыңлагызчы кайгы сүзен!

Марта

Мөмкин булса алдан кайгыны күрергә,
Һич сөймәгән булыр идем мин гомердә.

Мефистофель

Һәр шатлыкка кайгы, кайгыга — шатлык бар.

Марта

Ничек үлде, сөйләп бирегез барын да!

Мефистофель

Падуяда туфрак насыйп булды аңар
Изге Антоний янында,
Төзек, матур шәһәр аны
Мәңгелеккә үзенә алды.

Марта

Берәр нәрсә юкмы миңа соң иремнән?

Мефистофель

Әйе, бер бик авыр һәм зур үтенеч:
Өч йөз месса укытырга ихлас белән!
Бүтән нәрсә юк кесәмдә — ни үкенеч!

Марта

Нәрсә дисез? Аһ, бу көнне күрмәсәмче!
Капчыгында әйбер йөртә һәр һөнәрче

Өе өчен бүләккә дип,
Ач булса да үзе, соранса да.

Мефистофель

Әйе, бу хәл күңелсез бик;
Тик ул бушка акча түкмәде кайчан да.
Эш уңмый дип, бик көенде,
Бәхетсезлек изүенә сыкрап йөрде.

Маргарита

Ах! Кешеләр нинди бәхетсез дөньяда!
Мәрхүм өчен дога кылачакмын мин дә.

Мефистофель

Сезгә мөмкин бүген чыксагыз да иргә,
Сез шундый бер гүзәл бала.

Маргарита

Ах, юк, миңа иртә әле!

Мефистофель

Ирме, барыбер, әллә сөяркәме,
Күктән бүләк бу, дип санар бар да,
Шундый кызны кочакка алганда.

Маргарита

Мондый гадәт юк бит илдә.

Мефистофель

Бармы, юкмы, — мондый хәлләр очрый бирә.

Марта

Я, сөйләгез!

Мефистофель

Үлем түшәге янында
Булдым, түшәк — ярым чергән салам иде,
Тик ирегез динле килеш җанын бирде.
Гөнаһлары торды аның күз алдында.
„Мин, — диде ул, — үз-үземне дошман күрәм:
Хатынымнан киттем нинди вөҗдан белән?
Истәлекләр борчый җанны!
Дөньяда ук, аһ, ул бәхилләсен иде!“

Марта

(елап)

Кадерле ир! Күптән бәхилләдем инде.

Мефистофель

„Тик миннән дә гаеплерәк үзе тагы“.

Марта

Алдый! Ялган сөйли кабергә кергәндә!

Мефистофель

Күрәсең, ул бераз саташты үлгәндә,
Дөрес аңлый белсәм төбен.
„Бәйрәм итеп, — диде ул, — мин яшәмәдем,
Балаларым булды, икмәк хәстәрләдем, —
Һәм икмәкнең һәрбер төрен.
Өлешемне ләкин тыныч ашамадым“.

Марта

Оныткан ул тугрылык һәм сөю барын,
Көн-төн азапланганымны.

Мефистофель

Алай түгел, сезне ул сагынды.
Бер сөйләде: „Мальтадан, — ди, — кайта идек,
Балаларым, хатыным өчен дога кылдым,
Һәм кызганды тәңре үзенең колын, —
Диңгездә без төрекләргә туры килдек,
Солтан хәзинәсе иде каекларда.
Батырлыкның бүләге бар,
Һәм минем дә өлешемә тиде анда,
Дөрес булгач, шактый күп мал“.

Марта

И, кайда ул? Җиргә күмеп калдырганмы?

Мефистофель

Искән җилләр кая очыргандыр аны.
Ирегезне бер кыз үзенә караткан,
Ул ял итеп йөргән чакта Неапольдә.
Кыз сөйкемле, сылу булган, бик яраткан,
Ирегез дә сөйли иде аны көн дә.

Марта

Явыз нәрсә! Үз балаларын талаган!
Михнәт һәм җәфа эчендә
Һаман бозык гадәтләрен ташламаган.

Мефистофель

Әйе! Үлде шуның өчен дә.
Сезнең урыныгызда булса идем,
Траурда йөреп бер ел гына,
Табар идем тагы да шәбен ирнең.

Марта

Минем өчен иң әйбәте тик ул гына,
Тиз табылмас аның төсле бүтән кеше!
Яхшы җанлы иде мәрхүм, тиле-миле,
Илләр гизү иде ләкин сөйгән эше,
Кеше хатынын һәм шәрабын сөя иде
Һәм шул мәлгун отыш уеннарын.

Мефистофель

Алай булса, бик шәп бар да!
Рөхсәте бар икән аның
Яхшы үрнәк алгаларга —
Алмаширмын үзем чын күңелдән
Балдакларны сезнең белән.

Марта

Әфәндем, сез сөйлисез бит уйнап!

Мефистофель

(*үз-үзенә*)

Тизрәк кирәк моннан ычкынырга:
Җеннең үзен дә бу алыр кулга.

(*Маргаритага*)

Сезнең йөрәк тибә, кемне уйлап?

Маргарита

Аңлый алмыйм сезне.

Мефистофель

(*үз-үзенә*)

Гөнаһсыз саф бала!

(*кычкырып*)

Сау булыгыз!

Маргарита

Хушыгыз!

Марта

Бер сорау кала:
Язу алып булмас микән, дим, кулыма
Ирем кайчан, кайда үлгәне турында.
Тәртип сөям, яхшы булыр иде, әгәр
Үлгәненә газетада булса хәбәр.

Мефистофель

Хөкем өчен, ханым, ике шаһит җитә,
Шулар сүзе хакыйкатьне исбат итә.
Минем яхшы бер дустым бар;
Ул гуаһлык итсә ярар.
Алып килсәм нәрсә дисез?

Марта

Бик үтенәм!

Мефистофель

Туташкай да булырмы соң сезнең белән?
Бик күп илләр гизгән кеше дустым минем;
Әдәпле ул, белә бөтен эшнең ибен.

Маргарита

Кызарырмын, куркам, әфәнде янында.

Мефистофель

Кызармассыз һичбер корольнең алдында.

Марта

Ярый, сезне без көтәрбез, һәр икебез,
Кич җиткәчтен, минем бакчама килегез.

УНБЕРЕНЧЕ СЦЕНА

Урам

Фауст, Мефистофель.

Фауст

Я? Ничек соң? Бик озак ич!

Мефистофель

Әһә! Нинди дөрләп яна!
Тиздән синеке кыз бала!
Марта бакчасында була ул бүген кич.
Монсы аның гаҗәп хатын, шундый уңган,
Гүя кызлар кавыштыру өчен туган!

Фауст

Була бирсен!

Мефистофель

Тик бездә бер йомышы бар.

Фауст

Хезмәт, өчен хезмәт аңар.

Мефистофель

Гуаһ булып, әйтү кирәк безгә шуны:
Бу хатынның ире инде мәрхүм булды,
Иске шәһәр Падуядә күмелде, дип.

Фауст

Бик шәп! Барып килербез бит анда элек?

Мефистофель

Sancta simplicitas![74] Кирәк, ди, бик!
Гуаһлык ит, йөрмә күпне белеп!

Фауст

Алай булса, бу планны ташла себереп.

Мефистофель

Изге, имеш! Син кызык бит!
Ялган гуаһлык бирәсеңме
Үз гомереңдә беренче кат әллә?

Тәңре, дөнья һәм андагы бар көчләргә,
Кешегә һәм акылына, бар хисләргә,
Бик масаеп, билгеләмә бирмәдеңме[75]
Тыныч вөждан, кыю күкрәк белән?
Әллә сиңа, әйтсәк инде чынын гына,
Артыграк билгелеме ул турыда
Швердтлейн әфәнденең үлеменнән?

Фауст

Ялганчы һәм софист килеш син һаман да.

Мефистофель

Шулай күренә тирән белем булмаганга.
Иртәгә үк башкача сөйләрсез,—
Мескен кызга ниләр диярсез,
Ант итәрсез,—имеш сөясез.

Фауст

Чын йөрәктән.[76]

Мефистофель

Яхшы анысы.
Тугрылык һәм сөю мәңге, имеш,
Саф ашкыну яши көчле килеш,—
Бу чын йөрәктәнме барысы?

Фауст

Җитәр!—Шундый тирән дулкынланам,
Шашкын тойгы ташып ага,
Аңар исем таба алмам,
Уйлар белән очам бар дөньяда,
Матур сүзләр җыям анда,
Шундый бер ялкында дөрлим,
Чиксез ул дим, мәңгелек дим,—
Шайтан ялганымы бар да?

Мефистофель

Димәк, мин хаклы!

Фауст

Тыңла! Шуны бел:
Акырмыйча, әйтәм сиңа әкрен генә,
Хаклы булам, дисәң,— булсын телең генә,—
Син — хаклы гел.
Киттек! Бушка лыгырдаудан туйдым бигрәк,
Хаклы бул син, чөнки миңа шулай кирәк.[77]

УНИКЕНЧЕ СЦЕНА

Бакча

Маргарита Фауст белән култыклашкан, Марта Мефистофель белән ары-бире йөриләр.

Маргарита

Беләм, мине кызганудан гына
Сөйләшәсез шулай, мин оялам.
Ил гизүче гадәтләнгән була
Әдәплелек күрсәтергә һаман.
Яхшы аңлыйм, сездәй галим бер кешегә
Минем ярлы сүзем кызык түгелдер лә.

Фауст

Бер карашың һәм бер сүзең өчен синең
Бөтен дөнья хәкыйкатен бирер идем.

(Аның кулын үбә.)

Маргарита

Кирәк түгел! Ничек үбәсез сез аны?
Ул каты һәм тупасланган!
Минем өстә шул йорт эшләренең бары!
Пөхтәлекне сөя анам.

(Узып китәләр.)

Марта

Сез, әфәндем, гизәсезме һаман илдә?

Мефистофель

Ах, нишлисең, кәсеп шулай куып йөртә!
Йөрәк сызлый, калырга дип кайбер җирдә,
Булмый ләкин, алда тагын эшләр көтә.

Марта

Яшь чагында ярый бирә,
Теләгәнчә, бар дөньяны урап йөрү;
Тик бер вакыт картлык килә;
Ялгыз, ятим хәлдә салкын гүргә килү,—
Монысын инде кызык димә.

Мефистофель

Белеп торам моны, куркып, мин үзем дә.

Марта

Вакытында колак салыгыз сүземә.

(*Узып китәләр.*)

Маргарита

Әйе, күздән китсә — китте уйдан!
Якты йөз — ул сездә гадәт кенә;
Дусларыгыз белән дөнья тулган,
Барсы миннән күбрәк белә.

Фауст

О, кадерлем! Ышан, белем дип атала
Бик еш коры кәпрәю дә.

Маргарита

Шулай дисез?

Фауст

Ах, садәлек, гөнаһсызлык, һичкайда да
Кадрегезнең изгелеген сез белмисез!
Баш ию һәм түбәнчелек — менә болар
Иң югары сыйфатлар ич сөйгән җанда.

Маргарита

Сез уйлагыз мине, күз ачып йомганда,
Минем күңелем һаман, һаман сезне уйлар.

Фауст

Сез берьялгыз буласыздыр бик күп кенә.

Маргарита

Әйе; безнең хуҗалык кечкенә,
Өлгерергә кирәк ләкин бөтенесенә.
Хезмәтче кыз асрамыйбыз, тегәм-ямыйм,
Пешерәм, себерәм, барысын карыйм.
Тәртипне бик ярата шул әнкәм минем.
Тормышыбыз алай авыр димәс идем;
Яшәү мөмкин безгә яхшырак та тагы:
Әткәемнән әйбәт кенә мирас калды —
Кечерәк бер өй, бакча шәһәр читендә.
Хәзер инде бик тын үтә көнем;

Абыем солдат хезмәтендә,
Сеңелем үлде мескенем,
Аның өчен күп азапка мин чыдадым,
Рәхәтләнеп чыдар идем күбрәк тагын, —
Исән булса.

Фауст

Бер фәрештә булгандыр ул синең төсле.

Маргарита

Мин үстердем, мине сөйде шундый көчле.
Ул туганда әткәй инде үлгән иде,
Әнкәй мескен үләр чиккә килде,
Бик каты ятты урында,
Савыкты ул, бик озаклап, акрын гына.
Ул һич уйлый да алмады
Имезим дип яшь баланы.
Минеке ул, мин үстердем,
Сөтен бирдем, суын бирдем.
Кулларымда, итәгемдә
Зур үсте ул, уйнап бергә.

Фауст

Саф бәхетнең ни икәнен, димәк, белдең.

Маргарита

Һәм, билгеле, бик күп авырлык та күрдем.
Бала бишеге торды һаман
Минем урын янында: чак чайкаламы —
Төнлә мин уянам.
Сөт эчерәм, яткырам үз яныма аны.
Юанмаса, урынымнан торам да, мин
Бүлмә буйлап бәллү итеп, биеп йөрим.
Иртән тагын иртүк торам, кер өтелим,
Аш-суны да карыйм, базарга да барам,
Көннәр шулай үтә һаман.
Кайчагында күңелсез дә булып куя,
Тик ашавың тәмле, йокың татлы була.

(*Узып китәләр.*)

Марта

Мескен хатын-кызлар борчыла һаман да,
Өйләнмәгән кеше нигә үзгәрми, дип.

Мефистофель

Сезнең төсле хатын очраганда,
Төзәлергә без хәзер бит.

Марта

Күптән инде кайда булса бер сылуны
Тапкансыздыр, яшермәгез миннән шуны.

Мефистофель

Бер мәкаль бар: яхшы хатын
Һәм үз ояң — менә шулар алтын.

Марта

Сезгә шатлык таныш түгел, белмим, нигә?

Мефистофель

Мине яхшы каршылыйлар һәрбер җирдә.

Марта

Бәлки сезнең чынлап типмәгәндер йөрәк?

Мефистофель

Хатын-кыздан көлеп йөрү нигә кирәк?

Марта

Ах, сез мине аңламыйсыз!

Мефистофель

Бик үкенәм!
Миңа сезнең караш яхшы — шунсын беләм.

(*Узып китәләр.*)

Фауст

Фәрештәкәй, шулай танып алдым, диген,
Керү белән мин бакчага?

Маргарита

Күрдегез ич, керфекләрне түбән идем.

Фауст

Кичермәссең син, дип куркам, беркайчан да,
Хәтерләсәң минем турдан үткәнеңне,
Шунда артык кыю булып киткәнемне.

Маргарита

Мин оялдым очравыма шундый хәлгә;
Начар әйтмәс минем турда бер кеше дә,
Ах, дидем мин, бармы әллә
Ярамаган нәрсә минем бер эшемдә?
Шуңар, дидем, ул сүз кушмакчы булгандыр,
Бу кызыйны тиз күндерем, ди торгандыр.
Дөресен әйтәм, нәрсәдәндер, үзем белмим,
Сезнең хакта алай начар уйламадым,
Сезгә чынлап ачулана алмадым мин,—
Шуңар үземә ачуым килде ныграк тагын.

Фауст

Назлым!

Маргарита

Тимәгез!

Астра чәчәге ала да, бер-бер артлы аның яфракларын өзә.

Фауст

Чәчәк ник өзәсез?

Маргарита

Бер уен бу!

Фауст

Ничек?

Маргарита

Әйтмим, я көләрсез!

(*Чәчәк яфракларын өзә һәм пышылдый.*)

Фауст

Нәрсә пышылдыйсың?

Маргарита

(*ярым ишетелерлек.*)

Сөя мине — сөйми.

Фауст

Фәрештәм, син җазибәле нинди!

Маргарита

(*дәвам итә.*)

Сөя—сөйми; сөя—сөйми.

(*Соңгы яфракны өзә һәм сөйкемле шатланып.*)

Әйе, сөя!

Фауст

Дөрес, бала! Чәчәк теле сөйләп бирә
Аллаларның сүзен сиңа. Ул бик сөя!
Аңлыйсыңмы син бу сүзне? Сине сөя!

(*Аның ике кулыннан тота.*)

Маргарита

Мин дерелдим.

Фауст

О, курыкма! Күз карашым,
Кул кысуым әйтсен сиңа
Һич әйтелмәс нәрсәләрне:
Бирелергә бөтенләй һәм кичерергә
Мәңге бетмәс зур бәхетне!
Мәңге бетмәс! — Чөнки ахыры өметсезлек.
Хәер, ахыры юк! Юк!

Маргарита аның кулын кыса да, ычкынып, читкә йөгерә. Фауст, аз гына уйланып тора да, аның артыннан китә.

Марта

(*килеп керә.*)

Төн дә җитә.

Мефистофель

Безгә китәргә кирәк.

Марта

Калыгыз дип үтенер идем дә,
Безнең шәһәр халкы усал бигрәк.

Әйтерсең лә, һич эше юк беркемнең дә,
Тик йөри шунда,
Күршесенең һәр адымын санап тора,
Бер өзлексез чәйни гайбәтләрен аның.
Безнекеләр кайда?

Мефистофель

Алар югалдылар,
Иркә күбәләкләр!

Марта

Кызда егетнең күңеле бар.

Мефистофель

Һәм егеттә — кызның. Эше шул дөньяның.

УНӨЧЕНЧЕ СЦЕНА

Беседка

Маргарита беседкага сикереп керә дә ишек артына яшеренә, бармагын ирененә куеп, ишек ярыгы аркылы карый.

Маргарита

Килә!

Фауст

(*килеп керә.*)

Ах, наян кыз; үчеклисең мине!
Тотармын, бел!

(*Маргаританы үбә.*)

Маргарита

(*Фаустны кочаклап, аның үбүенә җавап кайтара.*)

Җаным! Шундый сөям сине!

(*Мефистофель ишек шакый.*)

Фауст

(*аяк тибеп*)

Кем ул?

Мефистофель

Дустың!

Фауст

Хайван!

Мефистофель

Вакыт аерылырга.

(*Марта килеп керә.*)

Марта

Әйе, бик соң.

Фауст

Мөмкинме озата барырга?

Маргарита

Әнкәм орышыр — сау бул!

Фауст

Димәк, китим, җаным?

Сау бул!

Марта

Адье!

Маргарита

Тизрәк күрешергә тагын!

Фауст һәм Мефистофель китәләр.

Маргарита

Тәңрем! Нинди галим ир ул!
Гомере буе уйланган шул!
Оялудан кызарып, мин
Һәр сүзенә тик „әйе!" дим.
Мин бер аңсыз мескен бала,
Белмим, миндә ул ни таба.

(*Китә.*)

УНДҮРТЕНЧЕ СЦЕНА

Урман һәм мәгарә

Фауст

(*ялгызы*)

Гали рух! Син бирдең миңа, бирдең миңа
Сораганнарымның барын. Һәм йөзеңне
Утта күрсәтүең бушка түгел иде.
Бай табигать бирдең минем хакимлеккә,
Көч бирдең син аны белергә, татырга.
Мин бер салкын, хәйран калган кунак түгел,
Рөхсәт иттең, дус йөрәген күргән төсле,
Күз салырга аның тирән күкрәгенә.
Саф-саф итеп уздырасың мәхлукатны
Минем алдан, өйрәтәсең кардәшемне
Күрергә тын урманда, суда, һавада.
Карурманда давыл көчле улаганда,
Сынган чакта йөз еллык калын нарат,
Күрше агачларны кубарып тамырыннан,
Ауган тавыш тауда тонык яңгыраганда, —
Син илтәсең мине тын бер мәгарәгә,
Күрсәтәсең мине үземә, йөрәктә
Ачылалар яшерен, тирән могҗизалар.
Күз алдымда калка шунда саф ай,
Тирә-якка тынлык биреп; һәм агылалар
Кыялардан, юеш урманнар эченнән
Борынгының көмеш шәүләләре, —
Күзәтүнең кырыс шатлыгы йомшара.[78]
Кеше өчен камил нәрсә һич юклыкны
Сизәм хәзер. Аллаларга якынайткан
Бәхетемдә юлдаш бирдең, аннан башка
Инде яши алмыйм, ә ул салкын, усал,
Түбәнәйтә мине үз алдымда,
Бер сүз белән бүләкләреңне юк итә.
Кыргый бер ут дөрләтә ул күкрәгемдә
Шул гүзәлгә карата, бик тырышып.
Мин айкалам теләкләрдән ләззәтләргә
Һәм ләззәттә ашкынамын теләкләргә.

(*Мефистофель керә.*)

Мефистофель.

Бу тормыш бер туйдырырмы икән?
Анда озак рәхәт табасың.

Татып карадың бер, — шул бик җиткән.
Инде таты тагын яңасын!

Фауст

Юкмы әллә бүтән эшең? —
Матур көнемне бозасың.

Мефистофель

Ярый, барыбер минем өчен,
Юкка гына син кызасың.
Шундый усал, тупас иптәшеңне
Югалтсаң да, үкенмәссең.
Көн-төн эшлим үземнең эшемне,
Хуҗаңа ул лəкин килешерме, —
Борынына карап, һич белмәссең.

Фауст

Нинди хаклы син бу юлы!
Ул йөдәтә — ә мин рәхмәт диген!

Мефистофель

Әйт әле, мескен җир улы,
Минсез ничек яшәр идең?
Буталчык һәм ямьсез уйларыңнан
Әллә кайчан терелттем мин сине;
Мин булмасам, җир шарыннан
Китәр идең күптән инде.
Бер ялгызың мәгарәдә, шул таш тауда
Ябалактай утыруда, әйт, ни файда?
Юеш таштан, черек мүктән, нәкъ бакадай,
Азык эзләп ятма алай.
Шәп уза, имеш, көннәре!
Юк, син һаман доктор әле.

Фауст

Аңлыйсыңмы, яңа көчләр бирә
Йөрү миңа шушы тып-тын җирдә.
Әгәр сизә белсә идең,
Шайтан ич син, көнләр идең бәхетем минем.

Мефистофель

Оҗмах ләззәтләре, имеш! —
Төнлә чыклы таш тауларда яткан килеш,
Рәхәт таба — җирне, күкне ала кочып,
Кабарына, алла булырга тырышып,

Ашкынулы фикере җирнен миенә җитә,
Алты көннең эшен үзендә хис итә,[79]
Мәгърур, көчле, рәхәт таба, белмим нидә,
Сөя, эри дә тарала бөтен җирдә,
Юк була тәмам җир улы,
Һәр ялкынлы омтылуы —

(*әдәпсез хәрәкәт ясый.*)

Әйтеп тормыйм — нинди нәтиҗәләр бирә.

Фауст

Тьфү битеңә!

Мефистофель

Ошатмадың бер дә монысын!
Бик әдәпле төкеренергә син хаклысың.
Әйтмиләр шул бик инсафлы колакларга,
Бик инсафлы йөрәк нидән кызык таба.
Кыскасы шул, сиңа иркен юл куям мин,
Туры килсә, бераз ялганлап та ал, дим.
Болай булса озак бармас,
Инде кибәсең бит тагын,
Һәм яңадан бирелер җаның
Шомлы уйга; бер ямь калмас.
Ярый, җитәр! Назлың ялгыз утыра анда,
Бернәрсәдән ямь тапмый ул,
Чыгармый ул сине исеннән һаман да,
Көчле мәхәббәт саклый ул.
Башта гыйшкың котырып ташыды синең дә,
Тар елгалар ташыган күк кар суыннан,
Ташкын койдың аның йөрәгенә,
Саекты елгаң соңыннан.
Утырганчы тәхеттә урманда,
Яхшырак, дип киңәш бирәм,
Кайнар канлы кызга синнән
Гыйшкы өчен мөкафәт булганда.
Уздыра алмый ул көннәрен,
Тәрәзәдән карый: болыт агыла һаман
Карт шәһәрдән тышка табан,
„Булса идем кош!“ дип җырлый, яшь күңелен
Юата ул көнен-төнен.
Бер шат була, тагын яна-көя,
Аннан елап ала
Һәм яңадан җанлана,
Үзе һаман сөя.

Фауст

Елан! Елан!

Мефистофель

(*үз-үзенә.*)

Эләктерермен! Куймам!

Фауст

Югал, мәлгун! Торма күз алдымда!
Гүзәл кызның исемен телгә алма!
Тән ләззәте дәртен тагын салма
Минем инде ярым тилергән җаныма!

Мефистофель

Эш нәрсәдә? Уйлый мескен, син киттең дип,
Чыннан шулай диярлек бит.

Фауст

Еракта да аңар бик якын мин,
Онытасым юк һәм беркемгә дә бирмәмен.
Әйе, хәтта Гайсабызның тәнен көнлим,
Тиергәндә иркәм аңар иреннәрен.

Мефистофель

Синнән, дустым, гөл чәчәкләр каплап алган
Ике игезәкне көнләдем мин бер заман.

Фауст

Аздыручы! Кит!

Мефистофель

Сүк! Көлеп тыңлыйм барын.
Тәңре үзе яраткачтын хатын, ирне
Сылтауны да бик тиз бирде
Башкарсыннар өчен иң төп бурычларын.
Хәсрәтме бу? — Исең китмәсен лә!
Чакырам сине иркәң бүлмәсенә,
Ә дар агачына түгел.

Фауст

Оҗмах шатлыгы бар кочагында!
Ял итсәмче шунда бер тагын да!
Сагышлы ул — сизә күңел.

Мин кем? Мескен качкын, йортсыз-җирсез торам,
Кеше түгел, тынлык белмим, максат белмим,
Таштан ташка үкереп төшкән ташкынсыман,
Комсызланып, упкыннарга ашкынам мин.
Һәм менә — ул, саф аның барлык уйлары,
Кечкенә бер өйдә яши Альпларда;
Шатлыклары, кайгылары
Тар дөньяга сыйган бар да.
Һәм — мин, алла каргаган җан,
Җитмәгәнме миңа тагы —
Кыяларны кубарам,
Көл итәм аларны!
Мин килдем дә, тыныч тормыш бетте аңар,
Тәмуг, әйдә миннән шушы корбанны ал!
Булыш, шайтан, курку көннәре кыскарсын!
Тәкъдир нәрсә язган, шуңар тизрәк җитик!
Аның язмышкае мине бөтереп алсын,
Бергәләп без төпкә китик!

Мефистофель

Тагын дөрли, тагын яна!
Бар, юат син аны, тиле!
Чыгу юлын эзләп тапмаганда,
Кычкыралар: беттек инде!
Яшәсен, димен, кыюлар!
Син үзең дә инде шактый шайтанландың.
Бу дөньяда ямьсезрәк соң нәрсә бар —
Шиккә төшкән шайтаннан да тагын?

УНБИШЕНЧЕ СЦЕНА

Гретхен бүлмәсе

Гретхен

(ялгызы җеп эрли.)

Бетте тынычлык,
Яна йөрәгем.
Узды мәңгегә
Гамьсез көннәрем.

Ул булмаган җир —
Миңа гүр генә,

Бөтен дөньясы
Ямьсез күренә.

Мескен башкаем
Тәмам чуалды,
Зиһенем таралды,
Уйлыйм тик аны.

Бетте тынычлык,
Яна йөрәгем,
Узды мәңгегә
Гамьсез көннәрем,

Тәрәзә аша
Мин аны күзлим,
Өйдән чыкканда,
Мин аны эзлим.

Тәкәббер сыны
Тыныч йөрүе,
Серле күзләрдән
Көч бөркелүе,

Сихерле сүзе
Матур көлүе,
Кулны кысуы,
һәм ах! үбүе!

Бетте тынычлык
Яна йөрәгем,
Узды мәңгегә
Гамьсез көннәрем.

Күңелем ашкына
Гел аңар табан,
Ах, булсын иде
Янымда һаман!

Туйганчы аны
Мин үбәр идем,
Назлап үпкәндә,
Мин үләр идем!

УНАЛТЫНЧЫ СЦЕНА

Мартаның бакчасы

Маргарита, Фауст

Маргарита

Генрих, сүз бир!

Фауст

Житсә көчем!

Маргарита

Әйтче миңа, дин белән эш ничек синең?
Син үзең бик яхшы бер кешесең,
Тик динне бик хөрмәтлисең дип белмимен.

Фауст

Калдыр, бала! Шунсын аңла—сине сөям,
Һәм сөйгәнем өчен йөрәк канын бирәм,
Дин тойгысын тартып алмыйм кешеләрнең.

Маргарита

Дөрес түгел, дин тотарга тиеш һәркем.

Фауст

Тиеш?

Маргарита

Ах! Мин ярдәм итә алса идем!
Изге бүләкләргә хөрмәтең күрмимен.[80]

Фауст

Хөрмәтлим мин.

Маргарита

Ләкин теләмичә генә.
Чиркәүгә дә барганың юк синең бер дә.
Ышанасыңмы аллага?

Фауст

Кем әйтә ала:
„Ышанам!“ дип?
Поптан яки хәкимнәрдән сорап кара,
Аларның да җавабы тик
Бер мыскыллау булып тоелыр.

Маргарита

Ышанмыйсың?

Фауст

Фәрештәкәй, син мине ялгыш аңлыйсың.
Кем аны атый ала?
Кем әйтә ала:
„Мин ышанам!“
Кем шулай хис итә,
Кемнең кыюлыгы җитә
Әйтергә: „мин ышанмыйм!“
Бөтенесен чолгап ала,
Бөтенесен саклап кала,
Чолгамыймы ул, сакламыймы
Сине, мине һәм үз-үзен?
Күк гөмбәзе юкмы югарыда?
Нык түгелме җир түбәндә?
Балкымыймы, шат нур чәчеп,
Мәңгелек йолдызлар күктә?
Текәмимме күземне күзләреңә?
Агылмыймы болар бар да
Миеңә һәм йөрәгеңә?
Тирбәлмиме, мәңгелек сер булып,
Күренеп һәм күренмичә, әйләнәндә?
Тутыр шуннан йөрәгеңнең бөтенесен,
Һәм кайчан син изге тойгыны белерсең,—
Ата аны теләгәнчә:
„Бәхет! Йөрәк! Сөю! Алла!“
Мин исемен белмим
Аның! Тойгы барсы.
Исем-тик аваз, төтен,
Күк йөзен ул каплаган.

Маргарита

Монысы дөрес, аңлый алам;
Поп та шулай диде беркөн,
Сүзләр генә бераз башка анда.

Фауст

Шулай диләр һәркайда,
Һәрбер йөрәк үзенең шат, ак көнендә,
Һәркайсы үз телендә;
Нигә мин дә әйтмим үз телемдә?

Маргарита

Моны ишетү миңа шатлык бирә,
Тик шунсына әрни минем күңел,
Гайса белән син дус түгел.

Фауст

Бала!

Маргарита

Күрдем исә иптәшеңне,
Шул әрнетә йөрәгемне.

Фауст

Кем ул?

Маргарита

Теге кеше, сез гел бергә,
Ул дошманлык тудыра минем күңелемдә.
Һичнәрсә һәм һичкайчан да
Тоз салмады минем канга—
Шыксыз йөзе хәтле аның.

Фауст

Курыкма аннан, курчагым!

Маргарита

Ул барында газапланам, әрним.
Бар кешене дә сөям мин,
Ләкин сиңа җаным ашкынганда,
Шул кешедән курку мине чолгап ала,
Һәм миңа ул бер алдакчы кебек тоела,
Хаксыз булсам, ярлыкасын үзе хода.

Фауст

Андыйлар да яшәү теләгендә.

Маргарита

Андый белән яши алмам мин гомердә!
Ул ишектән килеп керә.
Мыскыллап күз йөртеп, көлә,
Үзе усал тагы,
Күренеп тора бар нәрсәне чит санавы;

Һәм язылган аның маңгаенда—
Дөньяда ул сөйми бер җанны да.
Кочагыңда рәхәт синең,
Тәнем эреп китә минем,
Тик ул керсә, тагын сыкрый башлыйм эчтән.

Фауст

О, минем сизгер фәрештәм!

Маргарита

Бу җирәнү шундый көчле,—
Безнең янда ул булганда,
Сине дә мин хәтта сөймим төсле.
Ул барында укый алмыйм бер дога да.
Йөрәккәйне шул кимерә,
Борчыйдыр ич, Генрих, бу сине дә?

Фауст

Яратмаудан килә болар бар да.

Маргарита

Я, сау бул, миңа вакыт.

Фауст

Беркайчан да
Булмасмыни тыныч кына сине кочып,
Җанны җанга, күкрәкне күкрәккә кысып?

Маргарита

Ах, әгәр мин ялгыз йокласам!
Ишек ачык калыр иде бүген төнлә.
Ләкин сизгер йоклый анам,
Һәм тотса ул безне бергә,
Үләрмен мин шул урында.

Фауст

Фәрештәкәй, куркып торма.
Менә сиңа шешә! Тик өч тамчы аннан
Кушып бирсәң суга,
Шундый каты йоклар анаң.

Маргарита

Синең өчен барсын эшләп була!
Тимәстер бит шәт зарары?

Фауст

Алай булса бирмәс идем аны!

Маргарита

Сине күрсәм, жиңә көчең,
Белмим нидән, бирелəм мин иркеңә.
Эшләдем бик күпне синең өчен,
Эшләр нәрсә калмады күк инде бер дә.

(Китә.)

(Мефистофель керә.)

Мефистофель

Маймыл! Киттемени?

Фауст

Тагын шымчы булдың?

Мефистофель

Әйе, барсын ишетеп тордым.
Кабатлады доктор дин сабагын,
Бер файдасы булмый калмас аның.
Кызыкканы һәрбер кыз баланың:
Ир кеше, ди, элеккечә булсын динле,
Шул чагында, дип уйлый ул, тыңлар мине.

Фауст

Син, хәшәрәт, күрмисең шул,
Аның саф һәм тугры жаны
Иман белән тулган,
Бәхетле ул:
Көчле иманы бар, тик газаплый аны
Авыр тойгы: имеш, яры һәлак булган.

Мефистофель

Акыллы һәм үгә акыллы гашыйк жан,
Борыныңнан бер кыз өстери.

Фауст

Кит син, шахшыдан һәм уттан туган!

Мефистофель

Физиогномиканы ул начар белми![81]
Ул аптырап кала мескен мин барында,
Минем маскам аңар серне әйтеп тора;
Я бер даһи бу, дип уйлый шул чагында,
Я шайтанның үзе шунда.
Димәк, бүген төнлә?

Фауст

Ә синең ни эшең?

Мефистофель

Шатлык ич бу минем өчен!

УНЖИДЕНЧЕ СЦЕНА

Кое янында

Гретхен һәм Лизхен кувшин тотканнар.

Лизхен

Син Бербельхен турында ишеттеңме?

Гретхен

Өйдән мин бик сирәк чыгам. Нәрсә булган?

Лизхен

Миңа Сивилла сөйләде бүген серне:
Кызый тәмам язган юлдан.
Бик кәпрәйгән иде!

Гретхен

Ничек?

Лизхен

Ис бар анда!
Икәү туена, ул эчкәндә, ашаганда.

Гретхен

Ах!

Лизхен

Яраган, күптән аңар шулай кирәк!
Егетенә сырышып йөри иде бигрәк!
Уенда, бәйрәмдә,
Күңел ачып йөргәндә,
Мин кем, диде, бик кыланды,
Шәрап эчте, паштетлар белән сыйланды,
Мин матур, дип дөньяга сыймады.
Оят, намус калмады бер чеметем дә,
Яшермичә бүләк алды егетеннән.
Бигрәк чытлыклана иде,
Менә чәчәк сулды инде!

Гретхен

Мескенкәй!

Лизхен

Кызганган була тагын да!
Без җеп эрләгән чагында,
Әнкәй кушып, төннәр буе,
Ул егете белән булды,
Караңгы бер тыкрыкта шәп егет белән
Бик күңелсез булмагандыр, диеп беләм.
Инде менә башын исен
Һәм чиркәүдә тәүбә күлмәген дә кисен![82]

Гретхен

Егете аны алыр бит шәт?

Лизхен

Тиле булса! Уңган егет
Тагын кызын табар, йөреп;
Киткән инде.

Гретхен

Монысы начар.

Лизхен

Шәп булмас, кыз чыкса аңар.
Егетләребез таптар кызның чәчәк таҗын,[83]
Без ташларбыз салам ишек төбенә аның.

(*Китә.*)

Гретхен

(өйгә кайтышлый)

Шулай кыю сүгә идем мин дә,
Абынып куйса кызый берәр җирдә!
Гөнаһларын күрсәм бер мескеннең,
Җитәрлек сүз тапмый иде телем!
Кара гөнаһларны мин һаман да
Тырыша идем тагы да нык каралар га,
Масаюлы иде сүзем, —
Ә хәзер мин гөнаһлы үзем!
Нәрсә саташтырды мине,
Ах, шундый ул рәхәт иде!

УНСИГЕЗЕНЧЕ СЦЕНА

Шәһәр стенасы

Стена куышында Mater dolorosa[84] һәйкәле, аның алдында чәчәкле савытлар. Гретхен яңа чәчәкләр куя.

Гретхен

Иелсен йөзең,
Күр, яшь түгә күзем,
Шәфкать ит тирән кайгымда!
Кылыч — күкрәгеңдә,
Әрнү — йөрәгеңдә —
Улың үлеме күз алдында.
Атаңа карыйсың син,
Сызланып армыйсың син
Үзеңнең тирән кайгыңда.
Кем тоя ала,
Ничек тарала
Әрнү — бар җиремә?
Йөрәккәем ничек дөрли,
Нидән курка һәм ни тели, —
Тик син беләсең, син генә!
Кая гына бармыйм, анда,
Һаман, һаман, һаман да
Сыкрана мескен җаным!
Ах, ялгызым калдыммы мин,
Елыйм, елыйм, елыйм,
Сызланам ныграк тагын.

Тәрәз төбемдәге гөл
Чыланды күз яшемә,
Һәм үздем дә мин аны,
Китердем сиңа менә!
Күмелгәндә бөтен булмәм
Иртән кояш нурына,
Хәсрәт чигеп күңелемнән,
Утырам мин урында.
Оятка, үлемгә калдырма!
Иелсен йөзең,
Күр, яшь түгә күзем,
Шәфкать ит тирән кайгымда!

УНТУГЫЗЫНЧЫ СЦЕНА

Төн. Гретхен ишеге турында урамда

Валентин[85]

(*солдат, Гретхенның абые*)

Утыра идем мин табында
Дуслар мактанган чагында,
Алар кычкырып көлгәндә,
Кызларга бәя биргәндә,
Касәләрне тутырып салып;
Терсәкләремә таянып,
Утыра идем тыныч кына,
Һәммәсен дә тыңлап шунда.
Һәм көлеп, сакалны тарап,
Касә тотып, туры карап,
Әйтә идем: болар дөрес бар да!
Табарсызмы ләкин сез дөньяда
Минем Гретхенга тиңне,
Таң калдырмас минем сеңелем кемне?
Топ-топ! Чың-чың! Һәркем тавышлана:
„Дөрес, бик дөрес сүзләре,
Кызларның ул иң гүзәле!“
Мактанчыклар бар да тынып кала.
Ә хәзер! — Чәчне йолкыйммы,
Башымны ташка орыйммы?
Чәнечкеле, усал сүзләр белән
Һәрбер тинтәк көлгән була миннән.

Бик зур гаепледәй утырам мин,
Һәрбер яман сүздән янам, тирлим!
Тетеп ташлар идем барсын бергә,
Мөмкин булса: „Ялган бу!“ диергә.
Бу кем килә, сөйрәлеп аннан?
Икәү алар, аера алам.
Шул булса — ул тере китмәс моннан,
Кузгалмас та баскан урыныннан!

(Фауст һәм Мефистофель.)

Фауст

Сакристиядә,[86] тәрәзә алдында
Мәңгелек бер лампада, нур сибеп, яна,
Һәм яктысы әкрен кими бара,
Караңгылык — тирә-ягында.
Шундый ук төн минем күкрәгемдә.

Мефистофель

Мин ошыймын арык бер мәчегә,
Үрмәли ул түбәләрдән,
Төшә аннан тагын түбән;
Инсафлы ич тойгыларым:
Бераз гына урлау, бераз шәһвәт тагын;
Тамырларга инде үтеп керә
Ямьле Вальпургия төне.
Ул бик тиздән, берсе көнгә,
Йокы алмый анда һичбер кемне.

Фауст

Җир эчендә алтын ялтырады,
Өскә калкып ул чыгармы?

Мефистофель

Тиз көннән син шатланырсың,
Бер казан казып алырсың.
Күрдем әле, караганда,
Талерлар чиксез күп анда.

Фауст

Ә йөзекләр һәм алкалар? —
Бизәр идем иркәмне мин шулар белән.

Мефистофель

Күрдем, анда һәммәсе бар,
Чын җәүһәрдән муенсалар.

Фауст

Ярый! Булмаса бүләгем,
Әрни, аңар барганда, йөрәгем.

Мефистофель

Күңеллерәк, минемчә, тагын да
Бушлай рәхәт табу кайчагында.
Кара да син яхшы йолдызларга,
Ишет, миндә нинди осталык бар:
Әхлак җырын җырлыйм аңар,
Хис уята ул кызларда.

(*Гитара уйнап, җырлый.*)

Нигә килдең,
Син Катринхен,
Сөеклеңнең
Ишегенә иртә таңнан?
Булсын бар да!
Кер син анда,
Саф кыз бала,
Тик кыз килеш чыкмассың син, кире аннан.
Һәр кайда шул:
Иркәләр ул,
Шуннан — „сау бул“,
Ах, сез, мескен кыз балалар!
Син дә шунда
Тинтәк булма,
Назла, уйла:
Башта балдак алмашалар.

Валентин

(*килеп чыга.*)

Кемгә бу җыр? Бетсен башың!
Күсе тотып йөрмә монда!
Шайтан алсын гитарасын!
Шайтан алсын җырчысын да!

Мефистофель

Гитарасыз калдым, һич юк кирәге дә!



Валентин

Ярылыр хәзер баш сөягең дә!

Мефистофель

(*Фаустка*)

Доктор, тиз бул! Һич каушама!
Минем арттан бар син һаман!
Кылычыңны аңар када!
Аның кылычын мин кайтарам.

Валентин

Менә кайтар!

Мефистофель

Ник кайтармыйм?

Валентин

Болай ничек?

Мефистофель

Шулай!

Валентин

Хәзер яхшы аңлыйм:
Җен сугыша![87] Кулым хәрәкәттән калды.

Мефистофель

(*Фаустка*)

Када!

Валентин

(*егыла.*)

Беттем!

Мефистофель

Тинтәк менә юашланды.
Киттек ләкин! Тиз юк булыйк моннан.
Тирә-якта инде кычкыралар.
Полиция белән дуслыгым бар,
Тик саклану кирәк судка тартылудан.

(*Китәләр.*)

Марта

(*тәрәзәдән*)

Тышка! Тышка!

Гретхен

(*тәрәзәдән*)

Ут бирегез!

Марта

Чәнчешәләр! Тиз килегез!

Халык

Берсе инде үлгән!

Марта

(*чыга.*)

Үтерүчеләр качканнар да?

Гретхен

(*чыга.*)

Бу кем ята?

Халык

Анаң улы анда.

Гретхен

Раббым! Аһ, мин ни күрәм!

Валентин

Үләм! — дип тиз әйтеп була,
Тизрәк эшләнә тагын да,
Кызлар, уламагыз монда,
Тыңлагызчы барын да.

(*Барысы да аның янына киләләр.*)

Гретхен, син яшь әле, сеңелем,
Аңламыйсың эшнең төбен,
Бик начар синең юл.
Шуны сиңа киңәш итәм,
Фахишә булгансың икән,
Тулысынча шул бул!

Гретхен

Абыем! Нәрсә бу? Я алла!

Валентин

Алланы син телгә алма!
Буласы эш — булган бары,
Шулай барыр моннан ары:
Башта яшерен, берәү генә,
Шуннан килер бүтәне дә,
Уникегә тулгач инде,
Бөтен шәһәр алыр сине.

Беренче кат язык туганда,
Яшерен була барсы да,
Төн киемен каплый кеше аңа,
Колагына һәм башына.
Бик телиләр аны үтерергә,
Тик үсә ул һәм зурая,
Шәрә йөри якты көндә,
Ләкин бик аз матурая.
Шыксызланган саен йөзе,
Көндез күбрәк йөри үзе.
Килер бер көн, күрәм алдан,
Әй сөйрәлчек, синең яннан
Намуслылар качар бөтенесе,
Йогышлы бер үләксәдән качкан төсле.
Кая барырга белмәссең,
Һәркем карап үткән чагында,
Алтын беләзекләреңне һич кимәссең,
Тора алмассың чиркәүдә, михрап алдында.
Чиккән яулыгыңны япмассың,
Биеп күңелеңне тапмассың.
Хәерчеләр һәм гариплар белән бергә
Тар почмакта калырсың гомергә.
Әгәр тәңре кичерә икән,
Җирдә нәләт сиңа миннән!

Марта

Сора, алла сине ярлыкасын!
Ник җаныңа тагын йөк аласың?

Валентин

Тибә алса идем корсагыңа,
Аздыручы хатын, шул чагында

Өмет итәр идем мин, чыннан да,
Кичерелер дип барлык гөнаһлар да.

Гретхен

Абый! Бу бит — тәмуг газаплары!

Валентин

Елап торган була тагы!
Намусыңнан коры калдың,
Йөрәккә хәнҗәр кададың.
Үлем йокысына талам,
Тәңребезгә батыр солдат килеш барам.

(*Үлә.*)

ЕГЕРМЕНЧЕ СЦЕНА

Чиркәү

Гыйбадәт, орган һәм җыр. Гретхен халык арасында. Гретхенның артында явыз рух.

Явыз рух[88]

Бар да, Гретхен, башка иде,
Син әле саф хәлеңдә
Михрапка килеп,
Искереп беткән китаптан
Дога укыганда,
Балачакның уеннары
Һәм тәңре иде йөрәктә.
Гретхен!
Кайда башың?
Һәм йөрәгеңдә
Нинди язык бар?
Анаң өчен дога кыласыңмы? Аны
Син газаплы, газаплы йокыга талдырдың!
Бусагаңда синең кем каны?
Һәм синең йөрәгең астында
Нәрсә ул кыймылдый,
Сине һәм үзен куркыта
Шунда булуы белән?

Гретхен

Хәсрәт! Хәсрәт!
Бушанса идем уйлардан!

Тирә-якта алар һаман йөри шунда
Мине борчып!

Хор

Dies irae, dies illa
Solvet saeclum in favilla.

(*Орган авазы.*)

Явыз рух

Калтыран!
Быргы кычкырта!
Табутлар ачыла!
Һәм йөрәгең
Көл эченнән,
Утлы газап өчен
Тагын терелеп,
Күтәрелә.

Гретхен

Китим моннан!
Әйтерсең, бу орган минем
Сулышымны буа.
Йөрәгемне
Бу җыр әрнетә.

Хор

Judex ergo cum sedebit,
Quidquid latet, adparebit,
Nil inultum remanebit.

Гретхен

Миңа шундый тар!
Бу таш диварлар
Кыса мине!
Түшәмнәре
Баса!—тын кысыла!

Явыз рух

Кач моннан! Язык һәм оят
Кача алмый.
Яктылык? Һава?
Хәсрәт сиңа!

Хор

Quid sum miser tunc dicturus,
Quem patronum rodaturus,
Qum vix justus sit securus?

Явыз рух

Йөзләрен чөйрәләр
Изгеләр синнән,
Кул сузарга куркалар
Сиңа пакь җаннар!
Хәсрәт!

Хор

Quid sum miser tunc dicturus?

Гретхен

Куршем! Шешә бир!
(*Һушсыз егыла.*)

ЕГЕРМЕ БЕРЕНЧЕ СЦЕНА

Вальпургия төне[89]

Гарц таулары, Ширке һәм Эленд[90] тирәсе.

Фауст һәм Мефистофель

Мефистофель

Телисеңдер бәлки бер себерке сабын?
Кәҗә тәкәсе бит аның бигрәк шәбе.
Барасы юл озын әле тагын.

Фауст

Яхшы сизгән чакта көчен аякларның,
Шул таягым җиткән әле.
Юл кыскартып соң ни файда! —
Борылмалы болын буйларында йөрү,
Шушы биек кыяларга мену, —
Күбекләнеп, аннан мәңге чишмә ага, —
Бу сәфәрнең чын рәхәте менә кайда!
Яшел каенда яз бөреләнә,
Язны сизә наратлар да;
Ул безнең дә буыннарга үтмәс мәллә?

Мефистофель

Ерак миннән болар бар да.
Кыш урнашкан минем тәнемә,
Мин яратам карга күмелгәнен юлның.
Бик соң гына нинди моңлы күтәрелә
Кимеп барган кызыл ай да, сибеп нурын.
Яктысы аз ләкин, мөмкин һәр адымда,
Ташка абынып, очып китәргә түбәнгә!
Рөхсәт ит чакырып алырга, —
Адашкан ут матур яна, әнә.[91]
Әй син, дускай! Килче тизрәк безнең янга!
Бушка нурың чәчеп йөрмә анда!
Яктырт безгә, озат югарыга.

Адашкан ут

Тырышырмын, чөнки сезгә зур хөрмәтем,
Шәт буйсыныр җиңел табигатем, —
Безнең гадәт — борылмалы юллар гына.

Мефистофель

Әһә, маймыл! Үрнәк аласың кешедән.
Тиз бул, кушам шайтан исеме белән!
Ут җаныңны сүндерермен юкса, өреп.

Адашкан ут

Күрү белән үз хуҗаңны була белеп.
Мин хәзермен хезмәтегезгә!
Тик белегез, тауда бүген сихер тулы,
Һәм күрсәтсә адашкан ут сезгә юлны,
Артык төгәллекне көтмәгез дә.

Фауст, Мефистофель, Адашкан ут

(*алмашлап җырлыйлар*)

Хыял, сихер сфераларына
Килеп кердек бугай инде,
Тырыш дөрес юл алырга;
Тизрәк кенә күрсәк иде
Ерактагы киң чүлләрне!

Бер-бер артлы, кара әле,
Узып китә агачлары,
Иелгән күк тау башлары,
Озын борыны кыяларның,
Ишет, көчле мышнаганын!

Агач һәм таш асларыннан
Гөрләвекләр ашыгып ага.
Чылтыраумы? Җырмы анда?
Саф мәхәббәтнең зарымы,
Әллә күкләр авазымы?
Безнең сөю! Безнең өмет!
Яңгырады шулар бар да,
Борынгы бер әкият кебек.

Уһу! Ябалак якында,
Бер кычкыра, тагын тына,
Йокламаган күкшә, бибек.
Саламандралар бар тагын!
Аяк озын, корсак калын!
Тамырлар нәкъ елан сыман,
Таштан, комнан, үрелеп чыга,
Сәер төенләнеп тора —
Туктатырга безне юлдан.
Яшәргән зур ботаклардан
Сузыла юлчыларга табан
Озын җепләр. Һәм тычканнар —
Чуар көтү кебек алар
Мүктә һәм куе чирәмдә;
Якты кортлар йөри очып,
Бер-берсенә кысылышып,
Адаштырып, без килгәндә.

Әйт, без барабызмы алга,
Бер урындамы һаман да?
Әйләнгәндәй — бар да, бар да,
Таш һәм агач теш ыржайта,
Ялган утлар һаман арта,
Үсә, күперенә бара.

Мефистофель

Итәгемә тотын, калма!
Без хәзер нәкъ урта тауда,
Анда Маммон ялтырый,
Күргән кеше аптырый.

Фауст

Нинди сәер булып аланнарга
Моңсу, кызгылт нурлар түгелгән,
Балкый алар текә таш ярларда,
Кире кайтып упкын төбеннән.

Анда авыр исләр, монда томан,
Сөрем аша ләкин балкый нур,
Сузыла ул, нечкә җепләр сыман,
Чишмә булып бәреп ташый ул.
Йөз тармаклы иркен юллар ала
Ул үзенә матур болында,
Тагын кысылып, бергә кушылып ага,
Тар елгалар булса юлында.
Чаткы чәчри бездән якын гына,
Сибелә кебек комның алтыны.
Күрче! Анда кинәт биек кыя
Зур, мәһабәт булып балкыды.

Мефистофель

Балкымасмы әллә шулай анда
Бәйрәмнәрдә Маммон сарае?
Бәхетең бар, син дә күрдең аны;
Сизәм, агыла бире шашкын кунаклар да.

Фауст

Котырына җил, чик юк аның һич көченә,
Ничек китереп бәрә муен тамырына!

Мефистофель

Тотын кыяларның кабыргаларына
Мәтәлерсең юкса упкынның эченә.
Төн күмелде ич томанга,
Нинди чытырдый урманда!
Куркып оча ябалаклар,
Чатныйлар баганалар
Мәңге яшел сарайда.
Куаклар сына анда.
Агачлар сыкрап авалар,
Тамырлары сызланалар.
Коточкыч бу җимерелүдә
Барсы ава шунда бергә,
Һәм тар елгалар эчендә
Җилләр улый бар көченә.
Нинди авазлар бар, тыңла,
Еракта һәм бик якында?
Әйе, бүген бөтен тауларда
Сихерле җыр, котырып, тарала!

Убырлар

(*хор белән*)

Безнең Брокенга барыш!
Уҗым яшел, сары—арыш.
Һәркем бүген бара шунда,
Тәхетендә Уриан[92] була.
Таш һәм тамыр — юлның барсы,
Кәҗә тәкәсе бик сасы.

Аваз

Баубо[93] карчык ялгыз калган,
Ана дуңгызга атланган.

Хор

Кем хөрмәтле — хөрмәт аңар!
Баубо карчык, син алдан бар!
Дуңгызы шәп, үзе ана,
Артыннан убырлар бара.

Аваз

Син кайсы юлдан?

Аваз

Ильзенштейн[94] турыннан.
Оясында бер ябалак күрдем үзем.
Акайтты ул ике күзен!

Аваз

Кая болай чабасың?
Җәһәннәмгәме барасың?

Аваз

Битемнән тырнап алды,
Күр, ничек яралады!

Убырлар

(*хор белән*)

Юл киң, юл бик ерак тагын,
Бу нинди бер ярсу ташкын?
Сәнәк-чәнчи, тырма-тырный;
Бала — үле, ана улый.

Баш сихерче

(*ярым хор*)

Без әкәм-төкәмдәй барганда,
Хатын-кызлар барсы алда,
Бозык бер йортка барганда
Мең адымга алар алда.

(*икенче ярым хор*)

Ис китмәсен моңар бер дә,
Бер хатын мең атлап йөгерә;
Аның бар йөгереп килгәне —
Ирнең тик бер сикергәне!

Аваз

(*югарыдан*)

Килегез монда, тау күленнән!

Аваз

(*түбәннән*)

Менәр идек чын күңелдән!
Без юындык, ап-ак булдык һәммәбез дә,
Тик җимеш юк мәңге бездә.

Ике хор бергә

Йолдыз сүнде, давыл тынды,
Моңлы ай инде юк булды.
Сихерле хор гүли һаман,
Мең-мең чаткы чәчри аннан.

Аваз

(*түбәннән*)

Тукта! Тукта!

Аваз

(*югарыдан*)

Упкыннан кем чакыра юкка?

Аваз

(*түбәннән*)

Алсагызла мине дә!
Нәкъ өч йөз ел бирелә

Азапланам, менә алмыйм тауга,
Үз ишемне табар идем анда.

Ике хор бергә

Атлан кәҗә тәкәсенә,
Сәнәк, таяк, себеркегә!
Кем бүген дә менми калыр,
Мәңгелеккә ул югалыр.

Ярым убыр
(*түбәннән*)

Өстерәләм күптән бирле,
Бүтәннәр бик ерак инде!
Өйдә тынычлана алмыйм,
Үзем һаман алга бармыйм.

Убырлар хоры

Май ягу дәрт бирә икән,[95]
Иске чүпрәк — яхшы җилкән,
Һәр тагарак — бик шәп көймә,
Очмый калган очар, димә.

Ике хор бергә

Тизрәк менеп җитик тауга,
Утырырбыз җиргә анда,
Агач, үлән күмелер бергә
Убырларның өерендә.

(*Җиргә төшәләр.*)

Мефистофель

Кыса, төртә, шаулый, кабалана!
Сызгыра һәм үкерә, акыра бар да!
Аңысы яна, моңысы сасы!
Бу — чын убырлар доньясы.
Миңа тотын тизрәк, аерылганчы!
Син кайда соң?

Фауст

(*еракта*н)

Монда!

Метистофель

Инде аерылдың да?
Хуҗа булыйм ахыры үзем мин тагын да.
Юл бирегез! Фоланд[96] килә. Юл бирегез!

Тотын миңа, доктор! Хәзер сикерербез.
Бу кысрыктан читкә бик тиз генә.
Кыен монда хәтта минем шикеллегә.
Нәрсә анда башкача бер якты бирә,
Никтер ошый шул куаклык күңелемә.
Сикрәм шунда, калма син дә!

Фауст

Каршылыклар рухы! Йөр! Син хуҗа юлда.
Тик акыллы эш буламы, уйлап кара:
Вальпургия төнне Брокенга бара —
Яшеренергә куе куаклыкта шунда.

Мефистофель

Күрче, анда чуар утлар бар!
Дәртле клуб — килгән кунаклар.
Без дә ялгыз булмас идек анда.

Фауст

Күңел тарта мине биек тауга!
Ут һәм төтен аннан күренә, әнә.
Явызлыкка ничек ашыга бар да,
Бик күп табышмаклар чишелер анда.

Мефистофель

Һәм бик күбе шунда төенләнә.
Олы дөнья анда гүли бирә,
Без гәпләшик шушы тыныч җирдә.
Күптән мәгълүм һәркем өчен дә:
Кече дөньялар ярала зур эчендә.
Күр, бер убыр кызы, ялангач ул,
Убыр карчык акыллы киенгән,
Каршыла син якты чырай белән,
Азабы аз, кызыгы зур!
Мин ишетәм, музыка да уйный анда.
Ямьсез тавыш! Күнегергә кирәк аңа.
Киттек, әйдә! Башкача юл юк дип беләм,
Синең белән шунда барып керәм,
Кунакларга сине тәкъдим итәм.
Ни диерсең, дустым? Киң бит урын.
Чикләренә күз дә җитми моның.
Йөзләрчә ут тезелеп киткән.
Бии, эчә, сөя, сөйли бар да, —
Шуннан да шәп, булыр кайда?

Фауст

Син соң анда ничек керергә тиешле,
Бер сихерче төсендәме, җен килешме?

Мефистофель

Инкогнито[97] йөрү минем гадәтем ул,
Тик бәйрәмдә орденны тагу кирәк шул.
Тез тасмасын[98] такмыйм әле,
Ләкин монда ат тоягы бик хөрмәтле.
Күрәсеңме, әкәм-төкәм монда килә,
Мөгезләрен сузып алга,
Кемлегемне ахры инде сизә.
Теләсәм дә, яшереп булмас, белер бар да.
Киттек! Күңел ачыйк, уттан утка йөреп,
Мин — димләүче булам, ә син кияү егет.

(*Сүнеп барган күмер янында утыручы кайберәүләргә.*)

Нәрсә, картлар, болай читтә утырасыз?
Мактар идем, сез уртада кысылышсагыз
Шаулы яшьләр тирәсендә.
Ялгызлык бит өйдә дә бик җиткән безгә.

Генерал

Кем ышана алыр халыкларга?
Эшләдем мин аларга барсын да,
Тик хатын-кыз һәм халык каршында
Яшьләр генә һаман тора алда.

Министр

Хәзер һәркем язды тугры юлдан,
Үткәннәрне мактыйм мин һаман,
Килә иде бар да безнең кулдан,
Алтын иде, чыннан, ул заман.

Парвеню[99]

Без дә түгел идек тиле,
Еш эшләдек кирәкмәгәнне дә;
Ләкин хәзер эшләр китте кире,
Эшне җайлыйк дигән мәлдә генә.

Автор

Акыллы һәм яхшы китапларны
Кемнәр генә укыр хәзер инде!

Бөтен яшьләр шундый начарланды,
Һичкайчан да алай булганы юк иде.

Мефистофель

(*кинәт ул бик карт күренә.*)

Әйе, халык мәхшәр көненә бара,
Соңгы тапкыр мендем убырлар тавына,
Минем мичкәм төссез ага,
Димәк, җитә заман ахыры да.

Иске-москычы убыр карчыгы

Әфәнделәр, тиз килегез!
Йоклап калмагыз тагын!
Иң шәпләре миндә товарларның,
Төрлесеннән бар, күрегез!
Бай кибет бу, чиктән ашып киткән,
Җир йөзендә тиңдәш юк аңа,
Андагы һәрнәрсә зарар иткән
Кешеләргә, бөтен дөньяга.
Андагы һәр хәнҗәрдән ал каннар тамган,
Күпме касә булса анда, алар бары
Сау күкрәккә зәһәр агу салган;
Андагы һәр бизәк матур хатыннарны
Аздырган, һәм һәрбер кылыч, качып анттан,
Дошманына кадалган ул, килеп арттан.

Мефистофель

Апа! Начар аңлыйсың син заманны
Эшләнгән эш — үткән бар да!
Эзләп тап син яңаларны,
Кызыктыра тик өр-яңа.

Фауст

Үз-үзеңне монда онытырсың,
Базар булса, менә шундый булсын!

Мефистофель

Бөтен ташкын агыла өскә табан,
Этәм дисең, этәрәләр сине һаман.

Фауст

Монысы кем соң?

Мефистофель

Ныклап кара: Лилит.[100]

Фауст

Кем?

Мефистофель

Адәмнең иң беренче хатыны бит.
Кагылмасын сиңа матур толымнары,[101]
Шулар гына гүзәллек тә бирә аңа,
Шулар белән яшь егетне чолгап ала
Һәм җибәрми бик тиз генә тагын аны.

Фауст

Әнә анда утыра карчык яшь кыз белән,
Арган алар инде бик күп сикерүдән!

Мефистофель

Бүген тынычлык белмиләр.
Кушылыйк без дә, хәзер яңадан бииләр.

Фауст

(*яшь кыз белән бии.*)

Мин бик матур бер төш күрдем,
Алма агачына мендем,
Балкып торган ике алма
Үзенә тартты мине анда.

Сылу

(*бии.*)

Сезгә алма ошый һаман,
Оҗмахта да ул алдаган.
Мин шат, минем бакчамда да
Сезнең өчен табылыр алма.

Мефистофель

(*карчык белән бии.*)

Мин бик кызык бер төш күрдем,
Агач куышына кердем;
Ул үзе бик ямьсез иде,
Кызыктырды ләкин мине.

Карчык

Сәлам сезгә, сәлам тагы,
Ат тоягы рыцаре!
Куыш ошый икән сезгә,
Булсын, әйдә, үзегезгә!

Проктофантасмист[102]

Мәлгун нәсел! Масаеп йөрисез!
Билгеле ич инде бик күптәннән:
Чын аяклар рухларга бирелмәгән.
Ә монда сез нәкъ кешеләр күк биисез!

Сылу

(*бии.*)

Ник килгән ул безнең балга?

Фауст

(*бии.*)

Әй, була ич ул һәркайда!
Гаепли ул безне биегәнгә,
Бер адымны күрмәсә әгәр дә,
Аныңча, ул адым атланмаган.
Алга барган өчен тирги тагы да яман.
Бер урында әйләнсәгез сез һаман да,
Ул үзенең иске тирмәнендә сыман,[103]
Мактар иде сезне, чыннан,
Бигрәк тә, сез рәхмәт дисәгез аңар да.

Проктофантасмист

Сез әле дә монда? Ишетелмәгән хәлләр!
Югалыгыз, аңласагыз сүзне әгәр!
Хәзер җеннәр кагыйдәне санлый белми!
Без акыллы, ә Тегельдә өрәк йөри![104]
Тинтәклектән тазартам мин күптән, мәгәр
Саф түгел һич! ишетелмәгән хәлләр!

Сылу

Ул соң үзәккә үтүдән кайчан тынар?

Проктофантасмист

Рухлар, сезгә ачык сөйлим!
Рухның деспотлыгына мин түзә белмим;
Өйрәнмәгән минем рухым моңар.

(*Бию дәвам итә.*)

Бүген эшләр барып чыкмас, бик беләмен,
Ләкин юлда булачакмын мин тагын да.
Өмет итәм, соңгы адымымда
Шайтанны да, шагыйрьне дә бер җиңәрмен.

Мефистофель

Бер пычракка утырыр ул, китеп моннан,
Үзен-үзе дәвалавы шулай аның,
Сөлекләр бер туйганчы имгәч арт ягын,
Котылыр ул рухлардан һәм үз рухыннан.

(*Биючеләр арасыннан киткән Фаустка*)

Нигә алай китеп бардың син кызыңнан?
Шәп җырлады ич янында!

Фауст

Ах! Ул җырлаган чагында
Кызыл тычкан сикереп төште авызыннан.[105]

Мефистофель

Менә кызык! Юкка исең киткән.
Соры түгел—шунсы җиткән.
Сөешкәндә сорап тормам аны, чыннан!

Фауст

Һәм күрдем мин—

Мефистофель

Нәрсә?

Фауст

Мефисто, кил, кара,

Бик ерактан бер кыз бала килә аннан,
Чырае ак, әкрен бара,
Әйтерсең лә, аягына йозак салган.
Аны моннан була танып,
Гретхен ул, әйтәм анык.

Мефистофель

Калдыр аны, рәхәте юк һичбер кемгә:
Бер шәүлә ул, җансыз гәүдә, сихер генә.
Һич яхшыга булмый аны очратканың,
Аның салкын карашыннан туңа каның,
Әйләнәсең ташка шул урында;
Ишеткәнең бардыр Медуза[106] турында.

Фауст

Юк, чынлап ул, тонган үлек күзе,
Йомдырмаган аны сөйгән кул,
Мине кыскан күкрәккәйнең нәкъ шул үзе,
Миңа тирән ләззәт биргән зифа тән ул.

Мефистофель

Тик сихер ул, алданма син, тинтәк булма!
Һәр кеше дә үз сөйгәнен күрә шунда.

Фауст

Шашкын бер дәрт! Әрнеп янам эчтән!
Аерыла алмыйм һич тә ул күренештән.
Нинди сәер, аның матур муены
Бизәлгән бер кызыл тасма белән,
Киң түгел ул хәнҗәр йөзеннән.

Мефистофель

Дөрес! Мин дә күрәм моны.
Йөри кайчак башын култыгына алып,
Чөнки Персей аны өзгән чабып.
Омтыласың юк хыялга!
Меник тизрәк биек тауга,
Бик матур ул, нәкъ Пратер![107]
Әллә күзләрем алдана? —
Анда чыннан да, театр.
Нәрсә бара?

Servibilis[108]

Хәзер яңадан башлана.
Яңа әсәр, алар җиде әсәр бары, —
Бездә шулай күп язарга өйрәнгәннәр.
Бер һәвәскәр язган аны,
Һәм уйныйлар һәвәскәрләр.
Гафу итегез, әфәнделәр, сездән китәм:
Мин һәвәскәр — пәрдә күтәреп торырга.

Мефистофель

Блоксбергта сезне очратам икән,
Бик яхшы бу: сез бит нәкъ урнында.

ЕГЕРМЕ ИКЕНЧЕ СЦЕНА

Вальпургия төнендәге төш яки Оберон белән Титаниянең[109] алтын туе интермеццо

Театр директоры

Бүген без ял итәбез,
Мидингның уллары.[110]
Безнең бөтен сәхнәбез —
Болын һәм тау буйлары.

Герольд

Алтын туй булсын өчен
Илле ел гомер кирәк.
Бәхәстә бетмәс көчем:
Алтын бит кадерлерәк.

Оберон

Күренегез сез миңа,
Монда нинди рухлар бар!
Король һәм королева
Яңадан кушылганнар.

Пук

Пук килә, кызык эзләп,
Аякны матур баса,
Аңар иярүче — йөзләп,
Һәммәсе күңел ача.

Ариэль

Ариэльнең җырлары
Бигрәк матур бары да,
Сихерле ич моңнары
Карчык һәм кызларны да.

Оберон

Ир-хатын! Шәп яшәргә
Бездән үрнәк алыгыз!
Сөям дисәң әгәр дә,
Башта аерылыгыз.

Титания

Хатын — усал, ир — яман,
Аерылсыннар ул чакта!

Төньякка ир китсен аннан,
Хатын китсен көньякка!

Оркестр

(*tutti, fortissimo*)

Чебен авызы, черки борыны,
Һәм якын туганнары,
Чикерткә һәм бака хоры —
Шәп бит музыкантлары!

Solo

Әнә волынка бара,
Сабын күбегесыман;
Бар җиргә мышнау тарала,
Тыңкыш, юан борыннан.

Яңа барлыкка килгән рух

Үрмәкүчнең аягы,
Һәм корсагы баканың, —
Әзер түгел хайваны,
Шигыре әзер аның.

Егет һәм кыз

Вак баса, киң сикерә
Бал чыгында тауларда;
Җирдә шәп йөри белә,
Оча алмый һавада.

Кызыксынучан юлчы

Бер маскарад мәллә монда!
Ышаныйммы күземә?
Гүзәл тәңре Оберон да
Килгән бүген үзе дә!

Ортодокс

Тырнак, койрык юк берсе, —
Шикләнмәгез сез моңа:
Юнан аллалары төсле,
Бу да бер шайтан гына.

Төньяк художнигы

Бүген монда ни табам? —
Бар да эскизләр генә;

Хәзерлек алып барам
Италия сәфәренә.

Пурист

Ах! Бәхетсез мин һаман!
Азгынлык бу барсы да:
Тик икәү пудраланган
Күп убыр арасында!

Убыр кызы

Картларга һәммәсе дә—
Кием дә һәм пудра да,
Мин кәҗә тәкәсендә
Ялангач барам, кара!

Убыр карчыгы

Бездә шактый тәҗрибә бар,
Бәхәсләшмик, белерсең,
Яшь әле син, мактанып кал,
Көне килер,—черерсең.

Капельмейстер

Күпме чебен, черки бар—
Сырмагыз ялан тәнне!
Чикерткәләр, бакалар,
Хорны бозмагыз әле!

Флюгер

(*бер якка*)

Нинди матур халык монда,
Карап туймас күзләрең!
Егетләр дә, кызлары да
Иркен тота үзләрен.

Флюгер

(*икенче якка*)

Җир ярылып, барысын бергә
Йотмый икән әгәр дә,
Мин хәзермен сикерергә,
Коточкыч җәһәннәмгә.

Ксениялəр

Черкилəрдəй җыелып килдек,
Үткер уклы һəммəбез;
Иблискə дан булсын, дидек,
Ул бит безнең əткəбез.

Геннингс[111]

Нинди кысрык, күр, анда,
Нинди гамьсез уйныйлар!
Үз җаннарын алар да
Бик яхшы дип уйлыйлар.

Музагет

Убырлар арасында
Мəңгегə калыр идем:
Җиңел монда барсы да
Музаларымнан минем.

Ci-devant[112] заманадаһие

Яхшылардан үрнəк алчы,
Тотын үземə, калма!
Брокен—немецлар Парнасы,[113]
Тау башы бик киң анда.

Кызыксынучы юлчы

Монысы кем, каты басып,
Бик эре атлап йөри,
Һаман эзлəнə, ярсып,
„Иезуитлар юкмы?" ди.

Торна

Балыкны мин тота алам,
Тонык һəм саф суларда.
Җеннəр арасында калган
Нинди инсафлылар да.

Дөнья баласы

Инсафлылар, динлелəр
Бик талымсыз булалар;
Шушы Брокен җирендə
Собор җыярлар алар.

Биюче

Əллə яңа бер хор тагын?—
Барабан тавышлары.

Бу—җырлавы бакаларның,
Шаулый саз камышлары.

Танцмейстер

Тыпырдыйлар, ду киләләр,
Берсе дә читтә калмый;
Бөкреләр дә сикеренәләр,
Ничек чыкса да ярый.

Скрипкачы

Берсен-берсе бу йолкышлар
Ашап бетерер иде;
Тик аларны уен куша,
Орфей җыры шикелле.

Догматик

Тәнкыйть куркытмый бер дә,
Шөбһә борчымый мине,
Бер нәрсәдер бит җен дә,
Юкса җен булмас иде.

Идеалист

Бүген фантазиям киң,
Белмим, чиге бардырмы.
Булсам әгәр барсы мин,[114]
Югалттымдыр акылны.

Реалист

Барсы—газап дип аңлыйм,
Ачуланам кайчакта;
Нык басып тора алмыйм
Беренче кат аякта.

Супернатуралист

Рәхәтләнеп торам монда,
Шатланам, барсын күреп,—
Җенгә карап, мөмкин була
Яхшы рухларны белеп.

Скептик

Бара алар ут артыннан,
Мал табып, бай булырга.
Рифмалаша: „шайтан“—„ялган“,
Монда мин нәкъ урнында.

Капельмейстер

Чикерткә һәм бака хоры,
Надан һәвәскәр бары,
Чебен авызы, черки борыны—
Шәп бит музыкантлары!

Җиңел куллар

Без һәммәбез шат җаннар,—
Sans souci исеме бирелгән;
Йөрми инде аяклар,
Без йөрибез баш белән.

Булдыксызлар

Мал артыннан чабып гомер узды,
Алсын аны аллабыз!
Безнең итек биеп тузды,
Ялан тәпи барабыз.

Адашкан утлар

Сазлыклардан без килдек,
Анда—туган илебез;
Монда сафка тезелдек,
Сезгә якты бирербез.

Атылган йолдыз

Мин биектән атылдым,
Балкып, көчле нур сибеп.
Ятам җирдә ялгызым:
Кем ярдәм итәр, килеп?

Авыр гәүдәлеләр

Урын бирегез киң итеп!
Җиргә иелсен үлән!
Рухлар килә, рухлар килә—
Авыр тәннәре белән.

Пук

Ябырыласыз алай нигә,
Фил көтүләресыман?
Мин, таза Пук, бүген үзем
Юан булыйм барсыннан!

Ариэль

Кемгә бирелгән канатлар
Табигатьнең үзеннән,
Гөл тавына очсын алар
Минем җинел эземнән!

Оркестр

(*Pianissimo*)

Менә томан тарала,
Болыттан күк арчыла.
Җил уйный камышларда,—
Һәм юк булды барсы да.

ЕГЕРМЕ ӨЧЕНЧЕ СЦЕНА

Кояшсыз көн. Кыр.

Фауст. Мефистофель

Фауст

Бәхетсезлектә! Өметсезлектә! Кызганыч хәлдә озак адашып йөргән ул җир йөзендә, ә хәзер—ябылуда! Җинаятьчене япкан төсле, зинданга, коточкыч газапка салганнар аны, бәхетсез, сөйкемле баланы!—Ә син, хыянәтче, игелексез рух, син шуны яшергәнсең миннән!—Тор шунда, тор! Башыңдагы җен күзләреңне, явызланып, тирә-якка акайт! Тор шунда һәм газапла мине үзеңнең кеше чыдамаслык рәвештә каршыда торуың белән! Ябылуда! Әйтеп бетермәслек бәхетсезлектә! Явыз рухлар кулында ул һәм гадел хөкемне белмәүче кешелек кулында! Ә син мине шундый чакта әшәке күңел ачуларда тирбәтәсең, аның һаман үсә барган зарын миннән яшерәсең һәм аны ярдәмсез һәлак булуга дучар итәсең!

Мефистофель

Ул беренче түгел.

Фауст

Эт син! Җирәнгеч хәшарәт! О син, чиге булмаган рух,[115] кайтар яңадан аны, кайтар шул кортны, үзенең эт кыяфәтенә,[116]—ул бик еш кына, төннәрен шул кыяфәткә кереп, минем тирәдә йөрергә, гамьсез юлчының аяк астында бөтерелергә һәм егылып баручының җилкәсенә

сикерергә ярата иде. Кайтар син аны яңадан үзенең сөйгән кыяфәтенә,—ул минем алдымда туфракта аунасын һәм типкәләп йөртим мин аны, дәргаһдан сөрелгәнне! Беренче түгел! Хәсрәт! Хәсрәт! Моңар һичбер кеше җаны чыдамас—шундый бәхетсезлек упкынына бер генә кыз батмаган, һәм иң беренчесе мәңге ярлыкаучы каршында, үзенең ачы үлем газабында бүтән барсының да гөнаһларын йолмаган! Шул берәүнең бәхетсезлеге минем тереклегем һәм мием аша әрнетеп үтә, ә син тыныч көләсең меңнәрнең язмышыннан!

Мефистофель

Менә без тагын үткер акыллылыкның чигенә килеп җиттек, анда җиткәч, сезнең, кешеләрнең, акылыгыз югала. Ахырына хәтле бара алмыйсың икән, нигә син безгә кушыласың? Үзең очарга телисең, үзең баш әйләнүдән куркасың? Без сиңа омтылдыкмы, син безгәме?

Фауст

Бирән тешләреңне миңа алай ыржайтма! Җирәнәм!—О син, бөек һәм кодрәтле рух, мине син үзеңне күрүгә лаек иттең, син минем йөрәгемне дә, җанымны да беләсең, нигә син мине шушы хурлыклы иптәшкә беркеттең, ул бит зарар эшләүдән кызык таба һәм һәлакәттән ләззәт ала!

Мефистофель

Бетердеңме?

Фауст

Коткар аны! Яки хәсрәт сиңа! Иң авыр нәләт сиңа мең, мең елларга!

Мефистофель

Үч алучының бауларын мин чишә алмыйм, аның йозакларын ача алмыйм.—Коткар, имеш, аны!—Ә соң аны һәлакәткә өстерәүче кем иде? Минме әллә синме?

(*Фауст, шашынып, тирә-ягына карый.*)

Яшеннәрне тотып алмакчы буласыңмы? Ярый әле, аларны сезгә, мескен үлем ияләренә, бирмәгәннәр! Каршы бер сүз әйткән гаепсезне теткәләп ташлау, бу—тираннар эше, аптырашка калганда шулай итәләр алар.

Фауст

Илт мине шунда! Ул азат булырга тиеш!

Мефистофель

Син үзеңне куркыныч астына куясың! Шуны бел: синең кулың белән эшләнгән канлы җинаять шәһәр естендә тора әле. Кеше үтерелгән урын турында үч алучы рухлар очалар һәм үтерүченең кайтуын сагалыйлар.

Фауст

Моны, җитмәсә, син әйтәсең? Бөтен дөньядагы үтерелү һәм үлем—синең өстеңә! Илт мине шунда, диләр сиңа, һәм коткар аны!

Мефистофель

Ярый, илтермен, ләкин мин нишли алам, тыңла! Күкнең һәм җирнең бөтен көчләре минем кулымдамыни? Мин зиндан сакчысының акылын оетырмын, син ачкычларны ал да, кызны кеше кулы белән ирекка чыгар! Мин сакта торырмын, тылсымлы атлар хәзер булыр һәм сезне алып китәрмен. Моны мин булдыра алам.

Фауст

Киттек—һәм хәзер үк!

ЕГЕРМЕ ДҮРТЕНЧЕ СЦЕНА

Төн. Ачык кыр.

Фауст һәм Мефистофель кара атларда очып баралар.

Фауст

Нишлиләр анда, дар агачы янында?[117]

Мефистофель

Белмим, нәрсә пешерәләрдер, нишлиләрдер.

Фауст

Бер менәләр, бер төшәләр, сыгылалар, бөгеләләр.

Мефистофель

Ырымлыйлар.

Фауст

Нидер сипкәлиләр, изгелиләр.

Мефистофель

Узып киттек!

ЕГЕРМЕ БИШЕНЧЕ СЦЕНА

Зиндан

Кулына ачкычлар бәйләме һәм лампа тоткан Фауст бер тимер ишек алдында басып тора.

Фауст

Күптән онытылган курку чолгап ала,
Мин җыйганмын кешелекнең бөтен зарын.
Бикләнгән ул шушы юеш диварларга,
Җинаяте — якты акылсызлык аның!
Ашыкмыйсың ник керергә?
Куркамсың аны күрергә?
Үлем көтә — каушап торма тагын!

(*Йозакка тотына.*)

Эчтә җыр

Фахишә анам
Һәлак итте бит;
Юньсез әткәем
Ашап бетерде!
Ә сеңелкәем
Сөякләремне
Яшерде кырга;
Матур урман кошы мин,
Очам, очам моннан!

Фауст

(*йозакны ача.*)

Сизми дә ул, дусты тыңлап тора аны,
Кыштырдый тик салам, чыңлый богаулары.

Маргарита

(*урынында яшеренә.*)

Хәсрәт! Ачы үлем килде!

Фауст

Әкрен! Сине коткарырга киләм.

Маргарита

(*аның аякларына егыла.*)

Кеше булсаң әгәр, кызган мине!

Фауст

Уятырсың сакчыларны тавышың белән!

(*Бикләрен ачарга теләп, зынҗырларга тотына.*)

Маргарита

(*тезләнеп*)

Кем сиңа, җәллад, көч бирде
Миннән көләргә?
Төнемне дә алма инде!
Кызган, теләмим шул мин үләргә!
Иртә таңнан килсәң җитмәгәнме?

(*тора.*)

Мин яшь әле, бик яшь әле!
Һәм үләргә тиешмен!
Матур идем, һәлакәтем шуннан минем,
Бар иде дус, ул еракта,
Чәчәкләрем чәчелеп ята төрле якта.
Мине алай каты тотма, зинһар!
Кызган! Сиңа нинди зарарым бар?
Бушка ялындырма инде,
Үз гомеремдә беренче кат күрәм сине!

Фауст

Аһ, бу газап үтерә мине!

Маргарита

Мин хәзер синең иркеңдә.
Тик бер генә имезим баламны.
Тирбәттем мин аны шушы озын төндә.
Газапларга мине, алар алды аны.
Һәм әйтәләр, имеш, аны мин үтердем.
Һичкайчан да мин шат булмам.
Минем турда җыр җырлыйлар! Аһ, нинди усаллар.
Элек шундый әкият булган;
Ә соң нәрсә белә алар?

Фауст

(*аның аякларына ташлана.*)

Күр, аягыңда сөйгән ярыңны
Өзәр ул тимер богауларыңны.

Маргарита

(*аңар ташлана*)

О, тезләник, ялварыйк без изгеләргә!
Баскыч астында, күр, әнә,
Һәм бусагада —
Тәмуг дөрли анда!
Җен килгән,
Коточкыч акыра,
Көлә ул миннән!

Фауст

(*кычкырып*)

Гретхен! Гретхен!

Маргарита

(*тыңлап*)

Дустым тавышы, ул чакыра!

Сикереп тора, зынҗырлары төшә.

Кайда соң ул? Ишетәм чакырганын.
Мин азат! Кем киртә салыр тагын?
Асылынсамчы аның муенына,
Ятса идем куенында!
Гретхен! — дип кычкырды ул бусагада,
Анда тәмуг үкергәндә, улаганда,
Иркәмнең мин матур тавышын танып алдым,
Җиңде изге аваз җеннәр акырганын.

Фауст

Бу мин!

Маргарита

Бу син? Тагын бер кабатла!

(*аны кочаклый.*)

Бу син! Кайда әрнү, газап бар да?
Кайда зынҗыр, кайда зиндан куркынычы?
Бу син! Син киләсең, минем коткаручым!
Мин азат! — Һәм мин яңадан бу урамда,
Беренче кат сине күргән идем анда,
Марта белән бергә
Көтә идем шул бакчада сине көн дә.

Фауст

(*аны алга өстери.*)

Киттек! Киттек!

Маргарита

Тукта, җаным!
Нинди рәхәт миңа, син дә булгач.

(*Иркәләнә.*)

Фауст

Ашык! Тагын болай озак торгач,
Туры килер бик кыйбат түләргә.

Маргарита

Теләмисең мине син үбәргә?
Киткәнеңә әле күптәнме,
Онытмансың ничек үпкәнне!
Ник куркыныч синең кочагыңда!
Бер каравың, тик бер җылы сүзең синең
Оҗмах бәхетен бирә иде ул чагында,
Буам сине, дигән төсле үбә идең.
Үп мине!
Яки үзем үбәм сине!

(*Кочаклый.*)

Һәйһат! Иренең шундый салкын,
Тынган.
Кайда соң синең
Сөюең?
Кем мине бу хәлгә куйган?

(*Аннан читкә китә.*)

Фауст

Киттек! Бәгырем, әйдә, калма миннән!
Сөям сине сүнмәс ялкын белән!
Калма миннән! Үтенәм шуны, калма!

Маргарита

(*аңар таба әйләнә.*)

Синме соң бу? Синме бу, чыннан да?

Фауст

Бу мин! Киттек!

Маргарита

Салдырдың богауны,
Күкрәгеңә кыстың мине тагы.
Курыкмыйча, ничек торасың алдымда?
Беләсеңме, кемне килдең коткарырга?

Фауст

Киттек тизрәк! Үтә бит төн.

Маргарита

Әнкәемне мин үтердем,
Баламны да батырдым шул!
Минеке — ул, синеке ул!
Синеке дә — бу соң синме?
Бир кулыңны! Төш күрмимме?
Бир сөекле кулыңны! — Ах, юеш нигә?
Ю син аны! Күрәм мин дә:
Кан бар анда.
Нишләдең син, я алла!
Кылычыңны кынына сал,
Тыңла сүземне!

Фауст

Калдыр үткәннәрне, — елап ни бар?
Һәлак итәсең бит син безне!

Маргарита

Юк, син калырга тиеш!
Һәм мин сиңа сөйләп биргән килеш,
Каберләр хәзерлә
Иртән таң беләː
Иң яхшысына әнине салырга,
Абыем кабере—аның янында,
Мине сал бер читкә,
Тик ерак китмә!
Баламны сал уң як күкрәгемә,
Бүтән кем дә булмас минем янда!
Син кадерлем мине назлаганда,
Нинди татлы, якты бәхет иде!

Инде мөмкин булмас бу кайчан да,
Көчкә торам кебек синең алда,
Этәрәсең кебек читкә мине.
Ләкин син бу, һәм карашың һаман матур.

Фауст

Мин дип белсәң, киттек,тиз бул!

Маргарита

Кая?

Фауст

Иреккә.

Маргарита

Кабер анда.
Үлем көтә, китик шул!
Моннан—мәңгелек йокыга талырга,
Ләкин артык атламам бер адым да!—
Киттең, Генрих? Булсачы бергә барырга!

Фауст

Бик мөмкин ул! Телә генә! Ишек ачык.

Маргарита

Ярамый шул; өмет беткән, булмый качып.
Ни файда бар? Анда сагалап торалар!
Яшәү авыр, садака сорап,
Һәм, җитмәсә, җанга йөк алып!
Үз иленнән читкә китеп яшәү авыр,
Һәм, барыбер, алар мине тотып алыр.

Фауст

Мин дә калам синең янда.

Маргарита

Тиз кит! Тиз кит!
Коткар, балаң бар бит!
Тиз бул син, юл ал!
Су буеннан йөр,
Күпергә бар
Һәм урманга кер,
Сул якта такта булыр,
Анда буа бар.

Тизрәк тотып ал!
Ул өскә чыга,
Тыбырчына, көч бир!
Коткар! коткар!

Фауст

Акылыңа кил!
Бер атласаң—син иректә!

Маргарита

Шул тауны үтик ничек тә!
Әнкәм утыра анда таш өстендә,
Тәнемә салкын үтә!
Әнкәм утыра анда таш өстендә
Һәм ул башын селкә;
Керфеген дә какмый, башы авыр аның,
Күптән йоклый, тормас инде тагын.
Рәхәтләндек, ул һаман да йоклый бирде.
Бәхетле заман бар иде!

Фауст

Файдасы юк ялынып сорауның,
Көч белән дә алып чыгармын.

Маргарита

Калдыр мине! Көч куллану нигә кирәк!
Кысма мине усал кеше кебек,
Мин эшләдем барсын, сине сөеп.

Фауст

Көн туа! Бәгырем! Бәгырем!

Маргарита

Көн! Әйе, көн! Туа шулай соңгы көнем!
Туй көнем шул инде минем!
Белмәсеннәр Гретхенда булганыңны.
Тапталды минем гөл!
Бетте бит бар да!
Тагын күрешербез анда;
Тик биегәндә түгел.
Халык агыла, шау-шу тынды.
Тыкрык һәм урам
Барысы тулган.
Чаң чакыра, таяк сынды.[118]

Кемдер мине бәйли, тарта,
Мин хәзер дар агачында.
Минем өчен дигән балта
Барсының да баш очында.
Кабердәй тын бөтен дөнья!

Фауст

О, тумаган булса идем!

Мефистофель

(*тыштан күренә*)

Киттек! Юкса, беттек, диген!
Озак сузма! Күп лыгырдап ни файда бар?
Минем атлар ашкыналар,
Инде таң беленә.

Маргарита

Җирдән нәрсә күтәрелә?
Ул! ул! Тормасын ул монда!
Нәрсә кирәк аңар бу изге урында?
Мин кирәк аңар?

Фауст

Яшәргә тиеш син!

Маргарита

Тәңре хөкме! Ал, дим, сиңа бирeләм мин!

Мефистофель

(*Фаустка*)

Тиз бул! Юкса, шунда ташлап китәм сине!

Маргарита

Мин синеке, ходай! Коткар мине!
Фәрештәләр, күктән сез иңегез,
Очып, миңа ярдәмгә килегез!
Генрих! Мин куркам синнән!

Мефистофель

Һәлак булды!

Аваз

(*югарыдан*)

Ул котылды![119]

Мефистофель

(Фаустка)

Калма миннән!

(Фауст белән бергә юк була.)

Аваз

(эчтән ишетелә, акрыная бара)

Генрих! Генрих!

Аңлатмалар һәм сүзлек*

„Фауст“ трагедиясенең төп образларын Гёте халык иҗадыннан, халык поэзиясеннән алган. Табигать серләренә төшенү, белем чикләрен киңәйтү, тормыш авырлыкларын җиңү өчен үзенең җанын җенгә-шайтанга сатарга хәзер торган герой образы халыкның шигъри аңында элек-электән яшәп килгән. Халык легендаларындагы Фаустның прототипы—тормышта чыннан да булган, җанлы кеше, XVI гасырның беренче яртысында яшәгән һәм магия (сихер) белән шөгыльләнгән бер галим.

„Фауст“ турындагы легенда шул чорларда туа. Бу—урта гасырларның яңа заман белән алмашыну чоры була. Халык хыялында Фауст я сихерче булып, я шагыйрь һәм гуманист булып сурәтләнә.

1587 елда Майндагы Франкфуртта Фауст турындагы легенданың Иоганн Шпис тарафыннан эшләнгән әдәби беренче китабы басылып чыга. Китапның хәзерге көндә юмор рәвешендә яңгырый торган исеме ул чагындагы дини карашларны һәм тәүфикълы булырга өндәүне чагылдыра: „Бөтен дөньяга билгеле сихерче доктор Иоганн Фауст турындагы хикәя. Аның ничек итеп шайтан белән килешү ясавы, шул вакыттан соң башыннан үткән гаҗәеп маҗаралары һәм ниһаять аның тиешле җәзасына дучар булуы турында. Күбрәк өлеше аның үзе язып калдырган әсәрләр буенча төзелде, тәүфикъсыз, әхлаксыз һәм динсез кешеләргә коточкыч гыйбрәт һәм куркынычлы сабак булсын“. Дини карашлары көчле булган автор Фаустны тәкәбберлеккә бирелде дип, “Үзенә бөркет канатларын беркетте, күкне һәм җирне нигезенә кадәр тикшерергә — белергә омтылды“ дип гаепли. Шпис хикәясендә Мефистофель, кан белән беркетелгән килешүнең вакыты чыккач, Фаустны шәфкатьсез рәвештә юк итә.

Фауст турындагы легенданың немец әдәбиятында XVI— XVII гасырларда чыккан яңа вариантлары Шпис „Фаусты“ югарылыгына күтәрелә алмыйлар.

Тик Англиядә XVI гасырның күренекле драматургы, Уяну (Возрождение) чорының вәкиле Христофор Марло гына легенданы башка төрле аңлатуда бирә. Азатлык идеяләрен кыю һәм ялкынлы рәвештә яклаучы Марло „Доктор Фаустның тормышы һәм үлеме“ дигән трагедиядә аллаларга каршы көрәшкән һәм, магиягә бирелеп, шәхесне табигатьнең иске кануннарыннан коткарырга омтылган Фаустның титаннарча образын алга китереп бастыра.

---

*Аңлатмалар М. Максуд тарафыннан төзелде, күбрәк өлеше Н. Холодковский һәм Я. Металлов буенча алынды.

XVIII гасырда, 1789 елгы француз революциясе алдыннан, искелеккә протест белдерүче галим сыйфатында Фауст аеруча популярлаша. Немец мәгърифәтчеләренең иң зурларыннан булган Лессинг „Фауст“ драмасы сызмаларында, белем комсызлыгына бирелгән галим образын тирән бер симпатия белән сурәтли. Шунысы характерлы: „Фауст“ның бу вариантында ук инде шайтанның Фаустны һәлак итәргә омтылуы алдан ук уңышсызлыкка мәхкүм була.

Һичбер төрле законнарны белми торган давыллы даһины алга сөрүче „Давыл һәм һөҗүм“ хәрәкәтенең вәкилләре, табигый, Фауст образын читләтеп үтә алмадылар. Унбиш-егерме ел эчендә „Давыл һәм һөҗүм“ драматурглары „Фауст“ның бер-бер артлы яңа вариантларын барлыкка китерәләр. 1778 елда Фридрих Мюллерның китабы чыга („Фаустның тормышы“). 1791 елда Клингерның „Фауст, аның тормышы, эшләре һәм җәһәннәмгә дучар ителүе“ дигән атаклы әсәре чыга. Клингер Фаустны XV гасырда китап басу осталарының берсе булган типографияче Фауст образында ала. Клингерның герое—белемгә, бәхеткә һәм ирекккә омтылучы даһи. Китап басыла башлауга шайтан шатлана, шушы юл белән ялган карашлар таратып һәм кешеләр арасындагы дошманлыкны көчәйтеп булыр, дип уйлый. Шайтан белән килешү ясагач, Фауст төрле илләрдәге коточкыч тәртипләр белән таныша һәм кешенең табигате бозык дигән нәтиҗәгә килә дә, өметсезлеккә бирелеп, үзен үзе шайтан кулына тапшыра.

Гёте бала чагында ук әле курчак театрларында халык легендасындагы Фауст образы белән таныша. “Давыл һәм һөҗүм“ хәрәкәтенә кушылгач, ул 1774—1775 елларда „Фауст“ның беренче вариантын яза. „Давыл һәм һөҗүм“ юнәлешенең рухына ярашлы рәвештә, бу вариантта әле Фауст—табигать законнарын белергә омтылган, ләкин, шиксез, җиңелергә мәхкүм булган бер бунтарь. Тик Гёте „Фауст“ының иң соңгы редакциясендә генә (беренче кисәге 1806 елда, икенче кисәге 1831 елда тәмам була) тормыш төзүче, иҗадчы Фауст образы барлыкка килә һәм җиңә.

Багышлау

„Багышлау“ны Гёте 1797 елда, ягъни „Фауст“ языла башлаганнан соң 23 ел үткәч язган. Үзенең яшьлек көннәрендә башлаган хезмәтенә яңадан керешкәндә, Гёте яшьлек дусларын искә төшереп, әсәрне аларга багышлый.

[1] Сез киләсез тагын, шәүләләр, чайкалып. . .— Фаустның, Маргаританың һәм Мефистофельнең шагыйрь хыялында, ул әле яшь чагында туган образлары.

[2] Эол—Борынгы юнаннарда җилләр алласы. Эол арфасы—җил искәндә гармонияле авазлар чыгара торган кыллы музыка коралы.

Театрда пролог

Пролог шул чорда немец театрында хөкем сөргән түбәнлекне һәм начар вкусларны фаш итә. Хәзер инде онытылып беткән Ифлянд һәм Коцебу кебек талантсыз язучыларның драмаларын ул чордагы театр директорлары да, публика да, Гёте һәм Шиллер әсәрләренә караганда яратыбрак, каршы ала булганнар.

[3] Рагу—вак кына итеп туралган ит һәм яшелчәләрдән хәзерләнгән ашамлык. Бу урында—төрле элементларны бергә бутаган, бөтенлеге булмаган әсәр мәгънәсендә.

[4] Бик күбесе төрле журнал укып килгән. . .— Гёте һәрвакыт газета һәм журналларның укучыларны дөрес карашларда тәрбияләмәүләрен күрсәткән.

[5] Кем өлгергән,—ярдәм итеп булмас аңар, ә кем үсә, рәхмәт әйтер ул һаман да.. — тирән философик мәгънәгә ия булган бу юлларның немецчадан сүзгә-сүз тәрҗемәсе: „Кем инде әзер (fertig), аңар бер нәрсә эшләп тә булмый, ә үсеп килүче (ein Werdendér) һәрвакыт рәхмәт әйтер". „Werden"—„становиться" фигыленең татарчасы булмау сәбәпле „үсү" дип кенә алырга туры килде. Соңгы юлны Валерий Брюсов: "Но кто становится, нас поблагодарит" дип тәрҗемә иткән. Н. Холодковский тәрҗемәсендә бу юлның мәгънәсе тәгәл бирелмәгән.

[6] Анда сезнең сәфәр тоташа күктән җәһәннәмгә җир аша (тәгәл тәрҗемәсе: Акыллы бер тизлек белән сез күктән дөнья аша җәһәннәмгә сәфәр итегез!)—бу урында директор Фаустның тормыш юлын һәм аның һәлакәтен күз алдында тотмый, бәлки трагедиянең җирне дә, күкне дә, тәмугны да үз эченә алган булуын аңлата.

Күктә пролог

Бу пролог 1800 елдан соң язылган. Беренче пролог шикелле үк монысы да сюжетны символик һәм философик тирәнәйтү теләгеннән күздә тота һәм трагедиянең беренче өлешенә генә түгел, бәлки бөтенесенә карый. Фәрештәләрнең бөтен дөньяны мактап җырлаулары тантаналы яңгырый. Мефистофельнең иронияcе бу мактау җырына диссонанс кертә һәм кешенең түбәнлеген табигатьтәге гармонияле бөеклеккә каршы куя. Ләкин Фаустның тантана итәчәгенә ышану Гётегә прологта оптимистлык рухын саклау мөмкинлеген бирә.

[7] Кардәш сфералар белән һаман кояш җырлый үзенең җырларын. . .—Бу юлларда борынгы философ Пифагорның сфералар гармониясе, сфералар музыкасы турындагы карашлары чагылдырылган. Сфера (грекча sphaira—шар)—бу урында кояш системасы һәм башка системалар мәгънәсендә. Әсәрдә бу сүз хәрәкәт мәйданы, хәрәкәт даирәсе мәгънәсендә дә кулланыла.

[8] Каинатең гүзәл бүген дә. . .—Каинат—барлык дөнья, иҗад ителгән барлык нәрсәләр, творение мәгънәсендә.

[9] Үсә барган нәрсә яши, эшли мәңге. . .—дип башланган дүрт юл шигырь Гёте философиясе өчен бик характерлы бер фикерне үз эченә ала. Шигырьнең тәгәл тәрҗемәсе болай: „Мәңге хәрәкәт итә торган (эшли торган) һәм яши торган үсә баручы (das Werdende—становящееся) сезне мәхәббәтнең матур чикләре (яки: челтәре) белән чолгап алсын, һәм тибрәнеп торган күренешләрдә очкан нәрсәне дәвамлы (яки: ныклы—прочные) уйларда ныгытыгыз!"(очу—немец телендәге „weben", рус телендәге „парить", „реять" мәгънәсендә). Бу юллар трагедиянең төп темасын—мәхәббәт көче капма-каршылыкларны җиңә дигән карашны аңлаталар.

1 сцена. Төн

Фәннәрдән өмете өзелгәч, Фауст магиягә (сихергә) мөрәҗәгать итә, магия ярдәме белән табигать серләрен белергә тели. Үзенең ырымнары белән Фауст Дөнья һәм Җир рухларын чакыра, алар Фаустка кешенең бөек түгеллеген әйтәләр. Педант Вагнер белән сөйләшкәч, Фауст үзенең мондый тар карашлы филистерлардан өстен икәнлегенә ышана, ләкин ул әле пессимизмнан котыла алмый. Матур яшьлек елларын искә төшергән чаң авазлары гына Фаустны агу эчүдән тотып калалар.

[10] Хокук фәнен, дин фәннәрен, — һәйһат! — тырышып укып йөрдем . . . — Бу юллар Фаустның фәннәрдән, бигрәк тә дин белеменнән күңеле кайтканлыгын күрсәтәләр. „Һәйһат" сүзе дин белеменә карый, оригиналдагы „Leider" („кызганычка каршы") сүзе мәгънәне көчлерәк бирә.

[11] Реторта — химиядән тәҗрибәләр ясау өчен кәкере муенлы пыяла савыт.

[12] Нострадам — (дөресе: Мишель де Нотр Дам. 1503—1566) — Француз короле Карл IX сараендагы лейб-медик (король докторы), легендага кергән Фаустның замандашы, алдан хәбәр бирүләре белән шөһрәт алган кеше.

[13] Макрокосм — бөтен дөнья, зур дөнья, бөтен табигать.

[14] Җир рухы — кече дөнья, табигатьнең стихия көчләрен гәүдәләндерә. Макрокосмга акылы җитмәүдән курыккан Фауст Җир рухы белән очрашуга да чыдый алмый, тетрәп төшә.

[15] Өстен кеше — русчасы: сверхчеловек, немецчасы: der Übermensch. Ницше вакытыннан алып бүтән телләрдә дә популярлашкан бу сүз немец әдәбиятында XVII гасырда кулланыла башлаган булырга тиеш. Бу урында Гёте аны ирониялe мәгънәдә ала.

[16] Туку станогын алып заманнарның... — Гётедә еш очрый торган образ. Гёте табигатьне гаять зур бер туку станогы дип ала. „Weben" сүзе төрле мәгънә аңлата: туку, хәрәкәттә булу, очу-агылу (реять), әрле-бирле кагылу (сновать). Бу сүзне Гёте гадәттә һәрбер төрле стихиячел ритмик хәрәкәтне аңлату өчен куллана.

[17] Фамулус — профессорның ассистенты, гадәттә ул шәкертләрдән булган һәм профессорның үз йомышларын да үтәгән.

[18] Ах! Бикләнеп шушы музейның эченә...— Ул вакытларда музей (музаларга хезмәт итү урыны) дип галимнәрнең кабинетын атаганнар.

[19] Прагматик максима — гадәттә курчак комедияләренең ахырында була торган рәвешчә, әхлакка өндәп фикер әйтү, акыл өйрәтү.

[20] Тик лахзаның тудырганы файда бирә... — лахза — мгновенье мәгънәсендә (немецча: der Augenblick, күз ачып йомардай кыска вакыт).

[21] Сәлам сиңа, фиал... — Фиал — җәенке касә, немецча бозып әйтелгәне „Phiole" тар авызлы шешә мәгънәсендә йөртелгән, аны алхимиклар кулланганнар.

[22] Юклык эченә күчү хәвефен бирсә дә ул... — Бу урында „юклык эченә" — „в ничто," „ins Nichts" мәгънәсендә. Бетү, һәлак булу, юк булу дигән сүз.

2 сцена. Шәһәр капкасы янында

Шәһәр кешеләренең ял итеп йөрүләре картинасын реализм нигезендә бик оста сурәтләп биргән бу сцена Фаустны җанлы чынбарлыкка китереп кертә дияргә мөмкин. Фауст шәһәр кешеләреннән читләшми генә түгел, бәлки аларны кызыксынып күзәтә, шатланып күңел ачучылар арасында үзен гади бер кеше итеп сизә. Үләт чире таралган елда күрсәткән ярдәме өчен Фаустка крестьяннарның рәхмәт укулары Фаустны фән белемнәренең чикләнгән булуы турында уйга калдыра.

Фаустның яңа дөньялар күрү өчен сихерле кием соравына җавап булып, кара пудель килеп чыга.

[23] Изге Андрей төне — 29 ноябрьдан 30 ноябрьгә каршы төн. Немецларда халык ышанычы буенча, ул төнне изге Андрей рухына дога укыган кыз үзенә насыйп егетне төшендә күрә.

[24] Адептлар — урта гасырларда философик таш эзләү белән шөгыльләнгән алхимиклар, философлар һәм врачлар.

[25] Кара кухнядан чыкмады...— чиркәү өйрәтүенчә, алхимия белән шөгыльләнү—кара китапка (сихерчелеккә) бирелү диган сүз, кара кухня дип әйтүнең нигезе шунда.

[26] Кызыл арслан, Лалә, Король кызы—алхимиклар кулланган терминнар: Кызыл арслан—алтын яки күкерт, Лалә—көмеш яки терекөмеш, Яшь король кызы—панацея, ягъни, имештер, барлык чирләрдән терелтүче чара.

[27] Күчерде ул бүтән бер бүлмәгә...— биредә сүз төрле элементларны бергә кушу, аларны бер пыяла савыттан икенчесенә күчереп, төрле тәҗрибәләр ясау турында бара. Оригиналда „das Brautgemach“ сүзе алынган (кияү белән кәләш бүлмәсе мәгънәсендә). Брюсов аны „брачный покой“ дип тәрҗемә иткән. Холодковский тәрҗемәсендә „савыттан савытка күчерде“ дип бирелгән.

[28] Кара пудель (йөнтәс эт) — Мефистофель.

3 сцена. Фаустның кабинеты

[29] Монда язган „Башта Сүз булган!“ дип,— Гёте монда инҗилнең беренче юлын китерә һәм Фауст инҗилне тәрҗемә итәргә теләгән дип күрсәтә. Дөресендә аны немецчага Лютер тәрҗемә иткән. „Сүз“—грекча „Логос“—барлык идеалистик философиядәге төп төшенчәләрнең берсе, ул—үзенең иҗад иткән нәрсәләрендә күренүче гакыл мәгънәсен аңлата. Гётедән элек үк әле „Логос“ны: фикер, ихтыяр, эш дип тәрҗемә итүне алга сөрүчеләр булган. Фаусттан аны Гёте „Эш“ дип тәрҗемә иттерә (немецчасы: „die Tat“, русча тәрҗемәләрдә: „Дело“, „Деяние“).

[30] Сөләйман ачкычы яхшы...— Сөләйман (Соломон, дини әкиятләрдә: Сөләйман пәйгамбәр) рухларны сихерли белүче дип саналган. Сөләйман ачкычы—еврейларның кайбер дини секталарында изге танылган китап.

[31] Саламандра, Сильфа, Ундина, Кобольд...— стихияләрнең рухлары. Саламандра—алма-чуар тимгелле амфибия, әкиятләрдә күрсәтелүенчә, ул утта янмый. Сильфа яки Сильфида—һава рухларының исеме (сильфа грекча „көя“—„моль“—диган сүз), Ундина (латинча „unda“—„дулкын“ сүзеннән)—су рухларының исеме. Кобольд — җир рухларының исеме (русча кайбер тәрҗемәләрдә „домовой“ дип алалар, бездәге „өй иясе“нә, „бичура“га туры килә). Incubus — шул ук кобольднең бер төре, яшерен хәзинәләрне саклый, йоклаганда буып үтерә, имеш.

[32] Узгынчы схоласт—шәһәрдән шәһәргә йөрүче ярым галим, ярым шарлатан кешеләр тибы.

[33] Алдакчы, Бозучы, Чебеннәр алласы...—христианнарда шайтанның төрле исемнәре. Чебеннәр алласы еврейча—Бээль—Зебуб (Вельзевул сүзенең тәрҗемәсе) чебеннәрдән саклаучы, аларга үз хөкемен йөртүче алла. Бозучы (Губитель)—грекча Аполлион, еврейча Аввадон.

[34] Үзен һичнәрсәгә каршы куя...—философик термин буларак, „һичнәрсә"—русча „Ничто", „Бернәрсә"—„Нечто" мәгънәсендә алына.

[35] Пентаграмма—геометриядәге бер фигура. Урта гасырларда пентаграмманы агачка кадакланган Гайса эмблемасы дип санаганнар, убырлардан һәм явыз рухлардан сакласын дип аны ишек бусагаларына язганнар.

4 сцена. Фаустның кабинеты

Мефистофель Фаустны аның гыйльми эзләнүләре кабинетыннан киң дөньяга алып чыгарга тырыша. Фаустның төрле күңел ачуларга, азгынлыкка бирелүен тели. Мефистофельнең костюмы да аның шушы теләкләренә җавап бирә.

[36] Нәләт сина, күренеш сукырлыгы, син зиһенгә керәп каласың...—күренешләрнең эчке серен аңламыйча, аларны тышкы яктан карап кына зиһендә калдыруга Фауст үзенең каршы икәнлеген аңлата.

[37] Маммон—байлык демоны, алтын һәм комсызлык символы.

[38] Бар көч күчә балавызга, күнгә...—Балавыз-мөһер, печать, күн-пергамент (язу язар өчен).

[39] Микрокосм—кече дөнья, кеше мәгънәсендә (1 сцена искәрмәләрендәге макрокосмны карагыз).

[40] Collegium Logicum – логика курсы. Ул чагында университетларда укуны шуңардан башлаганнар. Гёте монда схоластик логикадан көлә.

[41] Испан итеге—тездән һәм боттан кысып сөякләрне сындыра торган җәза коралы.

[42] Encheiresin—грекча „кулда булу" дигән сүз. Борынгы греклар аны берәр әйбергә хуҗа булу мәгънәсендә кулланганнар, урта гасырларның химиклары исә аны табигатьтәге хәрәкәт законнарының, табигать серләренә хуҗа булуның формуласы итеп кулланганнар.

[43] Редукцияне ләкин өйрәнегез, һәм классификацияне шәп белегез...—формаль логика терминнары. Редукция—төшенчәләрне категорияләргә кайтару, гомумиләштерү, классификация—аларны классларга бүлү.

[44] Eritis sicut Deus, scientes bonum et malum—оҗмахта Хаваны аздырган елан сүзләренең латинча тәрҗемәсе: „Яхшыны да, яманны да белгән алла шикелле булырсыз".

5 сцена. Лейпцигта Ауэрбах базы

Тупас рәвештә күңел ачуларга Фауст беренче тапкыр студентлар компаниясендә очрый. Ләкин ул кызмача студентларның уенкөлкеләреннән кызык тапмый, тизрәк аннан китәргә тели. Йөгәнсез тойгыларга бирелү Фаустны җирәндерә генә.

[45] Ауэрбах базы—Лейпцигта күптәнге шәрап базы. Студент чагында Гёте анда еш кына булгалаган.

[46] Ягез, папа сайлыйк инде...,—„папа сайлау" — Көнбатыш Европа илләрендә эчкечелек мәҗлесләрендә күптәннән бирле булып килгән бер йола.

[47] Блоксберг—(яки: Брокен)—Гарцтагы бер тау исеме, халыктагы ышану буенча, җеннәр туе үткәрелә торган урын. Гарц—Төньяк Германиядә урманнар белән капланган таулар тезмәсе.

[48] Бер аякка аксый зәхмәт...—Тәуратта язылуынча, шайтан күктән җәһәннәмгә ташланганнан соң аксап йөри башлаган.

[49] Риппах, тиле Ганс—Риппах—Лейпциг янындагы бер авыл исеме. Немец әкиятләрендәге тиле Ганс, имештер, шунда яшәгән.

[50] Борау бирегез...—Агач өстәлдән аккан шәрап турындагы хикәяне Гёте Фауст турындагы халык легендасыннан алган. Легендада бу фокусны Фауст үзе эшли, Гёте, үзенең героен бу тупас эшкә кушмаска теләп, аны Мефистофельгә тапшыра.

[51] Каннибаллар—кеше ашаучылар.

[52] Күренеш ялган, сүз ялган...—Гёте бу сценаны да халык легендасыннан алган.

[53] Күреп калдым үзем чыкканын
Шул ишектән мичкә өстендә...—Ауэрбах базында хәзерге вакытта да 1525 елдан бирле сакланып килгән ике картина бар: аның берсендә мәшһүр сихерче Фаустның студентлар белән эчүе, икенчесендә—Фаустның мичкәгә утырып баздан чыгып китүе күрсәтелгән.

6 сцена. Убыр карчыгының кухнясе

Бу сцена 1788 елда язылган. Ул элекке сценаларны һәм Фауст белән Маргаританың мәхәббәте тарихын үзара бәйли, Фаустның үзгәрүен, тән ләззәтләренә бирелүен хәзерли һәм аңлата.

Бүтән сценалардагы кебек үк, монда да көчле сатира бар. Гёте үзенең замандашларына ишарә ясый, алардан көлә. Ә бик күп немец комментаторлары бу сценадагы аллегорияләрне „ачарга" теләп әллә нихәтле кәгазь язып бетергәннәр. Мондый педантларны каты мыскыллап, карт Гёте болай дигән: „Утыз ел инде алар Блоксбергтагы убыр карчыгының себеркеләрен, убыр карчыгы кухнясендәге маймылларның сөйләшүләрен тикшерәләр һәм шушы драматик-юмористик чепуханың аллегорияләреннән аерылырга һич тә теләмиләр".

[54] Маймыллар—убыр карчыгының хезмәтчеләре, шакшы хайваннар. Немец халкындагы ышану буенча, аларны, алла тарафыннан бар ителгән кешеләргә карикатура рәвешендә, шайтан яраткан.

[55] Юк, мең күпер салырмын мин...—халыкта җен күперләр сала дигән ышаныч булган, бигрәк тә, җеннәр тауларда табигый күперләрне сала дип ышанганнар.

[56] Кайнатабыз хәерче шулпасы..—Буржуазиянең хәйрат („яхшылык эшләү") оешмаларында ярлылар өчен хәзерләнгән сыек, туклыксыз аш. Бу урында Гёте Германиядә күп таралган эчтәлексез, сыек әсәрләр мәгънәсен аңлата.

[57] Бу иләк кирәк каракны белергә...—Борынгы Римнан калып, урта гасырларда да сакланган ышаныч буенча, иләк үзеннән үзе карак ягына әйләнә булган.

58 — Нәрсә күрәм? Нинди күк гүзәле күренә миңа серле бу көзгедә... — Тылсымлы көзгедә кеше үзенең теләгәнен һәм киләчәген күрә дигән ышаныч булган. Көзгедә Фаустка кем күренгән: Еленамы, Гретхенмы, әллә гомумән гүзәллек идеалымы,— комментаторлар арасында бу турыда бәхәс бара. Мефистофельнең соңгы репликасыннан күренүенчә („Бик шәп эчтең, хатын-кызлар бар да, синеңчә, тиң булыр Еленага“), Гёте борынгы грек Еленасын күз алдында тоткан булырга тиеш.

59 Бик табигый: нәкъ алты көн үзе ходa эшләгән һәм: „яхшы булды!“ дигән шунда... — дини хорафәтләрдә күрсәтелүенчә, алла бөтен дөньяны алты көн эчендә барлыкка китереп бетергән һәм хатын-кызны шул алтынчы көндә бар иткән.

60 Скипетр — асылташлар белән бизәп ясалган таяк, патшалык билгесе.

61 Туры килгәндә, туа уйлар да... — шигырьләрендә мәгънә сирәк очрый торган формалист шагыйрьләргә сатира.

62 Ике козгын кая киткән... — „Ике козгын“ — җеннәрнең мәҗүси германнардан христианнарга күчкән бер билгеләре.

63 Өйрәтә шәп тапкырларга убыр... — Бу тапкырлау таблицасы мистикларча саннарны символ дип санауга сатира булып тора Убыр карчыгының таблицасында „яшерен“ мәгънә табарга тырышучы комментаторлардан Гёте үзе бик нык көлгән.

64 Өчне бер дип, берне өч дип, анда чын урынына ялган ныгып калган... — Христиан диненең изге өчлек (святая троица) турындагы тәгълиматына сатира.

65 Сивиллалар — борынгы дөньяда киләчәк турында хәбәр биргән, күрәзәлек иткән хатыннар.

7 сцена. Урам

Фауст беренче тапкыр — убыр карчыгында сихерле шәрап эчкәннән соң — мәхәббәт маҗаралары эзләүче „яшәргән“ кеше сыйфатында алга килеп баса. Фауст өчен физик ләззәтләргә бирелү, сыналу, эзләнү һәм ялгышулар чоры башлана.

66 Матур туташ түгел шул мин... — Мещан семъясыннан чыккан Маргарита „туташ“ дип эндәшкәнне кире кага, чөнки ул чагында югары сословиеләрнең, дворяннарның кызларына гына „туташ“ („Fraülein“) дигәннәр.

67 Минем көчем җитми аңар... — Фауст тойгыларының ялкынын тагын да көчлерәк дөрләтү өчен Мефистофель юри төрле киртәләр уйлап чыгара.

68 Азгын Ганс төсле син сөйлисең... — Азгын Ганс (Hans Liederlich) — немец халык әдәбиятында җиңел карашлы, әйттергеч егет тибы. Н. Холодковский тәрҗемәсендә Дон Жуан дип алынган.

69 Бай хәзинәләр күмелгән әйбәт урыннарны беләм... — Халык легендасында доктор Фауст хәзинәләр эзләүче дә итеп күрсәтелә.

8 сцена. Кич

70 Нинди кечкенә син, олы тиле! Егылыр иден аягына аның... — Алдагы сценада үзенең циникларча әдәпсез сөйлә-

нүеннән Фауст хәзер ояла, аның йөрәгендә Маргаритага карата чын мәхәббәт тойгылары уяна.

[71] Нинди бөркү, авыр һава...— Немецлардагы ышану буенча, шайтан булган бүлмәдә һава бөркүләнеп кала.

[72] Бер король булган Фуләдә...— 1774 елда ук әле Гёте тарафыннан язылган баллада. Фулә—әкияттәге ил, кайдадыр Европаның төньягында дип исәпләнгән.

9 сцена. Ял итеп йөргәндә

[73] Чиркәүнең нык аның аш казаны. — Гётеда чиркәүдән, руханилардан көлү еш очрый.

10 сцена. Күрше хатын йорты

Картаеп бара торган Мартаны һәм аңар Мефистофель килүен Гёте реалистларча бик оста сурәтли. Мартаның ире — ялланып хезмәт итүче сугышчы, ландскнехт.

11 сцена. Урам

Көчле дәрткә бирелеп, Фауст ялган шаһитлек итәргә риза була.

[74] Sanctasimplisitas!—Изгегадилек! Чехлар милли хәрәкәтенең юлбашчысы Ян Гусның утта яндырылганда кычкырган тарихи сүзләре. Ул аларны, бер карчыкның утка коры чыбыклар өстәвен күреп, әйткән.

[75] Бик масаеп билгеләмә бирмәденме...—Мефистофель Фаустның студентларга укыган лекцияләрен күздә тота, университет фәненең чикләнгән, көчсез булуына ишарә ясый.

[76] Чын йөрәктән... — Фауст үзен Маргаритага чын күңелдән гашыйк булдым, дип сизә. Мефистофель „мәңгелек" мәхәббәтнең ахырына скептикларча карый.

[77] Хаклы бул син, чөнки миңа шулай кирәк...—Төгәл тәрҗемәсе: „син бигрәк тә шуның өчен хаклы, чөнки мин тиешлемен", ягъни, сиңа буйсынырга тиешлемен, чөнки үземнең мәхәббәтем белән көрәшә алмыйм.

14 сцена. Урман һәм мәгарә

Бу сценада Фауст эчке кичерешләренең бөтен байлыгы белән алга килеп баса. Мефистофель белән союз ясау һәм, алдагы сценаларда күренүенчә, сөю ләззәтләренә ашкыну Фаустның философик эзләнүләрен бетерә алмаганнар. Ләкин хәзер инде Фауст, практик тормышта тәҗрибә алып, тынычрак акыллы кешегә әйләнгән. Элекке философик өметсезлегеннән котылып, Фауст табигатьнең йөрәгенә керә. Кешенең табигатькә „кардәш", „туган" булуы турындагы тантаналы монолог кешене „илаһи" табигатьнең бер өлеше дип өйрәткән Спиноза йогынтысында язылган.

Мефистофель Фаустның югары-философик тойгыларга бирелүеннән һич тә риза түгел. Ул, мәкерле рәвештә Гретхенның сагышы турында сөйләп, Фаустны урманнан кире кайтырга мәҗбүр итә.

[78] Күзәтүнең кырыс шатлыгы йомшара...— Күзәтү — созерцание (die Betrachtung) мәгънәсендә.

[79] Алты көннең эшен үзендә хис итә...— Бөтен табигатьне үзенең йөрәгендә дип сизә, мәгънәсендә (дини әкиятләрдә әйтелүенчә, алла бөтен дөньяны алты көн эчендә яраткан).

16 сцена. Мартаның бакчасы

Фаустның Маргарита белән дин турындагы сөйләшүләре дә табигатьнең илаһилыгы турында Спиноза тәгълиматы белән сугарылган. Чиркәү хорафатләрен Фауст чит күрә. Бу мәсьәләдә Фауст сүзләре Гётенең үз карашларын чагылдыра. Гётенең дусты Кестнер аның турында болай дип сөйләгән: „Аны бөтенләй үк динле дип әйтеп булмый. Ул чиркәүгә йөрми, дога сирәк укый, боларны эшләргә, ди ул, миндә алдакчылык җитми... Ул хәкыйкатькә омтыла, ләкин, аның тышкы күренешенә караганда, аны тоюга күбрәк әһәмият бирә“.

[80] Изге бүләкләргә хөрмәтең күрмимен...— Христиан динендәге хорафатләрне (святые дары, святое причастие) хөрмәтләмисең дигән мәгънәдә.

[81] Физиогномиканы ул начар белми...— Физиогномика — кешенең тышкы сызыклары буенча аның эчке сыйфатларын, характерын белү фәне.

17 сцена. Кое янында

[82] Һәм чиркәүдә тәүбә кылмаген дә кисен...— Азгын аналарны (иргә чыкмый бала табучыларны) чиркәүдә тәүбә иттерү йоласы 1786 елда Веймарда кабул ителгән законнар буенча бетерелгән, „андый йола бала үтерүләрне генә күбәйтә“ дип, Гёте аның бетерелүе яклы булган.

[83] Егетләребез таптар кызның чәчәк таҗын, без ташларбыз салам ишек төбенә аның...— „Гонаһлы кыз“ иргә чыкканда аны халык алдында мыскыл итү гадәте.

Егетләр туй көнендә кызның чәчәкләрдән үрелгән баш киемен (венок) тартып алып, аяк астына ташлаганнар, кызлар яшь кәләшнең капка төбенә тураклаган салам сипкәннәр.

18 сцена. Шәһәр стенасы

Дога укучы Маргарита кичерешләренең чын күңелдән һәм бик тирәнтен икәнлеген дога сүзләренең гади һәм „әдәби эшләнмәгән“ булулары тагы да ачыграк күрсәтеп торалар. Ритмның өзек-өзек булуы һәм доганың үксеп-үксеп елаулар белән аралашуы аның көчен арттыралар.

[84] Mater dolorosa — Католикларда хәсрәт чигүче „алла ана“ сурәте. Аның күкрәгендәге кылыч — баганага кадакланган улы Гайса өчен тирән газап чигү символы. Немецларда урта гасырлардагы гадәт буенча алла-ананың һәм „шәһәр сакчылары“ның образлары шәһәрнең эчке һәм тышкы стеналары арасында урнаштырыла булганнар,

19 сцена. Төн. Гретхен ишеге турында урамда

[85] Валентин—әсәрдәге бөтенлекле, художество ягыннан тулы эшләнгән образларның берсе. Шунысы характерлы: бу батыр солдат — ландскнехт, Маргаритага килгән бәхетсезлек өчен кайгырганда, барыннан да бигрәк, дуслар компаниясендә сеңелем белән мактанып булмаячак, дип кайгыра.

[86] Сакристия – католиклар чиркәвендә гыйбадәт өчен кирәкле әйберләрне (изге савыт-сабаны, дин башлыкларының гыйбадәт киемнәрен) куяр өчен билгеләнгән аерым бер урын.

[87] Җен сугыша...—Валентинны чынында Мефистофель үтерә, ә Фауст тик пассив роль генә уйный.

20 сцена. Чиркәү

[88] Явыз рух—Композитор Гуно тарафыннан язылган „Фауст" операсында бу рольдә Мефистофель чыга. Ләкин авторның күздә тотканы Мефистофельме, әллә иблиснең бүтән берәр илчесеме, яки ул Маргаританың вөждан газабын аңлатамы,—бу сорауга әсәрнең үзендә ачык җавап табып булмый.

21 сцена. Вальпургия төне

Бу сценаны Гёте 1800—1801 елларда язган, ләкин аның турындагы фикер шагыйрьдә күптән туган булса кирәк.

Гёте үлгәннән соң бу сценаның күп кенә караламалары табылган, алар сценаның язылып бетмәгәнлеген күрсәтәләр. Ләкин үзенең шушы хәлендә дә җеннәр туе сценасы хәрәкәтнең үсешендә критик момент булып тора: Валентин үтерелгәннән соң Фауст, Мефистофель котыртуы буенча, азгынлык баткаклыгына ташлана, тик сөйгән кызының образын күзгедә күрү аны һәлакәттән коткарып кала.

[89] Вальпургия төне — VIII гасырда бер монастырьдә игуменья (монастырь башлыгы) булган Вальпургия исемле монах хатынны изге кеше дип санаганнар һәм беренче май көнен католиклар аның көне дип бәйрәм итәләр. Германиядә христианлык урнашудан элек халык беренче майны яз бәйрәме рәвешендә үткәргән булса кирәк. Мәҗүсилектән калган барлык гадәтләрне христиан дин башлыклары шайтан азгынлыгы дип белдергәннәр һәм яз бәйрәмен дә 30 апрель төнендә Гарц тауларының берсендә үткәрелә торган җен туе дип аңлатканнар.

Җеннәрнең, убыр карчыкларының төрле сүзләрен, репликаларын „ачып салу" өчен комментаторлар күп көч түккәннәр, хәлбуки ул сүзләрнең күпчелеге, Гётенең үзенчә әйткәндә, „драматик-юмористик чепуха" дан гыйбарәт һәм художество чаралары белән Вальпургия төне картинасын сурәтләү теләген күзәтәләр.

[90] Ширке һәм Эленд — Гарцтагы Брокен (Блоксберг) тавы итәгендә ике авыл.

[91] Адашкан ут матур яна, әнә...— Халык ышанычы буенча, адашкан утлар (блуждающие огоньки) һавада очып йөрүче

тынгысыз җаннар дип, юлчыларны адаштыра торган явыз рухлар дип саналганнар, аларга шайтан хезмәтчеләре дип караганнар.

[92] Уриан—җеннең бер исеме. Немецлар берәүнең исемен әйтергә теләмәгәндә, көлке өчен, аны Уриан дип атыйлар.

[93] Баубо — грек мифологиясендә Деметра исемле алиһәгә сөт имезгән азгын хатын. Бу сценада грек мифологиясеннән алынган бердәнбер персонаж.

[94] Ильзенштейн — Гарц кыяларының берсе.

[95] Май ягу дәрт бирә икән...—Убырлар һәм сихерчеләр һавага күтәрелү өчен тәннәренә май ягалар дигән ышаныч борынгы грекларда да булган.

[96] Юл бирегез, Фоланд килә...—Фоланд—җеннең немецлардагы иске исеме.

[97] Инкогнито йөрү— кем икәнеңне белдермичә, ялган исем белән йөрү.

[98] Тез тасмасын такмыйм әле...—Тез тасмасы (подвязка) ордены — инглизларда югары орден.

[99] Парвеню (французча) түбән катлаудан чыгып, югары урын алган кеше (выскочка).

[100] Лилит — Адәмнең беренче хатыны. Хорафәтләрнең күрсәтүенчә, Лилит Адәмнең кабыргасыннан түгел, бәлки үзенә аерым яралган, соңыннан ул Адәмнән качып китеп, Саммаэль дигән җеннең хатыны булган. Сихерчеләргә, убырларга багышланган әдәбиятта Лилит, аздыргыч җен хатын рәвешендә, бик еш телгә алына.

[101] Кагылмасын сиңа матур толымнары... —Лилитнең чәчләрендә сихер көче бар, аның чәч араларында җеннәр яшиләр, дигән караш булган. Гомүмән урта гасырларда убыр хатыннарның чәчендә сихер көче бар, дип ышанганнар һәм сихерчелек өчен хөкемгә тартылган хатыннарның иң элек чәчләрен ала торган булганнар.

[102] Проктофантасмист — Бу исем астында XVIII гасырда яшәгән һәм Гёте белән Шиллергә каршы позициядә торган талантсыз немец язучысы Николаи бирелә. Николаи өтек фикерле рационалист булып, кеше тойгыларының ролен бөтенләй инкарь иткән.

[103] Ул үзенең иске тирмәнендә сыман...—Гёте „иске тегермән“ дип Николаи тарафыннан чыгарылган күп томлы „Гомуми немец көтепханәсен“ атый.

[104] Без акыллы, ә Тегельдә өрәк йөри...—Тегель—немец лингвисты Гумбольдтның Берлин янындагы именьесе. Тегельдә өрәкләр йөри дип, Гёте заманында Берлинда төрле хәбәрләр таралган. Бу турыда Николаи Берлин академиясенә зур бер трактат та язып биргән.

[105] Кызыл тычкан сикереп төште авызыннан...—Халык арасында таралган ышану буенча, гыйшык сүзләре сөйләгән чагында убыр кызының авызыннан кызыл тычкан сикереп чыга, имеш. Бу — канлы катастрофа булачагын, убыр кызының дошманлык һәм үтереш орлыклары чәчүен аңлата.

[106] Ишеткәнең бардыр Медуза турында...—Медуза — борынгы грек мифологиясендә куркыныч бер җанвар исеме, Медузага караган кеше шунда ук ташка әйләнә булган. Персей дигән батыр Медузаның башын кылыч белән чабып өзгән.

[107] Пратер — Вена шәһәрендәге бер парк, ял урыны.

[108] Servibilis — „Хезмәткә хәзер“ дигән сүз; хезмәтче рух.

22 сцена. Вальпургия төнендәге төш, яки Оберон белән Титаниянең алтын туе (интермеццо)

1796 елда Гёте һәм Шиллер дүртәр юллык бик күп сатирик шигырьләр — эпиграммалар язып, „Музалар альманахы"нда бастырып чыгарганнар һәм аларны „ксенияләр" ("кунакчыллык бүләге") дип атаганнар. Ул вакыттагы культуралы кешеләрнең тормышында булган кабахәтлекләрдән ачы рәвештә көлгәнгә күрә, бу ксенияләр күп кешенең ачуы кабаруга сәбәп булганнар. Гёте мондый эпиграммалар язуны дәвам иттергән һәм шуларның кайберләрен „Вальпургия төнендәге төш" сценасында берләштереп, интермедия рәвешендә, „Фауст" трагедиясенә дә керткән. Бу интермедиянең төп темага һич бәйләнеше юк. „Вальпургия төнендәге төш" дигән исемне Гёте Шекспирның „Җәйге төндәге төш" исемле комедиясенә ияреп биргән. Оберон, Титания һәм Пук образлары шуннан алынган (Ариэль образы Шекспирның „Давыл"ыннан алынган).

[109] Оберон белән Титаниянең алтын туе—Эльфлар патшасы Оберон үзенең хатыны Титания белән озак аерылып торганнан соң яңадан кушыла һәм ир белән хатынның килешүе хөрмәтенә бәйрәм үткәрелә. Туйда рухлар спектакльдәге кебек Оберон алдында чыгышлар ясыйлар.

[110] Мидингның уллары.—Мидинг—Веймар театрының декораторы һәм машинисты. Аның истәлегенә Гёте зур бер элегия багышлаган. Мидингның уллары — театр художниклары, декораторлар, сәхнә эшчеләре. Интермедиядәге уен сәхнәдә түгел, бәлки „кырда", „тауларда" бара, димәк, декораторлар ял итәләр.

[111] Геннингс, Август—Гёте белән Шиллернең классик эстетикасын "христианлык рухына чит нәрсә" дип инкарь иткән бер публицист.

[112] Ci-devant—элекке (бывший). Геннингс тарафыннан чыгарылган журнал, 1802 елда ябылган. Гёте шуңар ишарә кыла.

[113] Парнас — Грециядә биек бер тау исеме. Анда, имештер, Аполлон һәм музалар (фән һәм сәнгать алиһәләре) яшәгәннәр. Парнаска менү — шагыйрь булу мәгънәсендә кулланыла.

[114] Булсам әгәр бар сымин, югалттым дырак ылны...—Фихтенең бөтен тышкы дөньяны субъектив дөньядан („мин"нән) китереп чыгаручы идеалистик философиясенә ишарә.

23 сцена. Кояшсыз көн. Кыр

[115] О, син, чиге булмаган рух...—Фауст Җир рухына мөраҗәгать итә.

[116] Кайтар шул кортны үзенең эт кыяфәтенә... — Фауст Мефистофельнең пудель кыяфәтендә килгән чагын искә төшерә.

24 сцена. Төн. Ачык кыр

[117] Нишлиләр анда, дар агачы янында... — халыкта искедән калган ышаныч буенча, үлем җәзасы башкарыла торган җирдә, җәзаланган кешеләрнең җаннары очып йөри булган.

25 сцена. Зиндан

Бу сценада Гёте Фауст белән Маргарита арасындагы мәхәббәтнең фаҗигале рәвештә тәмамлануын сурәтли.

Маргарита зинданда. Авыр истәлекләр аны акылыннан яздыралар, кошмарлы күренешләр аның җанын газаплыйлар. Маргарита үзенең яшерен туган баласы турында, мещаннар мөхитенең гаепләвеннән куркып, аны үз кулы белән үтерүе турында, Фауст тарафыннан үтерелгән абыйсы һәм, йоклаткыч эчемлекләрдән булса кирәк, үлгән әнисе турында уйлый. Зинданга килгән Фаустны Маргарита башта палач дип белә.

Фаустның иркәләү сүзләре аз гына вакытка Маргаританы аңына китерәләр. Ләкин кире кайтмаячак матур көннәр турындагы истәлек озакка бармый, Маргарита тагын акылын җуя. Сөйгәне Фаустның үзен „салкын" тотуына Маргарита күңелсезләнә, качып китәргә риза булмыйча, зинданда кала, чөнки аны вөҗдан шелтәләре дә, сакчылар да, чит илдә хәерчелектә яшәү мөмкинлеге дә куркыта. Үз бәхете өчен көрәшүдән ваз кичеп, ул „алла хөкеменә" бирелә.

[118] Чаң чакыра, таяк сынды...—Маргарита үзенә үлем җәзасы бирелүен көтә. XVIII гасырның ахырына кадәр сакланган гадәт буенча, үлем җәзасы алдыннан "гөнаһлылар чаңы" какканнар. Хөкем карарын укыганнан соң судья, җәзаны тормышка ашыру тиешлеген белдереп, таяк сындырган.

[119] Ул котылды! — Мефистофельнең „һәлак булды!" дигән сүзләренә югарыдан килгән аваз: „ул котылды!" дип җавап кайтара. Бу җавап Маргаританың трагедиядәге символик ролен күрсәтә, Маргаританың чын күңелдән булган саф мәхәббәте шундый гуманистлык җавабы өчен нигез бирә.

ЭЧТӘЛЕК

Бит

Гёте һәм аның „Фауст“ әсәре. *Х. Госман* 5

ФАУСТ. Беренче кисәк.

Багышлау 11

Театрда пролог 13

Күктә пролог 18

Сценалар 1—25 23

Аңлатмалар һәм сүзлек *М. Максуд* 189

ИЛЛЮСТРАЦИЯЛӘР

Кипренский. Гёте портреты

Делакруа. Иллюстрацияләр

25 сцена. Зиндан

Бу сценада Гёте Фауст белән Маргарита арасындагы мәхәббәтнең фаҗигале рәвештә тәмамлануын сурәтли.

Маргарита зинданда. Авыр истәлекләр аны акылыннан яздыралар, кошмарлы күренешләр аның җанын газаплыйлар. Маргарита үзенең яшерен туган баласы турында, мещаннар мөхитенең гаепләвеннән куркып, аны үз кулы белән үтерүе турында, Фауст тарафыннан үтерелгән абыйсы һәм, йоклаткыч эчемлекләрдән булса кирәк, үлгән әнисе турында уйлый. Зинданга килгән Фаустны Маргарита башта палач дип белә.

Фаустның иркәләү сүзләре аз гына вакытка Маргаританы аңына китерәләр. Ләкин кире кайтмаячак матур көннәр турындагы истәлек озакка бармый, Маргарита тагын акылын җуя. Сөйгәне Фаустның үзен „салкын" тотуына Маргарита күңелсезләнә, качып китәргә риза булмыйча, зинданда кала, чөнки аны вөҗдан шелтәләре дә, сакчылар да, чит илдә хәерчелектә яшәү мөмкинлеге дә куркыта. Үз бәхете өчен көрәшүдән ваз кичеп, ул „алла хөкеменә" бирелә.

118 Чаң чакыра, таяк сынды...—Маргарита үзенә үлем җәзасы бирелүен көтә. XVIII гасырның ахырына кадәр сакланган гадәт буенча, үлем җәзасы алдыннан "гөнаһлылар чаңы" какканнар. Хөкем карарын укыганнан соң судья, җәзаны тормышка ашыру тиешлеген белдереп, таяк сындырган.

119 Ул котылды! — Мефистофельнең „һәлак булды!" дигән сүзләренә югарыдан килгән аваз: „ул котылды!" дип җавап кайтара. Бу җавап Маргаританың трагедиядәге символик ролен күрсәтә, Маргаританың чын күңелдән булган саф мәхәббәте шундый гуманистлык җавабы өчен нигез бирә.

ЭЧТӘЛЕК

Бит

Гёте һәм аның „Фауст“ әсәре. *Х. Госман* 5

ФАУСТ. Беренче кисәк.

Багышлау 11
Театрда пролог 13
Күктә пролог 18
Сценалар 1—25 23
Аңлатмалар һәм сүзлек *М. Максуд* 189

ИЛЛЮСТРАЦИЯЛӘР

Кипренский. Гёте портреты
Делакруа. Иллюстрацияләр

ТУЛЫ БУЛМАГАН УРТА ҺӘМ УРТА
МӘКТӘПЛӘР ӨЧЕН

И. ГЁТЕ

ФАУСТ

(на татарском языке)

Җаваплы редакторы Ш. Маннур

Техник редакторы И. Зәйнуллин

Корректоры Л. Хальфеева

Басарга кул куелды 29|III-48 ел. ПФ 01210. Тираж 10.165.
Басма табак 12³/₄. Заказ 462. Бәясе 15 сум.

Издательстволар һәм полиграфия Управлениесе каршындагы
Камил Якуб исемендәге китап фабрикасында басылды.
Казан, Бауман ур. 19, 1948 ел.

Бэясе 15 сум